# СОВЕРШЕНСТВОВАНИЕ МЕТОДИКИ ОБУЧЕНИЯ ЯЗЫКАМ: ПЛОЩАДКА ОБМЕНА ПРОГРЕССИВНОЙ ПРАКТИКОЙ

КАЗАНСКИЙ ФЕДЕРАЛЬНЫЙ УНИВЕРСИТЕТ
ИНСТИТУТ ФИЛОЛОГИИ И МЕЖКУЛЬТУРНОЙ КОММУНИКАЦИИ
НОЦ статегических исследований в области родных языков и культур
НОЦ «Институт Каюма Насыри»

# СОВЕРШЕНСТВОВАНИЕ МЕТОДИКИ ОБУЧЕНИЯ ЯЗЫКАМ ПЛОЩАДКА ОБМЕНА ПРОГРЕССИВНОЙ ПРАКТИКОЙ

# ТЕЛЛӘРГӘ ӨЙРӘТҮ МЕТОДИКАСЫН КАМИЛЛӘШТЕРҮ АЛДЫНГЫ ТӘҖРИБӘ БЕЛӘН УРТАКЛАШУ МӘЙДАНЧЫГЫ

МАТЕРИАЛЫ VIII МЕЖДУНАРОДНОГО НАУЧНО-МЕТОДИЧЕСКОГО ОНЛАЙН-СЕМИНАРА

**КАЗАНЬ**

**2024**

**УДК 372.881.1**
**ББК 74.268.1**
**С56**

*Печатается по рекомендации Учебно-методической комиссии*
*Института филологии и межкультурной коммуникации*
*Казанского федерального университета*

**Научные редакторы:**
доктор филологических наук, профессор **Р.Р. Замалетдинов;**
доктор филологических наук, профессор **А.Ш. Юсупова;**
доктор филологических наук, профессор **Мостафа Онер**

**Редакционная коллегия:**
кандидат филологических наук, доцент **Э.Н. Денмухаметова**

**С56** **Совершенствование методики обучения языкам**: **площадка обмена прогрессивной практикой:** материалы VIII Международного научно-методического онлайн-семинара (Казань, 20 февраля 2024 г.) = Телләргә өйрәтү методикасын камилләштерү: алдынгы тәҗрибә белән уртаклашу мәйданчыгы: VIII Халыкара фәнни-методик онлайн семинар материаллары (Казан, 2024 елның 20 феврале). – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2024. –339 с.

Сборник включает в себя материалы VIII Международного научно-методического семинара «Совершенствование методики обучения языкам: площадка обмена прогрессивной практикой, проведенного 20 февраля 2024 года в онлайн-режиме на базе Института филологии и межкультурной коммуникации КФУ, при участии ученых из Эгейского университета (Турция), Азербайджанского государственного педагогического университета (Азербайджан), Евразийского национального университета им. Л.Н.Гумилева и Казахского национального педагогического университета имени Абая (Казахстан), Национального университета Узбекистана имени Мирзо Улугбека (Узбекистан), Башкирского государственного педагогического университета им. М. Акмуллы и других вузов, ссузов России. Сборник адресован научным работникам, преподавателям вузов и ссузов, аспирантам, студентам, а также широкому кругу читателей.

Материалы публикуются в авторской редакции.

**УДК 372.881.1**
**ББК 74.268.1**

**© Издательство Казанского университета**

# ЭТНОКУЛЬТУРНЫЙ АСПЕКТ ИЗУЧЕНИЯ РАССКАЗА «ИЛЬЯС» Л.Н. ТОЛСТОГО

*Абдуллина Л.Б.*
*Стерлитамакский филиал Уфимского университета науки и технологий*

***Аннотация.*** В этой статье дана попытка изучения рассказа «Ильяс» Л.Н. Толстого в этнокультурном аспекте. На наш взгляд, чтение и анализ данного литературного произведения дает возможность в определенной степени познакомиться с духовной и материальной культурой башкирского народа, с его бытом, образом жизни и традициями.

***Ключевые слова***: Л.Толстой, этнокультура, русская литература.

В последние годы в педагогической науке особое внимание уделяется исследованиям, посвященным вопросам формирования этнокультурной компетенции обучающихся разных уровней подготовки. Как пишет Т.В. Поштарева, этнокультурная компетенция – это одна из важнейших составляющих личности, включающая в себя «объективные представления и знания о той или иной этнической культуре», которая реализуется «через умения, навыки и модели поведения, способствующие эффективному межэтническому взаимопониманию и взаимодействию» [2: 228]. Наличие этнокультурной компетенции с одной стороны способствует укреплению межнациональных связей в обществе, толерантности и уважительного отношения к представителям других этнических групп, с другой – позволяет каждой личности осознать себя частью конкретного этноса, знать историю и культурные ценности своего народа.

В современной системе образования формирование этнокультурных представлений обучающихся осуществляется в рамках разных учебных дисциплин, особое место среди которых принадлежит литературе. Художественный мир, воссозданный писателями, является уникальным средством приобщения подрастающего поколения к культурным ценностям разных народов. Искусство слова во все времена оставалось источником знаний, материалом для формирования духовно-нравственных ориентиров личности. Процесс изучения художественного произведения дает возможность получить социально-нравственный опыт в разнообразных жизненных ситуациях, так как литература – это есть отражение самой жизни.

В этой статье дана попытка изучения рассказа «Ильяс» Л.Н. Толстого в этнокультурном аспекте. На наш взгляд, чтение и анализ данного литературного произведения дает возможность в определенной степени познакомиться с духовной и материальной культурой башкирского народа, с его бытом, образом жизни и традициями.

По мнению толстоведов, рассказ «Ильяс» был написан автором в несколько этапов. «Сначала, в автографе, целостно сложились сюжет и образы произведения, его идейно-тематическое своеобразие. Рукопись создана во

второй декаде марта 1885 года. Основанием для датирования этого периода являются письма Толстого к жене от 14 и 15 марта и дата переписчика 16 марта» [3: 246].

Источником вдохновения стали реальные факты из жизни Л.Н. Толстого. Основные события рассказа «Ильяс» разворачиваются в хорошо знакомых автору башкирских степях. Как отмечают биографы писателя, осенью 1871 года Толстой купил земельные угодья в Самарской губернии (а в 1878 году это владение было увеличено). В своем поволжском имении писатель жил в 1881 и в 1883 году, а в 1870-е годы выезжал на кумыс в самарскую степь почти ежегодно, за исключением 1877 и 1879 годов.

Толстой-художник активно общался с башкирами, внимательно наблюдал за их образом жизни, бытом и изучал их духовную культуру. Все эти впечатления писателя нашли отражение в его произведениях, многочисленных дневниковых записях, письмах. Так, в письме к своей супруге Софье Андреевне от 16-17 июля 1871 года Толстой писал: *«Принимали нас везде с гостеприимством... Куда приезжаешь, хозяин закалывает жирного курдюцкого барана, становит огромную кадку кумысу, стелет ковры и подушки на полу, сажает на них гостей и не выпускает, пока не съедят его барана и не выпьют его кумыс. Из рук поит гостей и руками (без вилки) в рот кладет гостям баранину и жир, и нельзя его обидеть»* [5: 198-199].

В рассказе «Ильяс» Л.Н. Толстой не раз упоминает о традициях гостеприимства башкирского народа. Вспоминая о прошлой благополучной жизни главного героя, автор писал: *«И приезжали к нему гости издалека. И всех принимал и всех кормил и поил Ильяс. Кто бы ни пришёл, всем был кумыс, всем был чай и шерба, и баранина. Приедут гости, сейчас бьют барана или двух, а много наедет гостей, бьют и кобылу»* [4: 41]. В указанном эпизоде особо подчеркиваются доброжелательность, великодушие Ильяса: когда он жил в достатке, «всех принимал и всех кормил».

Простота в общении и дружелюбие башкир весьма колоритно представлены и в эпизоде рассказа, где Мухамедшах принимает у себя дома издалека приехавших гостей: *«И случилось раз, приехали к Мухамедшаху сваты, далекие гости; пришел и мулла. Велел Мухамедшах поймать барана и убить. Ильяс освежевал барана и сварил и послал гостям. Поели гости баранины, напились чаю и взялись за кумыс. Сидят гости с хозяином на пуховых подушках, на коврах, пьют из чашек кумыс и беседуют»* [Толстой, 1937: 32]. Как видим, важнейшими элементами башкирского гостеприимства являются традиционные угощенья – баранина, конина и, конечно же, целебный кумыс. Р.Р. Баязитова пишет: «Подача кумыса приглашённому гостю означает приобщение его к общей трапезе. Молоко и молочные продукты у башкир считались сакральными» [1: 254].

Как известно, в тюркских народах всегда семейный быт предполагал почтительное отношение к родителям, беспрекословное подчинение старшему поколению. А родители же в свою очередь старались как можно лучше устроить дальнейшую жизнь своих детей: для дочерей искали выгодных,

обеспеченных мужей; сыновьям выделяли по возможности земельные угодья для ведения своего хозяйства. Таким отцом был и главный герой рассказа: *«Отделил его Ильяс, дал ему дом и скотины, и убавилось богатство Ильяса»* [4: 29].

Писатель в своем рассказе демонстрирует не только яркие эпизоды, связанные с описанием традиций, но и показывает плачевные последствия непослушания и нарушения общепризнанных канонов: «Ильяс оказался на пороге чужого жилища из-за нарушения обычая минората, по которому младший сын должен был ухаживать за своими престарелыми родителями» [Баязитова, 2022: 256].

В данном рассказе писатель сумел не только правдиво изобразить отдельные особенности традиционно-бытовой культуры башкир, но и отразил общий дух эпохи. Толстой мастерски передает национальный колорит, духовно-нравственные идеалы башкирского народа. Жизненные невзгоды, несчастья обедневшего Ильяса во многом находят параллель с нелёгким положением башкирского народа Самарской губернии.

**Литература**

1.Баязитова Р. Р. Традиционный этикет башкир в рассказе Льва Толстого «Ильяс» // Вестник Омского университета. Серия «Исторические науки». 2022. – Т. 9, № 2 (34). – С. 251–257.

2.Поштарева Т. В. Формирование этнокультурной компетентности учащихся в полиэтнической образовательной среде: Дисс... д-ра пед.наук: 13.00.01. – Владикавказ, 2009. – 383 с.

3.Сизова И. И. Рассказ Л. Н. Толстого «Ильяс»: актуальные проблемы истории создания и эдиции // Филологические науки. Вопросы теории и практики. – 2018. – No 3-2 (81). – С. 245–251.

4.Толстой Л. Н. Полное собрание сочинений: в 90-та т. / под общ. ред. В. Г. Черткова. М.: Худож. лит., 1937. – Т. 25. – 914 с. 22

5.Толстой Л. Н. Полное собрание сочинений: в 90-та т. / под общ. ред. В. Г. Черткова. М.: Худож. лит., 1938. – Т. 83. – 638 с. 23

# ИЗУЧЕНИЕ АНГЛИЙСКОГО ЯЗЫКА НА УРОВНЕ РОДНОГО ЯЗЫКА

***Агамамедова Ш.Х.***
***Азербайджанский государственный Педагогический Университет (Шамахинский филиал)***
*aqamammadovashafaq@gmal.com*

***Аннотация:*** Английский язык широко распространен во всем мире. Английский не только официальный язык многих стран, но и известен в деловых встречах, в мировых конференциях, в олимпиадах, в спортивных чемпионатах, в дипломатии, в мировых музыкальных соревнованиях и во многих других отрослях жизни. Владение английским языком расширяет возможности человека повсюду. По этому современному человеку необходимо изучать этот язык. Большинство людей изучают классический или литературный вариант этого языка. А есть люди, которые стараются изучать английский до уровня родного языка. Это побуждает их к его активному изучению. Они часто задают вопрос «можно ли выучить английский язык как родной?» Это возможно ,но сложно. Большую роль в этом играют такие факторы как возраст человека ,возможности и сроки обучения. Всем известно,что дети легче усваивают языки и на это влияют большую роль окружающая их среда.

***Ключевые слова:*** язык, родной язык, английский язык, учитель технологии

При постаянной практике и погружении в языковую среду возможно изучать английский на уровне носителя языка. Все зависит от желания, упорства и качественного обучения.

Английский язык можно изучать разными с пособами:

1.Самостоятельно.
2.С репетитором.
3.На онлайн—курсах.

Самостоятельное изучение самое сложное. Вы должны иметь не только базу знаний, который состоит из грамматики, лексики и словарного запаса, но и самостоятельно искать и изучать речевые обороты, идиомы, улучшить произношение. В этом полезно часто смотреть фильмы, сериалы или передачи, читать книги на английском языке. Книги нужно выбирать объемные и интересные.

Постепенно станет гораздо проще, чем в начале. Слова и грамматика часто повторяются и по этому легко запоминаются. Чтобы произошло полное погружение, читать нужно быстро и часто. Это очень важно для изучения языков. При этом важно обратить внимание на произношение.

Но с этими способами трудно изучать язык на уровне носителя. Потому что никто не исправляет ваши ошибки. По этому лучше начать изучать английский с репетитором, он или она поможет вам правильно и грамотно

составить предложения, исправит ваши ошибки и произношение.С ним вы можете тренировать разговорную речь и это очень важно.

Выбрать нужно хорошего учителя, чтобы он помог вам справиться всеми трудностями.

Современные технологии позволяют вам заниматься с репетиторами онлайн и это очень удобно, потому что вам не приходится терять время добраться до преподавателя. Онлайн курсы - самый быстрый, еффективный и удобный сбособ чтобы изучать язык. Они делают процесс обучения легким и интересным. Но при этом преподователь должен подбирать программу обучения правильно, чтобы она подошла уровню каждого ученика.

Заниматься можно как индивидуально, так и группами. Если вы хотите изучать язык на уровне носителя родного языка, вам бы лучше практиковаться с носителями.Такие уроки помогут вам быстрее научиться особенностям произношения и улучшить разговорную речь.И не нужно бояться делать ошибки. После нескольких занятий вы почуствуете улучшение вашего произношения и речи.

Снимая видео или записывая ваш голос, вы сможете послушать себя со стороны.Такими способами вы сможете легко улучшить свое произношение.

Для того чтобы ваша речь была на уровне родного языка, нужно выучить несколько современных оборотов, слов и идиомов.

Чтобы лучше понимать речь других, нужно много и постоянно слушать записи на английском.При прослушивании аудио материалов, конечно же попадутся слова и фразы, которые вы не знаете, по этому важно просто слушать и слушать, улавливать суть, записывая новые для вас слова, идиомы и сленговые фразы в блокнот.Слушать можно всегда и везде, во время прогулки, дома перед сном, главное быть расслабленным и окружать себя речью носителей.

Писать тоже очень важно в изучении языка.Это непосредственно связано с чтением, по этому чем больше вы читаете, тем лучше пишите. Вы должны уметь писать официальные письма, эссе и сочинения на различные темы, используя правильные предложения. Если ваш уровень английского выше среднего, не волнуйтесь, осталось не так много. Сейчас у вас есть хороший фундамент, а также широкие возможности эффективно использовать изученные. Вам так женужно познакомиться с основными акцентами

английского, чтобы понимать его на слух в реальных жизненных ситуациях. Поищите местные шоу из США, Великобритании Канады, Австралии, Южной Африки и т. д

Во время повседневных дел, например, когда готовите обед или моете посуду, слушайте аудиокниги на английском. Выбирайте художественную литературу, бизнес-книги, учебники, все что хотите. Читайте внимательно и старайтесь понять суть. После этого придумайте вопросы и найдите на них ответы, а потом продолжите разговор на эту тему. Это безусловно повысит ваш уровень владения английским языком.

## Литература

1. Как выучить английский до уровня родного языка. URL: uchis-online.ru
2. Как выучить английский до уровня родного языка. Продвинутый уровень. URL: livexp.com

# ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫНА ӨЙРӘТҮДӘ ИННОВАЦИОН ТЕХНОЛОГИЯЛӘР

***Афзалова Г. А.***
***МБОУ “СОШ №8” г.Октябрский***
***afzalova67@mail.ru***

***Аннотация.*** В системе образования успешно применяются современные технологии – педагогические технологии, основанные на эффективности организации и управления учебным процессом, и педагогические технологии, направленные на активизацию и интенсификацию деятельности учащихся.

***Ключевые слова:*** педагогическая технология, педагогическая техника, учебная деятельность, новые учебники.

Бөтендөнья белем бирү процессының мөхим тармагы – белем бирүдә заманча информацион технологияләр куллану. Соңгы елларда илебезнең мәктәпләрендә күп кенә предметлардан белем бирүдә компьютер техникасы һәм башка информацион технологияләр ешрак кулланыла башлады. Информатизация белем бирү процессына сизелерлек йогынты ясый. Ул белем бирү процессын үтемлерәк итәргә, белемне кабул итү тизлеген арттырырга, зур күләмдәге материалны аңлап, тирәнтен үзләштерергә ярдәм итә. Нәрсә соң ул информацион технология? Информацион технология – компьютер техникасы һәм программа чаралары ярдәмендә мәгълүматны укучыларга әзерләү һәм җиткерү процессы. Белем бирүдә кулланыла торган информацион технологияләр ике төргә бүленә: техник чаралар (компьютер техникасы һәм бәйләнеш чаралары), төрле максатта кулланылган программа чаралары. Әгәр укытучы дәресне оештырганда компьютер кулланырга уйлый икән, ул югарыда әйтелгән чараларның мөмкинчелекләрен һәм куллану тәртибен белеп эш итергә тиеш. Ни өчен туган тел дәресләрендә компьютер техникасы куллану кирәк, информацион технология чаралары кулланып, дәрестә нинди мәсьәләләр чишеп була? Беренчедән, укучыларда туган телне өйрәнүгә кызыксыну уяту. Мәктәптә укытылган башка фәннәр арасында туган тел дәресләренең абруен күтәрүдә, тәҗрибә күрсәткәнчә, компьютер техникасы куллануның да роле зур. Шулай ук шәхес тәрбияләү; фикерләү сәләтен үстерү; эстетик тәрбия бирү; информацион культура тәрбияләү; укытуның сыйфатын күтәрү; предмет-ара бәйләнеш булдыру; укучыларда эзләнү-тикшеренү теләге уятуда информацион технологияләрнең йогынтысы зур.

Хәзерге вакытта дәресләрдә инновацион технологияләр куллану үз эшеңнең нәтиҗәсен күрергә ярдәм итә.

Укучының алга таба үсеше башлангыч сыйныфта алган белемнәргә бәйле. Шуңа күрә башлангыч сыйныфларда белем бирү белән бергә баланы шәхес буларак үстерергә, уку эшчәнлегенең төрләренә өйрәтергә тырышам. Башлангыч сыйныфларга белем биргәндә күрсәтмә әсбаплар зур роль уйный. Бүгенге көндә таблица, рәсем, аудиоязма, видеоязма белән бергә компьютер

программалары, презентацияләр һ.б. кулланам. Мин башлангыч сыйныфларда татар теле һәм әдәбияты  дәресләрендә күбрәк уен технологиясе элементларыннан файдаланырга тырышам. Алар “Уен – табышмак”, “Уен – сәяхәт”, “Тылсымлы капчык”, “Ватык телефон”,“Хәрефләрдән сүзләр төзү”.

Башлангыч сыйныфларда, мин рольле уенны аеруча яратып кулланам. Рольле уенда парлап һәм төркем составында да катнашырга була. Төркем белән эшләгәндә, әкиятләрне үзгәртеп, тулыландырып, өстәмә сораулар ярдәмендә коммуникатив максатка ирешәм. Үземнең эш тәҗрибәмдә мин рольле уеннарга түбәндәге мисалны китерә алам. Мәсәлән, “Теремкәй” әкияте мисалында лексик һәм грамматик материал ныгытыла һәм бу уен дәрестә бик уңышлы файдаланыла.

Шул рәвешле укучылар, бер-берсенә йогынты ясыйлар. Табигый рәвештә, нәрсәдер әйтү, нәрсә турында булса да сорау ихтыяҗы яки әңгәмәдәшеңә җавап бирү теләге туа. Аралашу бик кызыклы бара.

Болардан тыш та төрле уен элементлары кулланырга мөмкин. Бөтен дәресне ситуацияле уенга кормыйча, аның билгеле бер этабында гына да уен элементы кертеп җибәреп була. Мәсәлән, “Туган көнгә чакыру”, “Кибеттә” кебек рольле уеннар бик кызыклы. Аны, гадәттә, шушы темаларга караган лексика һәм репликаларны өйрәнгәндә кулланам. Ул дәресне җанландырып җибәрә. Зуррак сыйныфларда югарыда санап үтелгән бөтен дәресне иңләп ала торган уен формалары кулайрак.

Еш кына үз дәресләремдә мин проблеманы хәл итүнең күмәк эзләү ысулын файдаланам. Хикәяләр буенча фикер алышу процессында барысы да катнаша, барысы да үз фикерләрен әйтәләр. Әлеге ысул теманы өйрәтүне тәмамлаганнан соң материалны үзләштерү нәтиҗәлеген бәяләү өчен уңайлы.

Иҗади үстерелешле укыту технологиясе укучыга иҗади үсәргә ярдәм итә. Төрле темаларга сөйләшү оештырганда, укучыларны, белем дәрәҗәләренә карап, берничә төркемгә бүлеп утыртам. Укучылар алдына проблемалы сорау куела: «Син спорт белән дусмы?» Сөйләшүне төрлечә дәвам итәргә кирәк. Төркемдәге һәр укучы үз фикерен тулысынча, мисаллар белән сөйләп бирә, һәм шулай ук үзбәя куела. Татар телен чит тел буларак өйрәтү процессында уеннардан файдалану укучыны белем алырга дәртләндерә, аларда фән белән кызыксыну уята. Аеруча, грамматик уеннар. Өйрәнелгән темалардан соң үткәрелгән уеннар аеруча нәтиҗәле була. Ул укучыларның сүз байлыгын арттыра, уен белән мавыккан укучы, курку хисен җиңә. Грамматик уеннар шунысы белән әһәмиятле: укытучы уенны башлар алдыннан, «татарча гына сөйләшәбез» дигән таләп куя, һәм ул укучы өчен җаваплы эш булып тора. Дәрестә уйнала торган уеннар берничә төркемгә бүленә: өйрәнелмәгән лексик – грамматик материаллы уеннар; өйрәнелгән лексик – грамматик материалны ныгытырга ярдәм итүче уеннар; граммматик кагыйдәләрне кызыклы формада бирүче уеннар; грамматик формаларны, җөмләдә сүзләр бәйләнешен һәм җөмлә төзү күнекмәләрен камилләштерүгә ярдәм итүче уеннар.татар телен өйрәнүгә кызыксыну уятырлык уеннар бик күп. Мәсәлән: предметларны чагыштыру һәм шуларны рәсемнәргә төшерү; аерым билгеләр буенча сүзләр

табу ( беренче аваз, хәреф һәм иҗек буенча; бирелгән тема буенча; рәсем буенча; соңгы хәреф буенча; синонимнар, антонимнар табу); «Тирәбездә нәрсәләр бар?» уены (әйләнә-тирәдәге мөмкин кадәр күбрәк әйбернең исемен атау); «Кем яхшы күрә?» (рәсемнәрдә сурәтләнгән әйберләрне, аларның билгеләрен, хәрәкәтләрен санау); сүзләрне тергезү (төшеп калган хәрефләрне кую; таралган хәрефләрне тиешле тәртиптә урнаштыру; таралган сүзләрдән җөмләләр төзү; яңа сүз ясау өчен хәрефләр (иҗекләр) өстәү яки алып ташлау); сынамышлар, тизәйткечләр, җырлар, табышмаклар, башваткычлар, мәкаль һәм әйтемнәрне урынлы куллану да татарча сөйләшергә өйрәтүдә зур әһәмияткә ия. Алар укучыларның белемен, осталыгын, иҗади эшчәнлеген үстерә.

Дәресләрдә индивидуаль һәм дифференциаль укытуга аерым роль бирәм. Шул максаттан, рольле уеннар дәресләре кебек иҗади дәресләр нәтиҗәле булып торалар. Рольле уеннар берничә этаптан тора: өйдә яки сыйныфта әзерләнү, сыйныфта уенны оештыру, йомгаклау этаплары. Уенны оештырганда, укытучы берничә факторны истә тотарга тиеш: укучыларның коммуникатив эшчәнлеген активлаштыру; сөйләм эшчәнлеге дәрәҗәсенең төрле булуын истә тотып, балаларга рольләрне дөрес бүлеп бирү; уенның нәтиҗәсе укучыларның хисси халәтенә бәйле булу; укучыларга яхшы таныш булган ситуацияләрне файдалану; үзара ярдәмләшү, телдә актив аралашу мохите булдыру.

Рольле уеннар диалогик сөйләмне үстерүдә бик нәтиҗәле чара булып тора.Әлеге дәресләрнең һәрберсенең үзенчәлекләре бар. Аларның уртак ягы –укучыларда сөйләм эшчәнлегенең һәм сөйләм иҗатының төрле төрләрендә мөстәкыйль уку күнекмәләрен үстерү. Өй эшен мин укучыларның сәләтенә һәм мөмкинлекләренә туры китереп индивидуаль бирергә тырышам. Укучылар өчен кызыклы эш формасының берсе- укыган әсәрләрне сәхнәләштерү, сәхнәләштерелгән тамашалар. Алар сөйләм күнекмәләрен, хәтерне, артистлык сыйфатларын үстерәләр. Татар теленә мәхәббәт һәм кызыксыну уяту өчен музыка, җырлар, шигърият зур мөмкинлекләр бирә. Шулай, балалар нинди дә булса биремне мөстәкыйль үтәгән вакытта мин тыныч татар көйләре кабызам, бу фикер йөртергә ярдәм итә һәм эзләнү эшчәнлегенә кызыксыну формалаштыра.

Укыту һәм тәрбия бирү максатларының берсе – укучыларга заманча компьютер технологияләрен үзләштерергә ярдәм итү, алар ярдәмендә алган белемнәрне киләчәк үзүсеш өчен кулланырга өйрәтү. Бу максатны тормышка ашыру өчен дәресләрдә һәм дәрестән тыш чараларда информацион технологияләр куллану зарури. Дәрестә презентацияләр киң кулланам. Иллюстрацияләрне текст белән бәйләп музыка фонында бирәм. Болай эшләгәндә бала күреп һәм ишетеп кенә калмый, иң әһәмиятлесе анда эмоцияләр барлыкка килә. Ә эмоцияләр, кичерешләр аша бирелгән белем үстерелешле укытуның нигезе булып тора. Дәресләрдә ИКТның төрле формаларын куллану укучыларның белемнәрен тирәнәйтә, күззаллауларын үстерә. Предмет буенча өлгерешләрен арттыра. Мөстәкыйль эшләргә өйрәтә.Үз уңышларын күреп, сөенү, куану хисләрен тудыра.

Мин информацион технологияләрне дәреснең төрле этапларында; укучыларның белем һәм күнекмәләрен тикшергәндә; проектлар методы белән

интеграль дәресләр үткәргәндә кулланам. Татар теле дәресләрендә укучыларга компьютер технологияләре ярдәмендә төрле күнегүләр бирәм, яңа темага керер алдыннан проблемалы ситуацияләр тәгъдим итәм. Әдәби уку дәресләрендә язучы биографиясенең кызыклы фактлары белән таныштырам, читтән торып сәяхәт итү кебек эш төрен кулланам, язучы иҗаты буенча куелган әкият яисә спектакльдән өзекләр күрсәтәм, нәфис сүз осталары язмаларын тыңлатам. Шулай ук дәрестән тыш чараларда; укучыларның игътибарлылык, хәтер, фикерләү кебек конкрет сыйфат һәм мөмкинлекләрен тикшерү, үстерү эшләрен алып барганда; компьютер технологияләрен куллануның уңай нәтиҗәләр бирүен күрдем. Укучылар үзләре дә компьютер программаларын файдаланып, төрле иҗади мөстәкыйль эшләр үтиләр. Мондый төр эшләр укучыны тагын да активлаштыра, белем алуга дәртләндерә һәм мөстәкыйльлек тәрбияли.

Бүгенге көндә мәктәпләрдә татар халкы тарихы бик аз күләмдә укытыла яисә бөтенләй укытылмый. Шуңа күрә татар теле дәресләрендә, коммуникатив һәм тәрбияви максатларны күздә тотып, кызыклы этнографик-тарихи темаларны яктырту укучыларга үз халкының үткәне турында күпмедер күләмдә мәгълүмат биреп, аларда татар тарихын өйрәнүгә мотивация булдыра. Икенчедән, бүгенге көн укучыларында татар халкының гореф-гадәтләре, традицияләре турында күзаллау бик шартлы. Бигрәк тә зур шәһәрләрдә яшәүче балалар өлкән буын вәкилләре – әби-бабаларыннан читтә яши, шуңа күрә аларда татар халкының гасырлар дәвамында формалашкан гореф-гадәтләре турында хәбәрсез булып калуы ихтимал: “Әбиләрегез яшь чакта кулъяулыклар чиккәндер, күргәнегез, сораганыгыз бармы?” - дип сорагач, балалар “без әби белән яшәмибез, ул аерым яши” яки “әби-бабай үлгән, йортлары сатылган инде”, диләр. Гомумән, социомәдәни компетенцияне тел материалы белән бергә үреп, диалогик яки монологик сөйләм итеп Өченчедән, укучыларда татар халкының дөнья цивилизациясенең бер өлеше булуын, аның үз милли киенү рәвеше, күзаллаулары, гореф-гадәтләре, рухи һәм материаль байлыгы барлыгы турында фикер урнаша.

Ә тәрбияви максаты татар милли бизәкләре, татар халкының киенү үзенчәлекләре, гореф-гадәтләре, аш-су осталыгы, кулдан эшләнгән эш кораллары турында мәгълүмат бирү, укучыларда үз халкының гореф-гадәтләренә, этнографик үзенчәлекләренә ихтирам-хөрмәт уяту, горурлык хисе тәрбияләү булган дәресләр комплекслы тәкъдим ителсә, укучыларыбызда үз халкы мәдәнияте турында тулы күзаллау булдырырга мөмкин. Шул рәвешле бүгенге заман укытучысы татар телен һәм әдәбиятын өйрәтү белән беррәттән, укучыларда, ягъни киләчәк буын вәкилләрендә, үз үткәненә, тарихына, мәдәни мирасына ихтирам-хөрмәт тәрбияли, димәк, һәр бала үз-үзен яратырга, әби-бабасын, әти-әнисен хөрмәтләргә өйрәнә.

Мәктәптә кулланыла торган иң отышлы инновацион технологияләрнең берсе электрон дәреслекләр һәм ярдәмлекләр. Үз дәресләремдә Хайдарова Р.З. Галиева Н.Г җитәкчелегендә чыккан “Күңелле татар теле” һәм күп кенә

электрон дәресләкләрне, Фәтхуллова К.С., Юсупова А.Ш., Денмөхәммәтова Э.Н. авторлыгында чыккан “Татарча сөйләшәбез, укыйбыз, язабыз” ярдәмлекләрен кулланам. Әлеге дәреслекләр һәм ярдәмлекләрдәге материаллар укучыда тел өйрәнүгә кызыксыну тудыра. Аларның зәвыклы бизәлеше, биремнәр һәм текстларның сәнгатьчә бизәлеше, бизәлештә төсләрне урынлы куллану, тәкъдим ителгән текстларның һәм өзекләрнең балалар өчен кызыклы булуы, яшь үзенчәлекләренә туры килүе, биремнәр һәм сорауларның укучы башкарып чыга алырлык катлаулылыкта булуы, аудирование өлешләре булу бик тә яхшы.

Алда язылганнардан нәтиҗә ясап, шуны әйтергә була: педагогика фәнендә укыту-тәрбия процессы сыйфатын үстерергә булышлык итүче технологияләр шактый. Укытучының бурычы – яңалыклар агымында югалып калмыйча, дөрес юнәлеш алу, укытучының һәр этабы өчен уку материалын аңлатуның иң уңышлы вариантын табу.

**Литература**


1. Агапова. Н. В. Перспективы развития новых технологий обучения. – М.: ТК Велби, 2005. – 247 с.
2. Харисов Ф.Ф. Научные основы начального обучения татарскому языку как неродному. – Казань: Тарих, 2000. – 479 с.
3. Харисов Ф.Ф. Татар телен чит тел буларак өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре . – Казан: Мәгариф, 2002. –367 б.
4. Хәйдәрова Р.З., Әхмәтҗәнова Г.М. Татар телен һәм әдәбиятын укытуда яңа технологияләр. – Яр Чаллы, 2011. – 61 б.

# УКУЧЫЛАРГА ТАТАР ТЕЛЕ ЛЕКСИКАСЫН УКЫТУ ЫСУЛЛАРЫ

***Әүхәдеева А. В.***
***Шәмәрдән "Үсеш" лицее***
***ms.avhadeeva@mail.ru***

***Аннотация.*** В данной статье дается возможность учащимся самим ставить цель творения на уроке и одновременно готовить себя к самостоятельной жизни. Обучение родному языку стало важным вопросом для современной школы. Учителя, чтобы развивать язык используют разные дидактические материалы и технологии. Дети к эти методам относятся с интересом, поэтому он помогает изучить родной язык. На уроках родного языка, детям предоставляется свободный выбор. Они сами выбирают трудные слова и стараются найти смысл этих слов. Также используется разные игры, тексты, словари.

***Ключевые слова:*** родной язык, учителя, дидактические материалы, смысл слов, словари, тексты, игры.

Телне өйрәнү, беренче чиратта, сүздән башлана. Сүзнең табигате, аның кулланылыш мөмкинлеге һәм даирәсе, яшәеше, мәгънә тирәнлеге аша без халыкның мәдәни-рухи мирасын барлыйбыз, милләтнең үсеш кыйбласын, башка халык, дәүләтләр белән бәйләнешен ачыклыйбыз. Сүз ул аралашу, аңлашу чарасы гына булып калмыйча, милләтнең дөньяны аңлавын, кабул итүен күрсәтә торган фактор да. Тел, җәмгыять үсеше дәвамында сүзләрнең мәгънәләрендә халыкның көн итеш үзенчәлекләре сакланып кала, милли яшәеш үзенчәлекләрен алдагы буыннарга җиткерү вазифасын да сүз башкара. Шул сәбәпле телнең сүзлек байлыгын тирәнтен өйрәнү милләтнең үткән тарихын, рухи кыйммәтләрен ачыклауга да ярдәм итә.

Телнең сүзлек байлыгын без лексика дип, ә шул байлыкны өйрәнә торган тел тармагын лексикология (гр. lexikos - сүз, logos – өйрәнү) дип атыйбыз. Лексикология фәне сүзне төрле яклап өйрәнүне үзенең максаты итеп карый. Беренче чиратта, лексикология фәне кысаларында, сүз мәгънәсе, аның типлары, сүзлек составының катламнары, сүзләрнең килеп чыгышы, кулланылыш үзенчәлекләре, телнең лексик составы баю, тулылану юллары тикшерелә. Телнең сүзлек байлыгы даими рәвештә тулыланып, үсеш-үзгәреш кичереп яши. Лингвистика фәненең бер генә тармагы да лексикология кебек җәмгыять тәэсиренә тиз бирешеп, үзгәрешкә дучар ителми. Сүзнең фонетик тышчасы, төзелеше үзгәрү гасырлар дәвамында бара торган гамәлләрдән санала, ә сүзлек составы исә унбиш-егерме ел эчендә шактый үзгәрергә мөмкин. Бу, беренче чиратта, телгә җәмгыять, иҗтимагый-сәяси, мәдәни тормыш тәэсире белән аңлатыла. Халык яшәешендә булган һәрбер яңалык, иң беренчеләрдән булып, сүзлек составында чагылыш таба, аның алга таба үсеш

юнәлешләрен билгели. Заман таләбе телнең сүзлек байлыгына да яңача караш таләп итә, аны өйрәнүнең яңа юлларын билгели.

Лексикология фәне чагыштырмача яшь тармаклардан саналса да (тел гыйлеме бүлекләреннән иң соңгылардан булып XX гасыр башларында тәмам формалашып җитә), аның кеше, җәмгыять тормышында гаять әһәмиятле урын биләве антик чорда ук фәлсәфәчеләр тарафыннан сүзгә, аның мәгънәсенә игътибар булдыруга китерә. Соңрак сүзнең нәфислегенә, сурәт ясау мөмкинлегенә игътибар бирелә башлый. Чит халыклар белән аралашу кысалары киңәю сүзлекләр төзү ихтыяҗын китереп чыгара. Шул рәвешле лексикология фәненең аерым юнәлешләре, күпкә алдан барлыкка килеп, әлеге фәнгә нигез салалар. Татар лексикологиясе беренче башлангычларны М.Кашгарыйның өч бүлектән торган "Диване лөгат-эт төрк" сүзлеге , XVII-XX гасыр башларында төзелгән сүзлекләрдән алып, фән буларак, XX гасыр урталарында зур үсеш ала.

Хәзерге көндә лексика фәне ничек өйрәнелә? Укучыларның белемнәре ничек максатка ирешелә?

Татар теле лексикасын үзләштерү башка чит телләрдәге лексиканы үзләштерү кебек үк күнегүләргә таянып килә. Ләкин рус балаларына татар лексикасын өйрәткәндә телебезнең үзенчәлекләрен дә истә тотарга кирәк. Татар теленең сүзлек составын үзләштергәндә очрый торган кыенлыклар байтак. Боларга:

-татар теленең лексик байлыгы гаять зур: аңарда бик күп тарихи сүзләр, архаизм, кайтарылган сүзләр бик күп очрый;

-татар телендә төп сингармонизм законына буйсынмаган гарәп һәм фарсы алынмалары да күп;

-татар телендә сүзләрнең күчерелмә мәгънәләре шактый;

-татар сүзе белән рус сүзе мәгънәләре арасында зур аермалар бар.

Әмма шул ук вакытта татар теленә өйрәнүдә укучылар өчен күпмедер җиңел моментларны да күрсәтергә мөмкин. Беренчедән, һәр ике телдә булган уртак сүзләр шактый. Болар төрки телләрдән рус теленә күп гасырлар элек кергән алынмалар: *башмак, башковитый, балык, хозяин, казначей, лошадь, каурый, караковый, карий, саврасый, игреневый, товар, товарищ, тамга, арба, тушканчик, арык, алтын, деньги.* Икенчедән, гасырлар буе янәшә яшәү нәтиҗәсендә татарлар да рус теленнән йөзләрчә сүзләр кабул иткәннәр: *өстәл, ыстанса, бүрәнә, сумала, эскәтер, эскерт.* Өченчедән, рус теле совет чорында халыкара аралашу теле буларак бөтен җирдә яшәүче халыклар телләренә күп кенә яңа сүзләр керде: *колхоз, космос, ракета.* Дүртенчедән, рус теле аша Европа телләреннән дә меңләгән сүзләр кергән һәм кереп тора: *армия, грамматика, король, император, химия, физика, кафедра.* Хәзерге чорда да андый сүзләр шактый: *компьютер, лизинг, бейсбол, маркетинг, менеджер, принтер.* Бишенчедән, татар телендәге сүзләрнең күпчелеген бер тамырдан ясалган сүзләр тәшкил итә. Мәсәлән: *баш, башлык, башмак, башлану, башта, башлы, башка-баш, башлангыч, башак* кебек сүзләрнең мәгънәләрендәге

уртаклыкны эзләп табып була. Бу – *баш* сүзе, ул һәрвакыт *голова, начало* мәгънәләре белән бәйле.

Димәк, рус укучысы *баш* дигән сүзне истә калдырса, шул тамырны тыңлаган, күргән, укыган, язган саен, ул аның мәгънәсен аңлый ала. Бу кагыйдә түгел, һәм монда очрак чыганаклар да табып була. Мәсәлән: *аш, ашханә, аш-су, ашый,* ләкин *ашыга.* Һәм бу күренешкә сак булып кына таянырга мөмкин.

Яңа сүзләрне тәъдим итү мәсьәләсе һәм кабатлау проблемалары андый ук актуаль түгел хәзерге көндә. Ләкин ул өлкәләр дә лексиканы өйрәнгәндә киң карала. Нинди дидактик материаллар кулланырга була? Шул материалларны карап китәрбез.

**Сүзләрнең мәгънәсен билгеләү**

*Сүзләрне лексик-семантик төркемнәргә (предмет, билге, процесс, халәт, күләм, мөнәсәбәт, эмоциональлек мәгънәләрен белдерү) аерыгыз.*

Бирелгән җөмләләрдән туры һәм күчерелмә мәгънәдә бирелгән сүзләрне язып алырга.

*1.Вакыт җилләре Шәвәли абзаңның да каралты-кураларына эзен салмый калмады. (Г.Ахунов) 2. Нәфисә бераз дулкынлана, үзен җидееллыкны тәмамлар алдыннан имтихан биргәндәге кебегрәк хис итә иде. (Г.Бәширов) 3.Таулар итәгеннән диңгезгә карап һәм куе яшеллеккә күмелеп утырган ак сарайлар шәһәре Сочига мин бүген көннең икенче яртысында килеп төшкән идем. (Ә.Еники)*

**Синонимнар**

***Җөмләләрдә билгеләнгән сүзләрне синонимнар белән үзгәртеп, күчереп яз.***

1. Җырчы кошлар **киң тугай** өстендә **нәни** канатларын җелпеп сайрыйлар.
2. Алар **чиксез** зур **шатлыкларын** белдерәләр.
3.Күл **тирәсе зифа** таллар, **сылу** камышлар белән уралган.

**Антонимнар**

*Җөмләләрдә антонимнарны язып бетер.*

1. Чулман зур елга, ә Ык … .
2. Җәен көннәр озын, ә кышын … .
3. Көньякта җылы, ә төньякта … .
4. Ак сыер торып китә, … сыер ятып кала.

**Омонимнар**

*1. Түбәндәге сүзләрнең омонимнарын табыгыз, мисаллар өстендә аңлатыгыз.*

Салам, кисәк, йөзлек, җыен, бәпкә, уң, чалу, тезмә, чык, ат, чап.

*2. Омонимнар белән җөмләләр төзегез.*

Басма – басма, без – без, өй – өй, күркәм – күркәм, ат – ат

**Неологизмнар**

*Мисаллардан неологизмнарны табып языгыз.*

1. Демократмы, партократмы диеп,
   Башын вата безнең агайне. (Б.Рәхимова)
2. Республикада җылылык бирү нокталары 80 процентка гына әзер.

**Искергән сүзләр**

*Җөмләләрдән искергән сүзләрне табыгыз.*

1. Тарханны, өлкән бичәне котлау өчен беренче булып Куян ыруыннан Котлуг бәк керде. (Н. Фәттах) 2. Бу аларның ымнары – алдан килешеп куйган сүзләре иде. (Н. Фәттах)

**Фразеологизмнар**

*Җөмләләрдә фразеологизмнарны бер сүз белән алмаштырып яз.*

1. Әбинең шәһәр тормышына **исе китми.**
2. Ул авызына **су капкан.**
3. Авылда әбинең **башы күккә тияр** иде.
4. Малай **ике куян артыннан куа.**
5. Әтинең моңа **хәтере калды.**
6. Әбигә **канатлар үсте.**

**Гарәп-фарсы алынмалары**

*А) Җөмләләрдән гарәп-фарсы алынмаларын табып язып алыгыз.*

1. Безнең сөннәтче бабай Сәлман фарси хәзрәтләреннән мирас тарихы берлән сөннәтчелекне алса да, Әбүгалисина хәзрәтләре тарафыннан тыйб гыйлеме, гыйльме симия вә гыйльме кимиягә иҗазәт алмаганга, әлбәттә, тыйб гыйльменең бу кадәр нечкәлекләрен белми иде. (Г. Исхакый) 2.Бүлмә эссе күк, бүлмә тыгыз күк тоела; тәрәзәгә китереп бәрә торган кар тавышы да Әхмәтнең рухында тагын бер яра ача иде. (Г. Газиз.) 3.Кечкенә генә тәрәзәле караңгы гына мәчет үзенең сәләмә намазлыклары белән бик фәкыйрь төсле күренсә дә, яшь мулланың сузып кына, яхшы гына кыярәт белән имам булуы шактый күңелгә тулды. (Г. Исхакый)

*Б) Гарәп-фарсы алынмаларына үзегезнең мисалларны искә төшереп языгыз:*

-парлы ясалышлы:

-кушма ясалышлы:

**Алынма сүзләр**

*А) Җөмләләрдә нинди рус алынмалары кулланылган?*

1. Буразнадан – завод цехларына, Яхшы түгел юлда соңлавы. (Г.Хуҗин) 2. Бүрәнәләрен инде китергәннәр, рәшәткә янына таслап өйгәннәр, форсат чыкканчы гына көтәләр, эһ дигәнче бурап күтәреп мүкләп куячаклар. (Т. Миңнуллин) 3. Бер көнне колхозның вак-төяк эшләрендә йөрүче кызларга бригадир яңа нәрәт кушты. (Н. Гыйматдинова) 4) Тик Николай вакыт-вакыт кына руль рычагын тарткалап, тракторны буразна сызыгына төшергәләп тора. (Н. Хәлитов) 5. … Ятам, аста арыш саламы. (С. Хәким) 6. Завхоз иртәгә эленәчәк расписаниене группа бригадирларына күрсәтте. (Х. Сарьян)

*Б) Түбәндәге җөмләләрдән алынмаларны табып, төркемнәргә (гарәп, фарсы, рус) бүлеп языгыз.*

*— Тугызынчы тәүлектә температураң кырыкка күтәрелгән. Төрмә врачы сине, карцердан алып, больницага салырга кушкан. Әмма тикшерүче, ул гаебен өстенә алмады дип, рөхсәт бирмәгән… Менә ни өчен безнең камерада син, Ибраһим, — диде Имәнкулов.* ( И.Сәләхов)

Лексикология фәне тел гыйлеменең башка тармаклары белән дә тыгыз бәйләнештә яши. Мондый бәйләнешләрнең асылы сүзне төрле яктан өйрәнүгә бәйле, чөнки теләсә кайсы телдә сүз төп урынны алып тора. Телнең төп берәмлекләре арасында ул – мөстәкыйль яшәешкә ия бердәнбер берәмлек. Сөйләмдә фразалар, җөмләләр ярдәмендә аралашу барса да, аларның барысы да сүз ярдәмендә төзелә. Морфема һәм фонемалар исә – сүз төзи торган берәмлекләр, ләкин алар сөйләм агышында мөстәкыйль формада яшәмиләр.

Шулай итеп, сүз телнең һәр ярусында теге яки бу формада яшәеш таба. Ә аның дөрес, урынлы кулланылышы укучы балаларның танып белү, белем, кызыксынучанлык, сүз байлыгы, сүз мәгънәләрен аңлау дәрәҗәсеннән тора.

Укучы балалар татар теленең лексикологиясен үз сөйләмнәрендә кулланса лар, әйтергә теләгән фикер аңлаешлы, тыңлап торырга матур, яңгырашы ачык, саф һәм нәфис була. Сөйләшә һәм сөйли белү укучы шәхесе формалашуда мөһим роль уйный. Татар теленең лексикологик байлыгын куллана белү телне үстерүгә, буыннарга тапшыруга, телне баетуга ярдәм итә, татар теленә, аның килеп чыгышы тарихына кызыксыну уята һәм телне саклап калырга ярдәм итә.

Әйдәгез, телебезне саклыйк, баетыйк, укучыларның белем һәм тәрбия ягыннан булган күнекмәләрне үстерик. Шул чакта гына телебез, мәдәниятебез мәңге сакланыр. Телебез байлыгы – милләтебез хәзинәсе.

**Әдәбият**

1. Әхәтов Г.Х. Хәзерге татар теленең лексикологиясе. – Казан: Тат. Кит. Нәшр., 2021. – 250 б.

2.Галиуллина Г.Р. Татар теле. Лексикология: таблицалар, схемалар, анализ үрнәкләре, күнегүләр, сүзлекчә. – Казан: Мәгариф, 2007. – 95 б.

3. Шәкүрова М.М., Юсупов А.Ф., Хөснетдинов Д.Х. Татар урта гомуми белем бирү оешмаларында татар телен укыту методикасы. – Казан: Казан университеты нәшрияты, 2015. – 110 б.

4. Шәмсетдинова Р.Р. Татар теле: Күнегүләр. Анализ үрнәкләре. Тестлар. − Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2007. – 191 б.

# ОЛИМПИАДАДА ҖИҢҮЧЕЛӘРНЕ НИЧЕК ӘЗЕРЛӘРГӘ?

***Әһлетдинова Л.Ф.***
***Казан шәһәре Татар телендә белем бирүче 149 лицей***
*Laf.74@mail.ru*

***Аннотация.*** Педагог, чьи ученики долгие годы были победителями республиканских олимпиад, делится своим опытом работы по подготовке учащихся к предметным олимпиадам по родной (татарской) литературе.
***Төп сүзләр:*** программа, татар теле, әдәбият, олимпиада, әзерлек, сәләт

Сәләтле балалар һәр мәктәптә дә бар. Без аларны һәрвакыт игътибар үзәгендә тотабыз һәм аларның бу сыйфатларын тагын да үстерергә тырышабыз. Сәләтле балалар белән эшләүнең төп максаты: һәр укучының сәләтен, иҗади башлангычын үстерү. Мондый укучылар белән эшләгәндә еш кына үзебезгә дә эзләнергә, яңа мөмкинлекләрдән файдаланырга туры килә.

Олимпиадага әзерлек укытучыдан һәм укучыдан күп көч, түземлелек сорый. Бертуктаусыз эзләнергә, укырга, тел һәм әдәбият яңалыклары белән танышып барырга кирәк. Гадәтилектән алга таба камилләшү өчен укучы күңеленә орлык дөрес сала белергә, аның тернәкләнүен биш күзләп күзәтү мөһим. Район олимпиадаларына әзерләнү барышында укучылар алдына түбәндәге максатлар куям: 1.Программа материалын бик яхшы белү; 2.Өстәмә чыганаклардан мәгълүмат алу; 3. Бөтен төр анализ үрнәкләрен белү; 4. Халкыбызның үткәне, бүгенгесе турындагы материалларны өйрәнү, вакытлы матбугат белән кызыксыну, радио, телевидениедән татарча тапшыруларны карап бару; 5. Фикерләү сәләтен үстерү; 6.Мөстәкыйль эшләргә өйрәнү.

Татар әдәбиятыннан олимпиадага әзерләнү өчен укучыларыма һәм үземә ярдәмлек әзерләдем. Ул “Олимпиада үрләренә – баскычлап” дип атала. Ул түбәндәге эчтәлектән гыйбәрәт: 1. Әдәбияттан минимум; 2.Чорга характеристика; 3.Әдәбиятны баскычлап кабатлау; 4.Әдәбият теориясе; 5.Чор әдипләре; 6.Әсәрләрнең эчтәлеге, кыскача характеристика, белемнәрне тикшерү өчен сораулар, тестлар; 7.Анализ үрнәкләре.

Хәзер кыскача бүлекләргә тукталып үтәм. Алдагы уку елында олимпиадага кирәсе укучы белән әзерлекне ел ахырында башлыйм. Җәйге каникулга укыласы әсәрләрнең исемлеген биреп, кыскача эчтәлек белән таныштырып кызыксындырам. Уку елы башында укучы әсәрләрне укып бетереп килә. Әзерлек чорларга бүленештән, һәм чор әдәбиятына характеристика бирүдән башлана. Чорның үзенчәлеге, бу чорда күтәрелгән темалар һәр әдәби төрдә аерым карала. Бу периодның өстенлек иткән жанрлары, уңышлы әсәрләре санала.

Түбән классларда өйрәнелгән әсәрләр дә читтә калмый. Аларны аерым таблицага урнаштырып искә төшерелә. Әсәрләрне хронологик тәртиптә кабатлыйбыз. Теге яки бу язучы иҗатын кабатлаганда, аның программада каралган әсәрләренә анализ ясап, иҗаты турында гомуми фикергә киләбез һәм үзебезнең фикерне башкаларныкы белән чагыштырабыз. Дәреслекләрне

караганда, әсәрнең авторына, жанрына, язылу вакытына, төп, ярдәмче геройларына аерым игътибар бирелә.

Әдәбият теориясе укучыларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып өйрәнелә. Урта звенода образ, тема, проблема; югары классларда иҗат юнәлешләре, әдәби алымнар һ.б.шундый төшенчәләргә аңлатмаларны гади тел белән кат-кат шәрехлибез, көнкүреш белән бәйләп карыйбыз. Катлаулы материал, терминнарны үзләштерүдә еш кына ассоциатив бәйләнешкә мөрәҗәгать итәм.

Бөтен әдәби төргә анализ үрнәкләрен бирү – укучыны мөстәкыйль фикер йөртү алымы. Шул үрнәкләр ярдәмендә укучылар таныш булмаган әсәрләргә дә ирекле анализ ясарга өйрәнәләр. Мәктәп программасыннан тыш укучылар татар дөньясы, андагы яңалыклар белән һәрдаим танышып барырга тиеш. Ә алдагы елларның олимпиада биремнәре укучыларның белемнәрен системага салырга, җавапларны дөрес, төгәл билгеләргә ярдәм итә.

Сәләтле балалар белән тиешле эш оештыру укытучыдан белем бирү эчтәлеген яңартуны, укыту методларын камилләштерүне, яхшыртуны, иҗади эзләнүне, һөнәри осталыкны үстерүне таләп итә.

Олимпиадада җиңү яулау ул бер яклы гына, бер укытучы яки укучы тырышлыгы белән генә ирешелә торган үр түгел. Бу укытучыдан да, укучыдан да байтак тырышлык таләп итә. Ел саен бәйгегә укучы әзерләү укытучы өчен дә зур файда. Безнең өчен олимпиада үзмаксат түгел, ә төпле белем бирүнең бер юнәлеше. Бары тик эш дәвамлы булганда гына нәтиҗәсе була. Нәтиҗәсе – укучыларыбызның елдан-ел яулаган уңышлары.

# ЭФФЕКТИВНОСТЬ МУЛЬТИМЕДИЙНЫХ СРЕДСТВ В ОБРАЗОВАТЕЛЬНОМ ПРОЦЕССЕ СРЕДНЕЙ ШКОЛЫ

***Болгарова А.Р.***
***Казанский федеральный университет***
***alinabolgarova15@mail.ru***

***Аннотация.*** В статье предлагаются формы использования мультимедийных средств для практического овладение школьниками навыков и умений речевого поведения на русском языке.

***Ключевые слова***: русский язык, мультимедия, речь, учебный процесс

Проблема использования новых технологий требует системного анализа и дидактического и методического обоснования. Ввиду этого перейдем к рассмотрению подтверждению эффекта дидактического потенциала мультимедийных технологий в образовательном процессе средней школы.

Общая стратегия выдвигает требование развития иноязычной коммуникативной компетентности [Абдиева: 6]. Она предполагает практическое овладение школьниками навыками и умениями речи на уровне, достаточном для осуществления иноязычного общения в типичных ситуациях повседневной деятельности.

Иноязычная подготовка учащихся – это ее практическая организация с учетом особенностей той деятельности, которую школьник может выполнять в будущем. В этом контексте мы рассматриваем общую неспециальную иноязычную подготовку школьников как организацию процесса обучения, включающую такой набор тем и ситуаций, позволяющий максимально приблизить учебную деятельность учащихся по цели, форме и средствам ее выполнения к реальным условиям повседневной коммуникации. Общая сфера общения предполагает темы и ситуации, так или иначе связанные с повседневной деятельностью коммуникантов. Отметим, что тема общения – это предмет обсуждения. В рамках тем общения выделяют ситуации общения, рассматриваемые как совокупность обстоятельств, при которых происходит реализация общения. Программа по иностранному языку для учащихся школ определяет следующие основные тематические блоки: «Школа», «Путешествия», «Пища», «Город», «Человек» и так далее. В этой связи, считаем, что изучение общих тем ориентирует на развитие практических навыков и умений общения в повседневных ситуациях.

Такое практическое направление тем и ситуаций придает учебно-познавательной деятельности учащихся мотивированный характер, поскольку их изучение обеспечивает познание школьниками особенностей их будущих коммуникаций, возможных трудностей, с которыми им придется сталкиваться, рассмотрение путей их преодоления. Это требует проявления умений оценивать и регулировать свою деятельность, активизирует развитие личностно значимых

качеств и формирует положительное отношение у учащихся к изучению иностранного языка.

Логика наших дальнейших рассуждений приближает к определению вопроса о принципах использования мультимедийных средств обучения в процессе обучения школьников иностранному языку. Принципы обучения представляют собой наиболее общие правила. Актуально для нашего исследования является мнение В. Р. Чеботаревой о том, что принципы не существуют отдельно, а образуют систему положений, на основе которых осуществляется процесс обучения. Они синергетически определяют ход образовательного процесса.

Изучение современных исследований свидетельствует, что в настоящее время нет пока единой классификации принципов обучения. Одним из подходов к их определению является позиция (Л. С. Суворовой, Н. Г. Помазан, М. В. Бирюковой), что систему принципов использования мультимедийных средств в процессе обучения школьников иностранному языку составляет совокупность дидактических, лингводидактических, психологических и методических принципов.

В традиционной дидактике общепринятыми считаются так называемые классические принципы: наглядности, доступности, сознания и активности, систематичности и последовательности, крепости, научности, связи теории с практикой [Суворова: 32]. В то же время, можно выделяются принципы в конкретных условиях обучения. Например, в обучении иностранному языку существует принцип коммуникативности [Суворова: 34]. В мотивационно-побудительной сфере значим мотивационный фактор, и соответственно – мотивационный принцип обучения [Суворова: 37].

Резюмируя вышесказанное, отметим, что система принципов открыта и допускает включение новых и переосмысления уже существующих. С учетом этого считаем логичным исследовать и уточнить систему принципов в контексте научной проблематики нашей работы.

Учитывая вышесказанное, обобщим, что в литературе выделяют следующие принципы использования мультимедийных средств обучения в процессе обучения школьников иностранному языку [Горохова: 38]:

– принцип наглядности;

– принцип положительной эмоциональности;

– принцип соответствия потребностям общества;

– принцип учета интересов и профессиональных потребностей учащихся;

– принцип моделирования деятельности учащихся;

– принцип коммуникативного направленности обучения иностранному языку;

– принцип комплексного использования мультимедийных средств обучения;

– принцип соблюдения эргономических норм.

Итак, уточненные нами принципы использования мультимедийных средств обучения в процессе обучения школьников иностранному языку,

обусловленные тенденциями развития системы образования, служат теоретической основой для организации учебно-познавательной деятельности школьников с помощью мультимедийных технологий. В то же время их внедрение в учебный процесс, ориентированное на формирование знаний и умений школьников, требует моделирования и технологизации этого процесса в условиях школы.

Внедрение мультимедийных средств обучения в процесс обучения школьников иностранному языку при условии соблюдения очерченных принципов, как правило приводит на практике к эффективным результатам. Поэтому мультимедийные средства обучения хорошо зарекомендовали себя в разных предметных областях, в том числе, как показал анализ литературы, при обучении иностранным языкам. Мультимедийные средства обучения были успешно внедрены в процесс обучения немецкому языку, французскому языку, английскому языку в школе. При этом исследователями получены экспериментальные данные, подтверждающие эффективность внедрения мультимедийных средств обучения в процесс обучения школьников иностранному языку.

4. Учителя следят за тем, чтобы уроки были взаимосвязаны и скоординированы с поставленными целями, а также поддерживали мотивацию к обучению.
5. Учителя должны поощрять самокоррекцию, допускать персонализированный подход.
6. Учителя должны развивать деятельность обучающихся, которая позволит им обнаруживать формы языка.
7. Должен быть задействован весь язык (аудирование, говорение, чтение и письмо).
8. Оценка обучающихся проводится продуктивно и для достижения цели; Обучающиеся должны иметь возможность измерить свой собственный успех и прогресс.

Эксперименты с обучением говорению, основанном на задачах были проведены в ряде стран, показывая положительные результаты за счет высокой интерактивности.

С. Обри провел экспериментальное обучение с использованием TBL в группе японских студентов первого курса крупного частного университета, специализирующиеся в области теологии, экономики, социологии и бизнеса. Это очное исследование длилось 11 недель. Исследование проводилось в два этапа: начальное выполнение задания и повторное выполнение задания. На каждом этапе еженедельно в течение пяти недель выполнялось устное парное задание. Устные задания в этом исследовании содержали двусторонний обмен информацией, за которым следовал компонент принятия решений. Студенты генерировали контент с помощью предварительного исследовательского задания, в ходе которого они собирали информацию, которая позже использовалась во время выполнения задания. Задания выполнялись во время запланированных занятий, и на выполнение каждого задания студентам давалось 25 минут. Все задания записывались на аудио. Во время выполнения

заданий учащиеся делали пометки на листе заданий, который помогал им выполнять задание. Результаты подтверждают, что интерактивные условия обучения TBL являются благоприятными, что выражалось в больших объемах пройденного материала и в более деятельных языковых дискуссиях, которые приводили к изучению языка [3: 288].

Схожее исследование проводили Н. Афифа и Т. Девана в четвертом семестре программы обучения английскому языку Университета Батураджи. Они отмечают, что произошло значительное улучшение разговорной речи студентов на основе обучения при помощи TBL на английском языке. Большинство студентов дают положительные отзывы об использовании проблемного обучения. Студенты были полностью согласны с тем, что обучение, основанное на задачах, помогает им получать удовольствие от изучения английского языка, а также большинство студентов согласны с тем, что занятия, основанные на задачах, являются хорошим способом улучшить словарный запас английского языка. После использования обучения, основанного на задачах, при обучении говорению учащиеся получают более высокие баллы, а также лучше говорят, особенно при изучении английского языка, они используют различные виды словарного запаса и получают удовольствие от изучения говорения [1: 135].

TBL применялся в обучении студентов Языкового центра Национального университета Чимборасо в Эквадоре. Основная цель исследовательской работы заключалась в том, чтобы определить влияние подхода к обучению, основанного на задачах, на улучшение разговорных способностей в английском языке. Чтобы определить эффективность подхода были проведены предварительное и итоговое тестирования на основе кембриджского экзамена KET. Было разработано пособие для учителя, которое использовалось на занятиях. Конструкция пособия для учителя была составлена с использованием различных типов заданий, таких как индивидуальные, групповые, открытые, закрытые и информационные. задания на пробелы, принимая во внимание мотивацию и трудности, которые каждое задание подразумевает в улучшении навыков разговорной речи учащихся. Результаты показывают, что подход к обучению, основанный на задачах, эффективно оказал положительное влияние на развитие устной речи учащихся, что улучшило их способность говорить.

На основании вышеизложенного материала мы приходим к выводу, что обучение, основанное на задачах, улучшает разговорные навыки обучающихся английскому языку за счет большей интерактивности процесса. После обучения на основе TBL учащиеся получают более высокие баллы, а также лучше говорят, они демонстрируют больший словарный запас и получают удовольствие от говорения. Обучающиеся согласны с тем, что обучение, основанное на задачах, помогает им получать удовольствие от изучения английского языка, а также большинство из них согласны с тем, что занятия, основанные TBL, являются хорошим способом улучшить словарный запас английского языка. Все задания были разработаны в мотивационной и увлекательной форме, чтобы способствовать устному взаимодействию

учащихся. Обучение на основе TBL является перспективной методикой, которую, с учетом реалий современного мира, следует рассматривать к применению в средней и высшей школе.

**Литература**

1. Afifah N, Devana T. Speaking skill through task based learning in English foreign language classroom // Journal of English Language Teaching Fakultas Pendidikan Bahasa & Seni Prodi Pendidikan Bahasa Inggris IKIP. – 2020. – Dec 28;7(2). – P.135-144.

2. Aubrey S. The impact of intra-cultural and inter-cultural task repetition on interaction // In M. Bygate (ed.) Learning Language through Task Repetition. –). Amsterdam: John Benjamins, 2018 – P. 117–142.

3. Aubrey S. The Role of Task-Based Interaction in Perceived Language Learning in a Japanese EFL Classroom // Using Tasks in Second Language Teaching: Practice in Diverse Contexts. – 2020. – Jul 7. – P. 281-306.

4. Guerrero B. R., Fray L. F., Fray J. I., Valle V. V. Task-Based Learning Approach to enhance oral production in university settings // Dominio de las Ciencias. – 2020. –6(2). – P. 554-586.

5. Hadley P. A., Rispoli M., Holt J. K., Papastratakos T., Hsu, N., Kubalanza M., McKenna, M. M. Input subject diversity enhances early grammatical growth: evidence from a parent-implemented intervention // Language Learning and Development. – 2017. – 13(1). – P. 54–79.

6. Huttenlocher J., Waterfall H., Vasilyeva M., Vevea J., Hedges L. V. Sources of Variability in Children’s Language Growth // Cognitive Psychology. – 2010. – 61. – P. 343-365.

7. Leong L.-M., & Ahmadi, S. An Analysis of Factors Influencing Learners’ English Speaking Skill // International Journal of Research in English Education. – 2016. – URL: http://ijreeonline.com/article-1-38-en.pdf (дата обращения 20.01.2024)

8. Subekti A. S. Alleviating anxiety, boosting confidence: A proposed model of Willis’ Task-Based Learning // Journal of English Language Teaching and Linguistics. – 2020. – Apr 26;5(1) – P. 131-144.

# ӘМИРХАН ЕНИКИНЕҢ ТУГАН ТЕЛНЕ УКЫТУГА МӨНӘСӘБӘТЛЕ КАРАШЛАРЫ

***Гайнуллина Г.Р.***
***Казан федераль университеты***
***gulfiarasllevna@mail.ru***

***Аннотация.*** Татар әдәбияты классигы Әмирхан Еникинең публицистик язмаларында милли әдәбиятның киләчәге, урта мәктәптә әдәбиятны укыту, туган телдә белем бирү мәсьәләләре хакында фикерләр еш яңгырап тора. Мәкаләдә әдипнең татар мәгарифенә мөнәсәбәтле “Татар баласына урысча белмәү куркынычы янамый” (1998) мәкаләсендә урын алган фикер-карашлары җиткерелә.

***Төп төшенчәләр:*** милли мәгариф, Ә.Еники, туган телне укыту методикасы

Татар әдәбиятының йөзек кашы, язучы, публицист Әмирхан Еники (1909-2000) мирасының әһәмияте иң беренче чиратта милли нигезләргә кайту дәвере әдәбиятын формалаштыру, “язучылар иҗатында дәвам итәчәк авангард эзләнүләрнең чишмә башы булу, милли әдәбиятны яңа сыйфат үзгәрешенә китерү” [2: 157] буларак билгеләнә.

Әдипнең публицистик язмаларында милли әдәбиятның киләчәге, урта мәктәптә әдәбиятны укыту, туган телдә белем бирү мәсьәләләре хакында фикерләр еш яңгырап тора. Биредә Ә.Еникинең татар мәгарифенә мөнәсәбәтле “Татар баласына урысча белмәү куркынычы янамый” (1998) мәкаләсендә урын алган фикер-карашлары турында сүз алып барабыз.

Мәкаләдә аң-белем мәсьәләсенә карашлар җәмгыятьтәге милли вәзгыятькә бәйле яктыртыла: “Тел мәсьәләсендә минем карашым менә нидән гыйбарәт: татар халкының кимендә яртысы үз телен (ана телен) югалтты. Сәбәбе билгеле: большевиклар партиясенең вак халыкларны, аеруча безнең татарны, әкренләп урыслаштыру сәясәте иде... Хрущев вакытында ук Татарстан шәһәрләрендә, шулай ук күрше өлкәләрнең авылларында да татар мәктәпләре ябылып бетте диярлек...Казанда, мәсәлән, татар балаларының 93 проценты урыс мәктәпләренә күчте. Утыз ел буена без балаларыбызны ана телендә укытудан мәхрүм булып тордык. Шул вакыт эчендә урыс мәктәпләре аша узган берничә буын үз телен онытты, урыс теле генә төп тел булып калды” [1: 814].

Язучы бу “фаҗигадән чыгу юлын” мәгариф системасында күрә: “Менә шул фаҗигадән ничек чыгарга?.. Моның өчен туган телебезгә яңадан кайту кирәктер. Ә кайтыр өчен татар балалары һәммәсе дә (100 проценты белән) бары тик ана телендә укый башларга тиеш...Бөтен дөньяда ул шулай – һәр милләт баласы иң элек үз телендә укырга-язарга өйрәнә...” [1: 814].

Ә.Еникинең милли вәзгыятькә мөнәсәбәте, карашлары ачык: “Безгә дә шул максатка ирешер өчен, беренче нәүбәттә башлангыч мәктәпләрне тизрәк ачарга һәм аларның саннарын да күбәйтергә кирәк иде. Бу хакта мин «үзгәртеп кору» башлангач та язып чыккан идем. Ләкин ни сәбәптер баштарак моңа юньләп

игътибар итүче дә булмады... Ә соңрак инде «нигә башлангыч мәктәп» кенә? «Юк, безгә татар гимназияләре, татар университетлары да кирәк», – дип бик ялкынланып китүчеләр дә булды... Әмма адәм баласы укуын университеттан башламый, мәктәпнең беренче сыйныфыннан башлый. Сүз бит яшь буынны «маңкорт» булудан саклап калу турында бара! Шуннан соң 10-15 ел вакыт үтеп китте, ә без туган телебезнең язмышы турында һаман баш ватудан, бәхәсләшүдән узганыбыз юк... ” [1: 814]. Сүз иярә сүз, язучы Казан мәктәпләрендәге туган телдә укытуга мәнәсәбәткә бәйле борчуын аерып җиткерә.

Әдипнең туган телне саклап калуга мөнәсәбәтле фикерләре аерымачык, төгәл, системалы. Мәкаләдә яшь буында милли үзаң тәрбияләү, туган телебезне саклау юлында мәгариф системасы ничек катнашырга тиешле, ана телен укыту методикасына бәйле әдипнең карашлары түбәндәгечә җиткерелә: “Бу мәсьәләдә мин һаман иске карашымда торам... Мәгәр кайбер яңа тәкъдимнәр дә өстисем килә.

1. Балаларны ана телендә укыта башлау безнең Татарстанда, махсус закон нигезендә, мәҗбүри булырга тиеш. Кабатлап әйтәм: сүз укыта башлау турында гына бара. Ягъни бала үз телендә камил укый-яза белгәнчегә кадәр... Моның өчен дүртьеллык башлангыч мәктәпне тәмамлау җитәчәк. Шуннан соң баланың теләсә нинди телдә укуын дәвам иттерергә хакы булырга тиеш.

2. Татар балаларын урыс мәктәпләренең башлангыч сыйныфларына кабул итми торырга... Иң элек ул татар мәктәбенә барырга тиеш. Аннары урыс телен татар мәктәбендә дә өйрәнәчәкләр. Ләкин беренче класстан ук түгел, яшь балага берме-икеме ел фәкать үз телен генә укыту кирәк.

3. Татар мәктәбе үзенә аерым булырга тиеш... Балаларны чорнаган мохитнең да “татарча” булуы кирәктер, мөгаен... Өч-дүрт урам саен бер башлангыч мәктәп булсын иде... Аңа зур биналар кирәкми, әнә Казанны уратып алган меңнәрчә ике-өч катлы коттеджлар да ярый торгандыр, минемчә... Бу изге эшкә хөкүмәт акча табарга тиеш” [1: 815].

Әдәби иҗатында да, публицистикасында да әдип татар шәхесләрен тәрбияләүдә XX йөз башы милләт хадимнәре үрнәген мисал итеп китерә. Аның карашынча, туган телдә белем алу кешенең шәхес буларак оешу-формалашуы юлында иң әһәмиятле факторладан: “Минем бу тәкъдимнәремдә яңалык юк диярлек. Татарның белемгә юлы ана теленнән башланган. Үзебездәге мәктәп-мәдрәсәләрдән соң, әгәр теләсә, югары белемне чит илләргә барып алган. (Истанбулга, Бәйрутка, Каһирәгә, хәтта Сорбоннага). Әмма инде туган телен бервакытта да онытмаган. Бу җәһәттән олы шәхесләребезнең белем юлы безгә бик матур үрнәк!..” [1: 816].

Боларга өстәп, әдип “гамәлдә никадәр күбрәк кулланылса, тел шулкадәр камилләшәчәк”[1: 816] дигән фикерне ассызыклый: “Татар һәм урыс телләре дәүләт теле булып саналгач, без шул ике тел белән әйбәт кенә яшәргә тиешбез... Әмма татар теленең ролен көчәйтү бик кирәк. Мәсәлән, халыкның 70-80 проценты татарлар гыйбарәт районнарда идарә итү эшләре татар телендә барырга тиеш. Бу бик законлы булачак. Шулай ук дәүләт органнары

тарафыннан чыгарылачак һәртөрле карар, законнар да башта татар телендә язылып, соңыннан русчага тәрҗемә ителергә тиеш. Телне эшләтә белергә кирәк..” [1: 816].

Шул рәвешле, әдип яшь буында милли үзаң тәрбияләү башлангыч һәм урта мәктәтә туган телдә белем бирү белән бәйли, бу хакта фикер-карашларын укыю җиткерә.

### Әдәбият


1. Еники Ә.  Татар баласына урысча белмәү куркынычы  янамый / Сайланма әсәрләр. 3 томда. – 3 том. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2019. – Б.8154-816.
2. Заһидуллина Д.Ф. 1960-1980 еллар татар әдәбияты: яңарыш мәйданнары һәм авангард эзләнүләр. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2015. – 383 б.

# МЕЖЪЯЗЫКОВЫЕ ОМОНИМЫ В ТУРЕЦКОМ И РУССКОМ ЯЗЫКАХ

***Гайнутдинова А.С.***
***Казанский федеральный университет***
***ASGajnutdinova@kpfu.ru***

***Аннотация.*** Одним из важных аспектов при сравнении двух языков является наличие или отсутствие в них схожих слов. С самого начала человеческой истории носители языка всегда искали сходства в своих контактах с носителями других языков. Сравнительная лингвистика уделяет особое внимание общему происхождению, однако этимологические исследования имеют более широкий охват и, следовательно, требуют более тщательного изучения лексических сходств.

***Ключевые слова:*** образование, межъязыковые омонимы, обучение, слова, отличие.

Сам термин «омоним» у многих ученые трактуется с неким различием. В.В.Виноградов, Л.А.Булаховский, О.С.Ахманова и др. утверждают, что омонимы - это фонетически идентичные слова, однако имеющие различное значение, вне зависимости от их написания. В.В.Броун, И.В.Арнольд, Н.М.Шанский утверждают, что омонимы - это фонетически идентичные слова, однако имеющие различное значение, с обязательно одинаковым написанием [1: 288].

Турецкие лингвисты также касаются темы термина «омонимы», для ее определения используются: «sesteş», «eş sesli kelimeler» «eş adlı kelimler» или «homonim». Однако в турецком языке омонимы рассматриваются лишь формально через призму грамматики языка.

Изучение двух и более языков выявило термин «межъязыковые омонимы» (также называемые «ложными друзьями переводчика»), которые образовываются путем исторических, политических, культурных и социальных перемен в обществе, отражаются в обоих языках [4: 116].

Межъязыковые омонимы всегда были объектом пристального внимания исследователей. Ученые по-разному определяли и классифицировали данные единицы, исходя из разницы их значений в двух языках. В частности межъязыковые омонимы разделяются как полные, так и частичные, а также по лексико-грамматическим (табл.1) и лексико-семантическим признакам (табл. 2), (табл.3).

В современном турецком языке, согласно словарю Ассоциации турецкого языка, 616.767 слов [11]. Следовательно, в данной работе будет рассмотрено, лишь малая часть слов, которые часто встречаются с точки зрения русскоязычного общества.

**Таблица 1. Межъязыковые омонимы, имеющие сходное написание и звуковые сходства турецком и русском языках.**

| Турецкий | | Русский | |
|---|---|---|---|
| **Написание и ударение** | **Значение** | **Написание и ударение** | **Значение** |
| ad [стт.] | имя | ад [гре.] | преисподняя |
| atle´t [фр.] | 1) майка<br>2) спортсмен, занимающийся атлетической гимнастикой, атлетикой. | атле´т [фр.] | спортсмен, занимающийся атлетической гимнастикой, атлетикой. |
| bank [фр.] | скамейка | банк [фр.]<br>[ита.] | крупное финансово-кредитное учреждение;<br>скамья, прилавок. |
| barda´k [стт.] | стакан | барда´к [уг.]<br>[тур.] | 1)беспорядок;<br>2)(устар.) горшок, стакан. |
| barı´ş [тур.] | мир | бары´ш [блр.] | прибыль, доход. |
| baya´n [стт.] | женщина | бая´н [др. рус.] | 1)хроматический аккордеон;<br>2)арго. шприц |
| bez [ара.] | тряпка | без [др. рус.] | русский предлог «без» |
| hala´t [рум.] | канат, трос | хала´т [тур.] | банное изделие, комфортная домашняя одежда и часть рабочей спецодежды. |
| ham [пер.] | сырой | хам [др.евр.] | грубиян, невоспитанный человек, отличающийся наглостью и пренебрежением к окружающим. |
| kaba´n [арм.] | теплая куртка | каба´н [тюрк.] | дикая свинья |
| kana´t [стт.] | крыло | кана´т [греч.] | толстая веревка из волокон |
| karga´[стт.] | ворона | карга´[блр.] | злобная старуха |
| kaza´k [фр.] | свитер | каза´к [тюрк.] | свободный, независимый человек |
| kol [стт.] | рука | кол [ст.слав.] | заострённый с одного конца шест |
| kot [тур.] | джинсы | кот [ст.слав.] | самец мелких кошачьих |
| kula´k [стт.] | ухо | кула´к [тюрк.] | кисть руки со сжатыми пальцами |
| kum [стт.] | песок | кум [ст.слав.] | крестный отец по отношению к родителям крестника |
| lor [пер.] | разновидность свежего, мягкого и несоленого белого сыра. | лор [лат.] | оториноларинголог - врач, который занимается лечением заболеваний уха, горла и носа |
| patro´n [фр.] | хозяин, владелец предприятия, патрон | патро´н [лат.] | соединенные посредством гильзы в одно целое пуля (снаряд), пороховой заряд, средство воспламенения. |
| priz [фр.] | розетка, в которую вставляют вилку для получения электрического тока. | приз [ст.фр.] | награда, которая вручается человеку, чтобы вознаградить действия или достижения |
| ray [фр.] | рельсы | рай [д.инд.] | место вечного счастья и наслаждений. |
| sır [ара.] | секрет | сыр [ст.слав.] | пищевой продукт в виде твёрдой или полутвёрдой массы, получаемый в процессе сыроделия из заквашиваемого особым способом молока. |
| sirk [фр.] | цирк | сирк [осет.] | боевой топор, секира |
| son [стт.] | последний | сон [ст.слав.] | состояние пониженной умственной и физической активности, при котором сознание изменено, а сенсорная активность в определенной степени подавлена. |
| şuru´p [ара.] | сироп | шуру´п [нем.] | Крепёжное изделие в форме стержня с наружной специальной резьбой, резьбовым коническим концом и головкой на другом конце. |
| taba´k [ара.] | тарелка | таба´к [фр.] | высушенные, измельчённые и ферментированные листья и стебли некоторых видов одноимённого рода растений, употребляемые для курения. |
| tok [стт.] | сытый | ток [искон.] | направленное движение заряженных частиц (электронов, ионов), которое создается изменением электрического поля (напряжением). |
| yâr[пер.]<br>yar [стт.] | любимый<br>обрыв | яр [тюрк.] | крутой берег, обрыв |

[5; 6; 7; 9; 10].

**Таблица 2. Межъязыковые омонимы, имеющие сходное написание и различное звуковое ударение в турецком и русском языках**.

| Турецкий | | Русский | |
|---|---|---|---|
| Написание и ударение | Значение | Написание и ударение | Значение |
| baba´[стт.] | отец | ба´ба [лат.] | прос. женщина |
| banka´ [ита.] | финансовое учреждение | ба´нка [польск.] | сосуд цилиндрической формы |
| belki´[ара. + пер.] | может быть, возможно | бе´лки [гре.] | высокомолекулярные органические вещества, состоящие из альфа-аминокислот, соединённых в цепочку пептидной связью. |
| hata´ [ара.] | ошибка | ха´та [др. венг..] | жилище<br>арго. тюремная камера |
| kara´ [ара.] | черный | ка´ра [польск.] | наказание, возмездие |
| lapa´ [рум.] | каша | ла´па [ст.слав.] | ступня либо вся конечность у некоторых млекопитающих. |
| mama´[стт.] | 1)мама<br>2)кашица для грудных детей | ма´ма [лат.] | женщина-родитель по отношению к своему ребёнку |
| marka´ [ита.] | бренд | ма´рка [нем.] | обозначение оплаты почтовых услуг в виде небольшого, наклеиваемого на угол конверта бумажного треугольника |
| para´ [пер.] | деньги | па´ра [польск.] | два однородный или одинаковый предмета |
| pa´sta [ита.] | торт | па´ста [ита.] | какое-либо вещество в виде тестообразной массы, используемое в косметике, живописи, кулинарии и т. п. |
| yama´[стт.] | заплата | я´ма [ст.слав.] | углубление, вырытое или образовавшееся в земле. |
| ya´zık [стт.] | жалость | язы´к [ст.слав.] | речь, орган вкуса |

[5; 6; 7; 9; 10].

**Таблица 3. Межъязыковые омонимы с частичным графическим изменением в турецком и русском языках.**

| Турецкий | | Русский | |
|---|---|---|---|
| Написание и ударение | Значение | Написание и ударение | Значение |
| cins [ара.] | вид, тип, сорт | джинсы | универсальная и прочная ткань, которая может использоваться в различных предметах одежды, включая обувь. |
| çardak [пер. + ара.] | беседка | чердак | помещение между потолком и крышей дома |
| koza [пер.] | кокон | коза | Общее название рода животных из семейства полорогих |
| kravat [фр.] | галстук | кровать | предмет мебели, предназначенный для сна в положении лёжа. |
| üzüm [стт.] | виноград | изюм | сушенные ягоды винограда |
| zeki´[ара.] | умный | зе´к [рус.] | з/к, «заключенный каналоармеец» -это лицо, подвергнутое аресту в порядке меры пресечения. |

[5; 6; 7; 9; 10].

Имеются также слова, при произношений которых русскоязычные ассоциирует совершенно иные вещи. Например, слова, у которых турецкая «ğ» проглатывая, воспринимается другие слова:

Dağ [пер.]– да [слав.] – *гора*

Yağ [стт.] – я [д.рус.]– *масло*

А некоторые слова же, ассоциируются с известными марками, например:

Boş [стт.]- марка быт. техники Bosch - *пустой*

Bülbül [пер.]– буль буль (обычно имеют ассоциации, с маркой «Gallina Blanca», реплика из рекламы: «Галина Бланка. Буль буль, буль буль») – *соловей*

Tayt [анг.] – марка стирального порошка Tide – *лосины*.

Естественно имеются слова, которые русскоязычные воспринимают, как ругательство или болезнь, например:

Durak [стт.] – дурак (человек с ограниченными умственными способностями) - *остановка*

Kış [стт.]– кыш (междометие «поди вон») – *зима*

Vali [ара.]- вали (арго. иди отсюда) - *администрация*

Yavaş [стт.] git [стт.]– я ваш гид – *езжай по медленней*

Bilgi [стт.+ тур.] panosu [фр.] – в произношение «билги паносу» (понос, диарея) - *доска объявлений* [3: 427-430]

В турецком языке также имеются слова, которые могут возмутить русского человека, например:
Kal [стт.]– кал/фекалии [слав.] - *останься*
Tampon [фр.] – тампон [фр.] (пробка, средство гигиены) – *бампер автомобиля*
Huy [пер.] – хуй (арго. мужской половой орган) - *характер, темперамент*
Her [пер.] – хэр (арго. мужской половой орган) - *каждый*
Manda [арм.]– манда (арго. мошонка) - *буйвол* [2].

В турецком языке также имеются слова, которые являются для русского человека обыденным, однако их они могут возмутить, например:
Bok [стт.]– бок [слав.] - *фекалии*
Sıç [арго тур.]- (птица) сыч [слав.] - императив от глагола *«срать»*
Sürtük [стт.]– сюртук [фр.] – *проститутка* [9; 10].

В современном мире имеются слова, которым присвоили иное значение, например: Makaron [фр.] – макарон (кондитерское изделие) – *в современном турецком языке употребляются два значения. Обозначающий цветные макароны (печенья) и термин обозначающий бумагу для обертки сигарет* [8].

В турецком языке также имеются имена собственные, при произнесении которых, для русскоязычных несет совершенно другое значение, например:
Baran [пер.] - дождь – *баран*
Necip [ара.] - аристократ – *не джип*
Nejdet /Necdet [ара.] – сильный, мужественный – *не ждет*
Niğde [хет.] - от слова «Накита/Нихита» – победоносный;
[др. пер.] - от слова «Анахита» - незапятнанная,
в русском ассоциируется со словом - *нигде*
Yakup/Yakub [ивр.] - воющий с землей – *я куб*
Yaşar [ара.] - живущий, живой - *я шар* [9; 10].

В заключение, можно сделать вывод о том, что межъязыковых омонимов представляет собой достаточно трудную задачу. Однако в работе приведены перечень слов турецкого языка, которые, могут быть с легкостью усвоены благодаря сходству графического написания в турецком и русском языке. Усвоение значений приведенных омонимов может способствовать улучшению коммуникации, устранению неверных восприятий, которые могут приводить к межъязыковой интерференции.

**Литература**

1. Виноградов В.В. Об омонимии в русской лексикографической традиции.// Виноградов В.В. Избранные труды. Лексикология и лексикография.- М.: Наука, 1977. – 318 с.
2. Гершуни В.Л., Ильясов Ф.Н. Русский мат. Антология. Под ред. Ф.Н.Ильясова. – М.: Издательский дом Лада М, 1994. - 50 с.
3. Клугликова Л.Е., Большой академический русский словарь, Том 5. – М: РАН. 2006. - 694 с.

4. Лонская А.Ю. Образ власти в языке российских печатных СМИ 1990-х гг. // Вестник Российского университета дружбы народов. Серия: Русский и иностранные языки и методика их преподавания. 2017. Т. 15. № 1. – С. 113-125.
5. Шипова Е.Н. Словарь тюркизмов в русском языке. Ответственный редактор: А.Н. Кононов. – Алма–Ата: Издательство «Наука» КазССР, 1976. - 444 с.
6. Этимологические онлайн-словари русского языка.// URL: https://lexicography.online (дата обращения 02.01.2024)
7. Gufo.Me. Словари и энциклопедии.// URL: https://gufo.me (дата обращения 02.01.2024).
8. Makaron nedir, ne işe yarar? Makaron anlamı ve kullanım alanları!// URL: https://www.cnnturk.com/ajanda/makaron-nedir-ne-ise-yarar-makaron-anlami-ve-kullanim-alanlari (дата обращения 02.01.2024)
9. Nışanyan Sözlük.// URL: https://www.nisanyansozluk.com (дата обращения 02.01.2024)
10. TDK Sözlük. // URL: https://sozluk.gov.tr (дата обращения 02.01.2024)
11. Türkçede Kaç Kelime Var? Türk Dil Kurumu Sözlüğüne Göre Türkçe Kelime Sayısı Kaçtır?// URL: https://www.sabah.com.tr/egitim/turkcede-kac-kelime-var-turk-dil-kurumu-sozlugune-gore-turkce-kelime-sayisi-kactir-e1-6342551 (дата обращения 02.01.2024)

# ФИНАНС ГРАМОТАЛЫЛЫГЫН ТУГАН ТЕЛ ҺӘМ ӘДӘБИ УКУ ДӘРЕСЛӘРЕ БЕЛӘН ИНТЕГРАЦИЯЛӘҮ

***Гайсина Р.С., Фәтхетдинова Р.Г.***
***Алабуга шәһәре 6 нчы урта мәктәбе***
***gaisina1972@inbox.ru; www.rasima2014@mail.ru***

Финанс грамоталылыгы темасы бүгенге көндә бик актуаль, чөнки кеше матди дөньяда яши, шунлыктан бу нигезләрне балалар кечкенәдән үк өйрәнеп үсәргә тиеш була. Мәктәптә белем алу барышында финанс грамоталылыгы нигезләрен теләсә кайсы фән, теләсә кайсы дәрес эченә кертергә мөмкин, түгәрәкләрдә, дәрестән тыш чараларда өйрәнергә була. Чыгышыбызда бу мәсьәләнең чишелешен туган тел һәм әдәби уку дәресләре мисалында карарбыз. Әлбәттә, дәресләрдә вакыт чикләнгән булу сәбәпле, эшлекле, имитацион, рольле уеннар һәм квест кебек формаларны тирәнтен биреп булмый, чөнки туган (татар) теле һәм әдәби уку буенча укыту программасы башка, тик бу теманы бераз өйрәнү бик мөмкин хәл.

Соңгы елларда бу эш башлангыч сыйныфларда туган тел дәресләрендә дә алып барыла башлады. Мәсәлән, 1, 2 сыйныфларда “Мәктәптә” темасын өйрәнгән вакытта укучы, уку-язу әсбапларының ничә сум торганнын әйтергә, һәм алар белән ничек кулларырга, аларны саклап тотарга кирәклеген белергә тиеш. Безнең мәктәп янәшәсендә “Юлдаш” канцелярия кибете урнашкан. Укучылар белән кибеткә экскурсиягә бардык, уку-язу әсбаплары бәяләре белән таныштык. Товарлар төрле булганлыктан, бәяләре дә төрле, кайсы товарны алсаң, күпме акча китәсен, ничә сум, тиен экономиягә калачак, ул акчага тагын нинди кирәкле товар алып булачагы турында әңгәмә оештырдык. Тел белемен камилләштерү максатында, укучылар сатучы белән әңгәмә кордылар, сатучыдан кирәкле киңәшләр дә алдылар.

“Бакчада” темасы буенча төрле уен алымнарын кулларырга мөмкин. “Базарда”, “Кибеттә” уеннары уйнату теманы өйрәнүдә яхшы нәтиҗә бирә. Укучы яшелчә, җиләк-җимешләрнең нинди бәядә икәнен, нинди хезмәт белән үскәнен белә.

Финанс грамоталылыгын “Сәламәт бул*!”* темасын үткән вакытта кулланырга мөмкин. Укучыларга “Кибеттә” уены бик ошый. Алар шәхси гигиена предметларын кулланып, Сатучы, Сатып алучы булып уйныйлар. Аларның бәяләренә игътибар итеп, әйбернең кадерен белергә өйрәнәләр.

“Минем яраткан уенчыкларым” темасын өйрәнгәндә укучылар үзләренең яраткан уенчыкларын ясыйлар. Мәктәптә үткәрелә торган ярминкәләрдә, ясаган уенчыкларына үзләре бәя куеп саталар. Бу да укучыга һәр әйбернең хезмәт белән килгәнен, акчаны саклап тотарга кирәклеген өйрәтә.

3 нче сыйныфта “Ашханәдә” темасын үткәндә бу эш алымын куллану үтемле. Пешекче янына килеп меню сорыйлар, бәясе белән кызыксыналар. Алар азыкның нинди бәядә торуын белеп, азыкны әрәм-шәрәм итмәячәкләр.

4 нче сыйныфта “Һөнәрләр” темасын өйрәнгән вакытта төрле уен алымнарын кулланабыз. «һөнәрләр дөньясы» эшлекле уены уйныйбыз. Мондый эшлекле уенны дәрестә уздыру кызыклы. Балалар төрле һөнәр костюмнары киеп, реквизитлар белән киләләр һәм үз һөнәрләре турында сөйлиләр. Хезмәт турында мәкальләр әйтәләр. Бу һөнәр ияләренең эш хаклары белән кызыксыналар. “Кем булырга телисең?” темасына диалоглар төзегәндә, “Ни өчен бу һөнәрне сайларга телисең?” дигән сорау куябыз. Укучылар җавапларында бу һөнәрнең кызыклы, тормышта кирәкле булуы, чөнки әти-әнисенең шул һөнәр ияләре булуы белән беррәттән, “алар яхшы хезмәт хакы ала” дип тә әйтәләр.

Бүген дөньяны акчасыз күз алдына китереп булмый. Шуңа күрә дәресләрдә финанс грамоталылыгын куллану бик кирәк.

Дәресләрдә финанс грамоталылыгы темасына түбәндәге ысулларны кулланырга мөмкин: сүзлек диктанты, грамматик биремле диктантлар, текст белән эшләү, бирелгән текстны үзгәртеп язу, эссе, иншалар язу, проект эшләре яклау һәм башкалар. Мәсәлән:

1. Мәкальләрне әйтеп яздыру, исемнәрнең астына сызу.

*Акча янчыгы җиңел булганда - күңелдә авыр.*

*Акча табу җиңел түгел, акча тарату җиңел.*

*Кем озак йоклый, шул акча тупламый.*

2. Иншалар һәм текстлар төзү өчен темалар: “Минем гаилә бюджеты”, “Акча ничек арта?”, “Бәхет акчадамы?”, “Бәхетле булу өчен күпме акча кирәк?”

3. Текстлар төзү өчен темалар:

“Мин – бер меңлек”

Мин – биш меңлек”

“Мин биш тиен алтын”

“Мин – тишекле бер тиен”

Соңгы вакытта Проект эшләре киң таралды, “Акча тарихы”, “Төрле илләрнең акча берәмлекләре” сыйфат, сан темаларын өйрәнгәннән соң “Туган көнгә әзерлек”, “Минем бүлмәмә ремонт кирәк” кебек финанс темаларына проект эшләре тәкъдим итәргә була.

Туган тел дәресләрендә “Эш кәгазьләре” темасы өйрәнелә, ул дәресләрдә үрнәк буенча “Расписка” язарга өйрәтүне кертергә мөмкин, татар сыйныфларында үрнәк буенча расписка тексты яздыру, татар телен өйрәнүче рус төркемнәрендә текстны күчереп язуны оештырырга була.

Дәресләрдә монолог, диалоглар төзү дә, аларны күмәк уйнау да укучыларның финанс белемен күтәрүгә этәргеч бирә, “Мафия” уены, кибеттә товар сайлау; кибеткә килгәч, бары тик кирәкле әйберләрне генә алырга игътибарны юнәлтергә өйрәтергә кирәк.

Әдәби уку дәресләрендә финанс грамоталыгына өйрәтүгә килгәндә, мисалларны күпләп табарга була. Борын-борын заманнан ук безнең халыкны финанс темасы кызыксындырган. Хәтта халык авыз иҗатында да бу темага мисаллар бихисап, акча темасына багышланган мәкальләр, Хуҗа Насретдин мәзәкләрендә, экиятләрдән дә мисалларны күпләп китерергә була. Бары тик ул

заманнарда “финанс темасы” дигән термин гына булмаган, акча, байлык темасы итеп күрсәтелгән. Мисалга мәкальләрне карыйк: “Татар халык иҗаты. Мәкальләр һәм әйтемнәр” җыентыгында [1: 236] бу темага багышланган мәкаль-әйтемнәр бихисап. Мәсәлән, 100 сум акчаң булганчы, 100 дустың булсын, Акча аккош, муенын суза да оча, Акча акчаны таба, Акча бакчада үсми, “Акча” дигәнне чукрак та ишетә, Акчаның күзе юк, Тиен тәңкәне саклый, Тирләмичә акча табылмый, Хәерченең акчасы әтәч булып кычкыра. Гыйлем акчага килми, тырышлык белән килә. Өч тиенлек куян - биш тиенлек зыян. Акчалының кулы уйный, акчасызның күзе уйный. һ.б. Әгәр дә бу мәкальләрне өйрәнеп, тема буенча бүлеп классификацияләсәк, тәрбия темасына да караган бик күп сорауларга җавап табып булыр иде.

Әкият, мифларны искә алыйк: “Су иясе” мифында комнан бау ишеп, күлегезне күккә элеп куеп киптерәм, дип тапкыр егет үзенең тишек бүреген тутырырлык күл төбендә яткан алтын тәңкәләр сорый, тапкырлыгы белән зур чокыр казып, шуны тутырганчы, су иясе аңа алтын тәнкәләр ташый. “Ак бүре” әкиятендәге патшаның өченче улы да зур байлыкка ия була. “Алтын балта” әкятендә карт, үзенең дөрес сүзе белән көмеш, алтын балтага ия булып, байлыкта яши башлый.

Безнең халык яшь буын вәкилләрен “акча колы булма”, “акчага табынма” дип өйрәтсә дә, бик күп әкиятнең азагында төп уңай герой байлыкка ия була, ярты патшалыкны ала һәм патша кызына өйләнеп, байлыкта-муллыкта, яңа сарайлар төзеп яши башлый.

Шулай итеп, туган тел һәм әдәби уку дәресләрендә финанс һәм социаль грамоталылык тәрбияләргә мөмкин. Бала күбрәк акчаны бәяли башлый, финанс темасы турында күбрәк белә, көндәлек тормышта финанс чишелешләрен кабул итәргә өйрәнә. Балаларны шулай ук кечкенәдән гаиләнең финанс хәле белән таныштыру кирәк. Финанс белемнәре алган укучы үзенең киләчәгенә җаваплы караячак. Нинди дә булса карарлар кабул иткәндә ул бик уйлап эш итәчәк.

Финанс грамоталылыгы гади генә итеп әйткәндә ул – акчаны сакчыл рәвештә, дөрес максатларда файдалану. Укучылар акчаның нинди юл белән эшләнгәнен аңлаган очракта гына, аның кадере булачак.

**Әдәбият**

Татар халык иҗаты. Мәкальләр һәм әйтемнәр. Казан: Тат.кит.нәшр, 1987.- Б. 236-246.

# КАЗАН УНИВЕРСИТЕТЫНЫҢ ТАТАР ТЕЛЕ КАФЕДРАСЫНДА ФОРМАЛАШКАН ФӘННИ МӘКТӘПЛӘР
## (татар теле һәм әдәбияты кафедрасының 80 еллык юбилее уңаеннан)

***Галиуллина Г.Р.***
***Казан федераль университеты***
***caliullina@list.ru***

***Аннотация.*** В статье представлен обзор научной деятельности представителей кафедры татарского языка Казанского университета. Основное внимание уделено научным школам, которые сформировались на кафедре и получили широкую известность в тюркологии.

***Ключевые слова:*** татар теле белеме, Казан университеты, төрки-татар фәнни мәктәбе.

Ике йөз елдан артык тарихы булган Казан тюркология фәнни мәктәбе бөтен дөньяда төрки телләр һәм әдәбият тарихын өйрәнү үзәге буларак танылган. Фәнни мәктәпнең барлыкка килүе Казан Император университеты ачылу белән бәйле. Аның 1804 елның 5 ноябрендә имзаланган беренче уставы буенча татар теленең бер лектор штаты билгеләнгән. Университетта татар теле укытыла башлау һәм бу юнәлешләрдә башланган тикшеренүләрне дә университет ачылу белән бәйләү бик хаклы.

Казан тюркология мәктәбенең уңышлы эшләвендә һәм үсешендә Казан лингвистика мәктәбенең роле зур. Аның вәкилләре татар һәм башка төрки телләрне өйрәнүдә алдынгы фәнни юнәлешләргә башлангыч бирделәр. Казан лингвистика мәктәбенә нигез салучы И.А. Бодуэн де Куртенэ, профессор В.А. Богородицкийның татар теле үсешенә зур өлеш кертүе һәркемгә билгеле. Нәкъ менә Казан тюркология фәнни мәктәбе кысаларында Каюм Насыйри, Әхмәтһади Мәкъсуди, Галимҗан Ибраһимов, Җамал Вәлиди һ.б. кебек беренче татар галимнәре пәйда булды. Аларның эшчәнлеге XX гасырда татар теле белеменең яңа юнәлешләрен формалаштыруга һәм үстерүгә ярдәм итте [4: 3].

Казан дәүләт университетында 1944 елда татар теле һәм әдәбияты бүлеге ачылу татар теле белеме өлкәсендәге эшчәнлекнең киңәюенә, фәнни мәктәпләр оешуга зур этәргеч була. Филология фәннәре кандидаты, доцент Р.А. Хәкимова җитәкчелегендә дүрт кешелек штат белән ачылган әлеге бүлек, югары белемле, киң профильле филологлар әзерләү генә түгел, фәнни тикшеренүләр юнәлешендә дә системалы эшчәнлеккә керешә [1: 134]. Узган гасырның урталарына инде татар теле белеме фәненең грамматика, тел тарихы, ономастика, стилистика, лингвометодика тармаклары зур үсешкә ирешә, телнең төрле катламнарын функциональ һәм структур яктан өйрәнү системалы һәм комплекслы характер ала. Тел белеменең төрле тармаклары буенча фәнни мәктәпләр формалаша һәм татар фәнендә генә түгел, төрки дөньяда танылa башлый. Әлеге фәнни мәктәпләрнең күренекле вәкилләре хезмәтләрендә яктыртылган мәсьәләләр алга таба да татар теле белеменең үсеш юнәлешләрен

билгеләп, тагын да киңрәк эзләнүләргә юл ача.

Татар теле кафедрасы вәкилләренең актив эшчәнлеге нәтиҗәсендә дөньякүләм танылган фәнни мәктәпләрнең берсе – хәзерге татар теленең структур һәм функциональ үзенчәлекләрен өйрәнү юнәлеше.

Татар теле белемендә телнең структур төзелешен тикшерү беренче татар грамматикаларыннан ук башлана. XX гасыр урталарына татар грамматикасы бай һәм киңкырлы традицияләре булган фәнни тармакка әверелә. Шул тармакларның берсе – татар теленең синтаксик төзелеше. Татар теле белемендә беренчеләрдән булып, М.З. Зәкиев татар синтаксисын комплекслы өйрәнеп, фәнни хезмәт әзерли, университет студентлары өчен татар синтаксисы буенча курсны гамәлгә куя. Аның 1963 елда филология фәннәре докторы дәрәҗәсенә якланган «Татар теленең синтаксик төзелеше» дигән темага диссертациясе Казан университетында яңа фәнни мәктәп формалашу һәм нәтиҗәле үсүгә этәргеч бирде. Соңрак бу традицияне Казан дәүләт университеты доценты С.М. Ибраһимов дәвам итә һәм, беренчеләрдән булып, «Татар телендә аналитик төзелмәләр», «Чагыштырулы төзелмәләр һәм аларның синонимнары» (1966), «Синтаксик синонимнар һәм аларның төрләре» (1970), «Татар телендә синтаксик синонимнар» (1976), «Синтаксик стилистика» (1989) һ.б. фундаменталь хезмәтләрен яза. Профессор Ф.С. Сафиуллина – татар теле белеме һәм тюркологиядә беренчеләрдән буларак татар сөйләм теле синтаксисы, диалект синтаксисы һәм текст стилистикасы, рус һәм татар телләренең чагыштырма синтаксисын комплекслы тикшерүче галимә. Безнең фикеребезчә, аның 1978 елда дөнья күргән «Синтаксис татарской разговорной речи» хезмәте татар теле белеме өчен фундаменталь әһәмияткә ия. Биредә сөйләм теле әдәби телнең аерым бер формасы буларак аерып күрсәтелә [5: 5].

Хәзерге вакытта югарыда аталган галимнәрнең традицияләре аларның укучылары доцентлар Р.К. Сәгъдиева, Р.Х. Мирзаһитов һ.б. тарафыннан үстерелә.

Татар теленең грамматик төзелешен өйрәнү юнәлешендә татар теле белемендә генә түгел, тюркологиядә дә зур казаныш яулаган академик Д.Г. Тумашева эшчәнлеге мөһим урын били. Аның 1964 елда нәшер ителгән һәм 1978 елда икенче басмасы дөнья күргән «Хәзерге татар әдәби теле морфологиясе» хезмәте бүгенгәчә югары уку йортлары студентлары өчен дәреслек вазифасын башкара. Галимә татар теленең морфологик төзелешен, сүз төркемнәре, аларга хас грамматик категорияләрне гомумтеоретик, тюркологик принципларга таянып, татар теле морфологиясе казанышларына нигезләнеп, үзенә генә хас логик эзлеклелектә, фәнни нигезләп бирә. Сүзләрне төркемләү принциплары, сүз төркемнәренең үзара мөнәсәбәтләре мәсьәләләре татар теле белемендә булган фикер төрлелеген, я булмаса, игътибардан читтә калып барган аспектларны өйрәнгәндә бик әһәмиятле җирлек булып торалар [6; 7].

Галимәнең 1986 елда дөнья күргән «Татарский глагол» фундаменталь хезмәтендә иң катлаулы саналган фигыль сүз төркеме һәм аңа хас граммматик категорияләр функциональ-семантик аспектта комплекслы тикшерелде. Фигыль сүз төркемен өйрәнүдә семасиологик һәм ономасиологик принципларны бергә

кулланып, Д.Г. Тумашева темпоральлек, модальлек һәм персональлек функциональ-семантик кырларына караган күпсанлы грамматик формаларны һәм конструкцияләрне тикшерә. Хезмәттә моңарчы игътибар үзәгеннән читтә калып барган әдәби, диалекталь, сөйләмә телдәге формалар, стилистик вазифа үти торган конструкцияләр махсус анализланып, алар арасындагы синонимик бәйләнешләр бәян ителә [7: 179].

Соңрак басылып чыккан фәнни хезмәтләрдә, дәреслекләрдә, шул исәптән берничә тапкыр рус һәм татар телләрендә нәшер ителгән өчтомлык «Татар грамматикасы» академик басмада Д.Г. Тумашева тәгълиматлары тулысынча чагылыш тапты. Галимә нигез салган фәнни тикшеренү методы хәзерге татар теле морфологиясе буенча язылган хезмәтләрнең фәнни-методологик нигезен хасил итә.

Күренекле галимә Ф.М. Хисамова, үзенең остазы Д.Г. Тумашева идеяләрен үстереп, камилләштереп, 2006 елда югары уку йортлары студентлары өчен «Татар теле морфологиясе» хезмәтен язды. Әлеге дәреслек 2015 елда тулылындырылып яңадан дөнья күрде. Галимәнең Казан университетында морфология фәнен укыту барышында туплаган тәҗрибәсе монографик пландагы хезмәт өчен ныклы нигез булып тора. Ф.М. Хисамова морфология фәне өлкәсендә барган бәхәсләргә, аларны чишү юлларына әлеге дәреслектә махсус тукталып үтә. Сүзләрне төркемләүгә бәйле булган төрлелекнең сәбәпләрен күрсәтү белән бергә, татар теле белеме казанышларына нигезләнеп, объектив рәвештә аларның җирлеген анализлый [7: 58]. Әлеге хезмәттәге идеяләр яңадан эшкәртелеп басылып чыккан «Татар грамматикасы» (2016) хезмәтенең икенче томында да төп урынны били.

Татар теленең төзелешен, фонетик системасын тикшерү юнәлешендә Казан дәүләт университеты галимнәре Казан лингвистика мәктәбе традицияләренә таянып эшлиләр. В.А. Богородицкий, Г. Шәрәфләр башлаган эксперименталь юл белән татар фонетикасын өйрәнү юнәлешендә Ү.Ш. Байчура зур эшчәнлек алып бара. 1954-1959 елларда ул татар теле һәм әдәбияты кафедрасында эшли, шул чорда татар сузык авазларын эксперименталь юл белән өйрәнеп, филология фәннәре кандидаты гыйльми дәрәҗәсенә диссертация яклый (1954). Аталган галимнәр салган традициянең дәвамы кафедра доценты Г.М. Сөнгатов эшчәнлегендә дәвам итте. 1991 елда ул Д.Г. Тумашева җитәкчелегендә себер татарларының диалект сөйләмен эксперименталь юл белән өйрәнеп, кандидатлык диссертациясен яклады.

Казан университетының эксперименталь фонетика лабораториясендә ничәмә буын татар филологларын тәрбияләп, фәнни юнәлешкә алып кергән тынгысыз галим гамәли лингвистика, чит телгә өйрәтү методикасы, эксперименталь фонетика өлкәсендә күпсанлы хезмәтләр авторы Т.И. Ибраһимов татар теле кафедрасы белән тыгыз бәйләнештә эшләп, Ф.М. Хисамова белән берлектә М.Р. Сайхуновның татар телен ритм-темпоральлек ягыннан тасвирлауга багышланган диссертациясенә (2010) җитәкчелек иттеләр.

Бүгенге көндә татар эксперименталь фонетикасы юнәлешендә тикшеренүләр актив алып барылмый, әмма тасвирлама фонетика кысаларында башкарылган тикшеренүләр доцент Г.К. Һадиева хезмәтләрендә чагыла. Шулай ук татар теле белеме кафедрасы галимнәре төркеме Россия Фәннәр Академиясенең LingvoDoc виртуаль лабораториясе инструментарийлары ярдәмендә татар теленең структур һәм функциональ үзенчәлекләрен өйрәнү юнәлешендә эш башладылар.

Бүгенге көндә дә татар теле белеме кафедрасы вәкилләре телебезнең структур-функциональ үзенчәлекләрен өйрәнүгә зур игътибар бирәләр. Соңгы елларда бу юнәлеш киңәеп, татар сөйләм телен функциональ-структур планда өйрәнүгә юнәлдерелгән хезмәтләр дөнья күрә. Шуларның берсе – Г.Р. Галиуллина, Э.Х. Кадыйрова, Г.К. Һадиева авторлыгында басылган «Современная татарская разговорная речь: идентификационные признаки и социальная дифференциация» монографик хезмәте (2020). Бу хезмәт татар теле белемендә беренче тапкыр, заманча методлар кулланып, татар сөйләменең аерым социаль параметрларын һәм аермалы билгеләрен фонетик, лексик-семантик һәм грамматик яссылыкта өйрәнүне күздә тота. Әйтергә кирәк, моңа кадәр бу аспектта эшләр булмавын истә тотып, авторлар хәзерге татар әдәби теленең норматив билгеләрен һәм әдәби тел нормасыннан тайпылышларның асылын ачу омтылышы да ясадылар [3: 181].

Татар теле кафедрасында XX гасыр урталарында татар теле тарихын фәнни яктан комплекслы өйрәнү юнәлеше активлашты. Л.Җәләй хезмәтләрендә формалашып, соңрак аның укучысы В.Х. Хаков тарафыннан үстерелеп, тулы бер фәнни мәктәп буларак оешкан әлеге юнәлеш татар фәненә дистәләгән белгечләр тәрбияләде. Хәзерге көндә дә бу мәктәп вәкилләре кафедраның әйдәп баручы гаимнәре булып тора. Филология фәннәре докторы, профессор Ф.Ш. Нуриева –урта гасыр төрки-татар язма телен өйрәнү буенча танылган галим-тюрколог, төрки-татар әдәби теле формалашуның тарихи һәм лингвистик алшартлары, кулланылыш һәм үсеш этапларының үзенчәлекләрен өйрәнүгә багышланган дистәләгән монография авторы. Соңгы елларда галимә иске раритет текстларның телен өйрәнү, аларны басмага әзерләү һәм киң җәмәгатьчелеккә таныту юнәлешендә киң колачлы эш алып бара. Шулар арасында Ф.Ш. Нуриева өйрәнгән И. Мегизер, Я. Емельянов, Г.Ф. Миллер хезмәтләрен, сергач мишәрләре һәм керәшен татарларының язма истәлекләрен аерым атарга кирәк.

В.Х. Хаковның укучысы, аның фәнни традицияләренең дәвамчысы филология фәннәре кандидаты, доцент Х.Х. Кузьмина – хәзерге көндә тел тарихы юнәлешендә борынгы төрки-татар язма истәлекләренең телен өйрәнүче гаять тәҗрибәле галимә. Ул борынгы телебезнең үзенчәлекләрен комплекслы өйрәнүгә йөз тоткан һәм татар теле тарихына багышланган коллектив фундаменталь хезмәтләрның авторы да булып тора.

Тел тарихы юнәлешендәге тагын бер үзенчәлекле юнәлеш – суфичылык поэзиясенең телен өйрәнү. Бу өлкәдә филология фәннәре докторы А.Ф. Йосыпов шактый нәтиҗәле һәм системалы эш алып бара. Аның «XX

гасырның беренче яртысы татар поэзиясе: стиль һәм образлы сурәт тудыру үзенчәлеге» (2020), «Языковая система татарской суфийской поэзии XIX века» (2022) һәм башка хезмәтләрендә тарихи стилистика, тел тарихына караган мәсьәләләр күтәрелә.

Казан университетында 1960 елларда профессор Г.Ф. Саттаров җитәкчелегендә татар ономастикасы өлкәсендә системалы эзләнүләр башлана. Галимнең топонимия һәм антропонимияне өйрәнүгә багышланган күпсанлы фундаменталь хезмәтләрендә татар ономастикасы фән буларак оеша һәм Казан төрки-татар ономастикасы фәнни мәктәбе формалаша. XX гасыр ахырына Казан университетының татар теле кафедрасы Урта Идел һәм Урал төрки-татар ономастикасын өйрәнү үзәге буларак кына түгел, бәлки Россия, чил илләр өчен фәнни кадрлар әзерләү үзәге буларак та танылa. Хәзерге көндә Казан федераль университеты вәкилләре төрки-татар ономастика мәктәбенең традицияләрен дәвам итәләр, ономастиканың төп берәмлекләрен генә түгел, перифериядәге өлкәләрен дә актив өйрәнәләр. Әлеге эзләнүләрнең нәтиҗәләре күпсанлы мәкаләләрдә, шулай ук монографик тикшеренүләрдә дә чагылыш таба [2: 53]. Мисал өчен, Г.Р. Галиуллина җитәкчелегендә татар эргонимиясе, ономастик лексиканың функциональ үзенчәлекләре, татар прагмотонимнарына багышланган фәнни хезмәтләр язылды. Кафедра доценты Г.К. Һадиева татар топонимиясе өлкәсендә эзлекле эш алып бара. Г.Р. Галиуллинаның исә татар антропонимиясенә багышланган җиде монографиясе һәм күпсанлы мәкаләләре дөнья күрде.

Кафедра галимнәре Татарстан Республикасы фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты җитәкчелегендә язылган һәм төрки-татар ономастика фәнни мәктәбенең актив эшләүче галимнәрен берләштергән «Татар лексикологиясе» (2017) өчтомлык хезмәтнең тулысы белән татар ономастикасына багышланган өченче томында әйдәп баручы авторлар буларак катнашты.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, татар теле белеме кафедрасы вәкилләре алдагы чорларда салынган традицияләрне дәвам итә, аларны заман фәне казанышлары нигезендә үстерә, баета һәм яңа юнәлешләрдә дә актив эзләнүләр алып баралар.

**Литература**

1. Баһаветдинова Х.З. Галимә Хәкимова Рабига Афзаловна: тормыш юлы һәм эшчәнлеге // Историческая этнология. – 2021. - Том 6, № 1. – Б. 132 -137.

2. Галиуллина Г.Р. Казан төрки-татар ономастика фәнни мәктәбе: тарихы һәм бүгенгесе // Тюркская ономастика: от истоков до современности: материалы МеждунаТ98 родной научно-практической конференции (Казань, 11–14 октября 2018 г.) / под ред. Г.Р. Галиуллиной. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2018. – С. 52-57.

3. Галиуллина Г.Р., Кадирова Э.Х., Хадиева Г.К. Современная татарская разговорная речь: идентификационные признаки и социальная дифференциация. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2020. – 222 с.

4. Замалетдинов Р.Р., Галиуллина Г.Р. Казанская тюркологическая школа и ее видные представители // Татарское языкознание в контексте Евразийской

гуманитарной науки: материалы Международной научно-практической конференции (Казань, 1-4 ноября 2016 г.) / под ред. Р.Р. Замалетдинова, Г.Р. Галиуллиной. - Каазнь: Изд-во Казан. ун-та, 2016. – С. 3-8

5. Сафиуллина Ф.С. Синтаксис татарской разговорной речи. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1978. – 253 с.

6. Тумашева Д.Г. Хәзерге татар әдәби теле. Морфология. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1978. – 220 б.

7. Тумашева Д.Г. Татарский глагол (опыт функционально-семантического исследования грамматических категорий). – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1986. – 188 с.

8. Хисамова Ф.М. Татар теле морфологиясе: югары уку йортлары өчен д-лек. – Казан: Мәгариф, 2006. – 335 б.

# РОЛЬ ЛИНГВОИНФОРМАЦИОННЫХ ТЕХНОЛОГИЙ В СОВРЕМЕННОМ ОБУЧЕНИИ ИНОЯЗЫЧНОМУ УСТНОМУ ОБЩЕНИЮ: ПЕРСПЕКТИВЫ И ВЫЗОВЫ

***Гимадиева Э.Н.***
***Казанский федеральный университет***
***gellonsy@mail.ru***

***Аннотация.*** Данная статья посвящена вопросу о роли лингвоинформационных технологий в процессе обучения иноязычному устному общению. В рамках статьи рассмотрено понятие лингвоинформационные технологии, представлена попытка обосновать их необходимость, раскрыт потенциал икуственного интеллекта Gliglish при обучении иноязычному устному общению, приведен пример коммуникативных упражнений на его основе.

***Ключевые слова:*** коммуникативная ситуация, преподавание иностранного языка, лингвоинформационные технологии, иноязычное устное общение

В настоящее время при обучении иностранным языкам протекает в рамках лингвоинформационного периода, что предполагает активное использование информационных технологий при обучении иностранным языкам [1]. Информационные технологии являются дополнением традиционной модели обучения, которые создают условия для оптимизации процесса обучения иностранным языкам. На данный момент распространены различные инструменты информационных технологий на занятии, как: флеш-карты, мультимедиа, специальное программное обеспечение, веб-ресурсы, технологии виртуальной и дополненной реальности, конкордансы, корпусы, также технологии на основе искусственного интеллекта. Все перечисленные инструменты активно применяются преподавателями во время занятий, главной проблемой выступает правильный подбор и правильная организация работы с ранее представленными инструментами для обучения иностранному языку, ввиду этого в рамках информационных технологий можно говорить о лингвоинформационных технологиях, которые используются именно на языковых занятиях.

Одной из проблем для практикующего преподавателя выступает проблема построения обучения иноязычному устному общению, то есть развивать коммуникативные умения в различных жанрах устного общения (например: дискуссия, дебаты, публичное выступление и т.д.).

Критериями отбора лингвоинформационных технологий могут быть их соответствие общедидактическим и методическим принципам обучения, принципы: коммуникативной направленности, аутентичности, индивидуализации и дифференциации, научности, новизны, самостоятельности и активности, интерактивности, наглядности, дружественности интерфейса.

В рамках данной статьи рассмотрим один из примеров внедрения

лингвоинформационных технологий в процесс обучения иноязычному устному общению и предложим ряд коммуникативных упражнений к нему.

Нами был выбран искусственный интеллект ’’Gliglish’’ (https://gliglish.com/), слоган, которого разработчиком представлен как: изучай языки с помощью искусственного интеллекта.

Искусственный интеллект представляет из себя возможность с учителем на свободные темы по выбору обучающегося либо согласно коммуникативной задаче, поставленной преподавателем, либо же предлагает варианты в рамках ролевой игры, где ситуация уже задана за вас и необходимо решать поставленные задачи в рамках коммуникации. Представленные ситуации варьируются от самых простых, например: у пекаря, до более сложных: сессия с психологом.

Искусственный интеллект представляет из себя диалог с собеседником, роль которого он исполняет. Пользователю необходимо записать то сообщение, которое хочет, для этого ему дается минута, после искусственный интеллект озвучивает свой ответ и дальше уже строится диалог на основе данных ответов. Если у обучающегося нет идей, что ответить, либо не может сформулировать свой запрос, система показывает свои «предложения» на полученный ответ, которые обучающийся может использовать в качестве вдохновения. Что касается языкового потенциала, кроме возможности практиковать устное общение, то система проверяет на наличие ошибок: грамматических, ошибок в произношении и т.д. и предлагает, как можно улучшить ответ. Для удобства сказанный текст транскрибируется и показывается в диалоге в момент озвучки, при необходимости также можно перевести сказанный текст.

На основе данного искусственного интеллекта обучающимся можно предложить коммуникативные упражнения. Важным элементом коммуникативного упражнения является постановка коммуникативной ситуации преподавателем, которая будет служить опорной точкой, а также инструкции к выполнению, например, в рамках дисциплины «Практика по культуре речевого общения», студенту предлагается почувствовать себя участником программы ’’73 Questions with VOGUE’’, особенность, которой заключается в том, что в рамках неё проводят интервью с известными людьми, задавая им 73 вопроса разного формата, начиная простыми темами, заканчивая сложными вопросами, требующие аргументации.

Упражнения могут быть внедрены, как и на занятии, так и в рамках самостоятельной работы обучающихся. В данной статье рассмотрим формат упражнений, задействованный и на занятии, и как часть домашнего задания. Обучающимся даётся инструкция по выполнению упражнения: первое, что предлагается обучающимся – это примеры подобных видео-интервью, чтобы была задана их специфика, обсуждение просмотренного, далее задаётся коммуникативная ситуация – ’’Can we do 73 questions with VOGUE? You ask me questions and I reply’’. Например (рис. 1):




Рисунок 1 – Работа с Gliglish

Далее предлагается сделать анализ своих ответов на наличие ошибок и т.д. Вторая часть задания предполагает запись своего видео-интервью в парах в формате ’’73 Questions with VOGUE’’, и после просмотр результатов на занятии для оценивания качества получившегося материала.

Таким образом, на основе вышеперечисленного создавая подобные коммуникативные упражнения на основе лингвоинформационных технологий, мы создаем возможности для организации самостоятельной работы обучающегося, а также условия для практики иноязычнного устного общения вне занятия, что при регулярном внедрении может сыграть ключевую роль при развитии коммуникативных умений в различных жанрах устного общения.

**Литература**

Гребенщикова А.В. Лингво-информационный период развития проблемы формирования вторичной языковой личности в системе профессионального лингвистического образования // Вестник ЮУрГУ. Серия: Образование. Педагогические науки. 2013. №1. URL: https://cyberleninka.ru/article/n/lingvo-informatsionnyy-period-razvitiya-problemy-formirovaniya-vtorichnoy-yazykovoy-lichnosti-v-sisteme-professionalnogo (дата обращения: 08.02.2023).

## ЛЕКСИКАНЫ ӨЙРӘТҮДӘ ШИГЪРИ ӘСӘРЛӘРГӘ ТАЯНУ

***Гыйләҗиева А.Н.***
***Казан шәһәренең 127нче мәктәбе***
**[batrus79@mail.ru](mailto:batrus79@mail.ru)**

***Аннотация.*** В этой статье дана представлены материалы из опыта работы со школьниками при изучении новой лексики на уроках татарского языка. Новизна работы состоит в том, что все упражнения на преобретерие навыков опираются на упражнения с поэтическими текстами.

***Ключевые слова***: лексика, родной (татарский) язык, преобреиение навыков, речь.

Сөйләм телен үстерүгә юнәлдерелгән төрле күнегүләр арасында лексик күнегүләр шактый зур урын алып тора. Бу төр күнегүләрне үткәрүдә төп максат, беренчедән, балаларның актив сүз байлыгын булдыру, икенчедән, теге яки бу фикерне дөрес һәм ачык итеп белдерү өчен, кирәкле сүзне сайлап алырга өйрәтү. Ләкин рус балаларына татар лексикасын өйрәткәндә телебезнең үзенчәлекләрен дә истә тотарга кирәк. Авазларның әйтелешен дә, сөйләмнең структур кисәкләрен дә, тел закончалыкларын да укучылар дәреслекләргә урнаштырылган күнегүләр, алардагы текстлар аша таныргa өйрәнә. Шунлыктан бу текстларны сайлау дәреслек төзүчеләр өчен бик әһәмиятле һәм җаваплы хезмәт булып тора. Дәреслекләрдәге күнегүләр системасы белән танышу, алардагы текстларның эчтәлеген һәм теге яки бу фонетик, лексик һәм грамматик кагыйдәне өйрәнүдә уңышлы ярдәмен ачыклау эшнең актульлеген билгели

Бу эшне төрле методик алымнар белән оештырырга мөмкин: балалар белән сөйләшү, аерым темага әңгәмәләр үткәрү, дидактик уеннар уйнау, җырлар җырлау, халык авыз иҗатыннан файдалану һ.б. Балалар белән сөйләшү темага яраклаштырылган булырга, аларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып төзелергә, балаларга якын, кызыклы булырга тиеш. Таныш сүзләр көн саен кабатланып торса, шулай ук нәтиҗә яхшырак була. Шунлыктан дәресләрдә төрле күнегүләр файдаланыла.

Сүзлек белән эшләгәндә,балалар туган телнең байлыгы белән таныша, үзләренең актив лексикасына яңа сүзләр өсти, татар теленең сәнгатьле сөйләм чараларын үзләштерә, сүзнең лексик һәм грамматик мәгънәләренә төшенә. 5 нче сыйныф дәреслегендә Р.Миңнуллинның шигырьләренә нигезләнеп, сүзлек белән эш биреме бирелгән күнегүне карап үтик:

Кайтыгыз инде, кошкайлар!
Сагындык үзегезне.
Кайтырлар дип, зәңгәр күктән
Алмыйбыз күзебезне.
Каеннар көтә зарыгып,
Зәңгәр яз көтә сезне.

Үзегез дә очрашуны
Көздән үк көтәсезме?
Туган якның бизәге сез,
Туган якның җан ы сез.
Туган якка сез бик кирәк,
Онытмагыз аны сез!( Кайтыгыз, кошкайлар!) Дәреслектә әлеге шигырьгә түбәндәге бирем тәкъдим ителә: *1 бирем*: Нәрсә ул туган як? Аңлатмалы сүзлектән мәгънәсен язып алыгыз. [Харисова, Сәйфетдинов, Максимов 2012:15]

Сүзлек белән эшләгәндә татар һәм рус телләре өчен уртак сүзләргә таянабыз. Һәр дәрестә кимендә 4-5 сүз өйрәнәбез, шул ук вакытта таныш булган сүзләрне дә кабатлыйбыз, аларны балаларның сөйләменә кертергә тырышабыз. Сүзләр яхшы истә калсын өчен, исеме аталган әйберләр күрсәтәбез, сүзне кат-кат әйттерәбез. Аңлашылмаган очракта, аның русча тәрҗемәсе китерелә.

Сүзлек белән эшләүнең төрле алымнары бар: яңа сүзнең мәгънәсен күрсәтмәлелектән файдаланып аңлату; синонимнар ярдәмендә аңлату; рус теленә тәрҗемә итеп күрсәтү; эш, хәрәкәт ысулы белән аңлату. Алар барысы да телгә өйрәтү процессында төрлечә кулланылалар һәм ситуациягә бәйле рәвештә файдаланылалар.

Яңа сүзгә аңлатма биргәндә, күрсәтмәлек - иң уңайлы чараларның берсе. Күрсәтмәлек ысулы беренче чиратта башлангыч мәктәптә кулланыла дип санала, ләкин бу чараны югары сыйныфларда да, хәтта югары уку йортларында да кулланырга мөмкин. Р. Миңнуллинның “Әниемә ял кирәк” шигыре ахырында күрсәтмәлек бирелгән [Харисова, Сәйфетдинов, Максимов 2012:38]. Ул сүзлекчә рәвешендә кулланылган.

Мырлама – не мурлычь
Мулама –не мычи
Тирәк-ива
Улама-не вой

Тасвирлаудан файдалану ысулы укучының үзләштергән лексикасына таянып яңа сүз кертүне аңлата. Мәсәлән: сабантуй – татар халык бәйрәме; калфак – хатын-кызның баш киеме. Ягъни: ашамлык – аны ашыйлар; аяк – аяк белән йөриләр, трамвайның аягы юк, кешенең ике аягы бар, этнең дүрт аягы бар һ.б. Кайвакыт бу ысул эчендә комментарий да кулланырга мөмкин. Комментарий – мәгънәсе аңлатыла торган сүзнең сыйфатлары күрсәтелгән кечкенә текст һәм аны теге яки бу милли колоритлы әйбергә карата еш кулланырга була. Мәсәлән: өчпочмак – милли ашамлык. Ул өч почмак кебек була. Аңа бәрәңге, ит, суган, май, тоз кирәк. Тасвирлаудан файдалану ысулы укучы белән моңа кадәр үзләштерелгән лексиканы да кабатлауга ярдәм итә.

Синонимнардан дөрес файдалану да мәктәп дәреслекләрендә өйрәнелә. Укучы яңа кертелә торган сүзнең синонимын инде өйрәнгән булырга тиеш. Синонимнар белән кулланганда, аларның арасындагы нинди дә булса аермасын билгеләү кирәк. Җамалетдинова И.З. авторлыгында чыккан 3 нче сыйныф дәреслегеннән мисал:

Кара әле, кара
Каен яфрак яра.
Каюм утын яра,
Кулларында – яра.
Кыям бара-бара.
Гел көнбагыш яра.
Бабай, шаулап кар,
Чыбык белән яра.
Менә әйбәт чара-
Шәрәф шәрран яра!(Яра) [Җамалетдинова,2008:26].

Абсолют синонимнар телдә бик сирәк була. Алар стилистик, мәгънәви яисә тарихи яклары белән аерылып торалар. Бу аермалар әһәмиятле булганда, алар турында әйтелергә тиеш. Мәсәлән: ләкин, ә – икесе дә каршы куючы теркәгечләр, Ләкин – кискен каршы куюны белдерсә, ә – җиңелчә каршы куюны белдерә.

Синонимнар турында мәгълүмат рустелле укучылар өчен төзелгән дәреслекләрдә дә бирелә. Мәсәлән, Р.Нигматуллина дәреслегендә Р.Миңнуллинның "Исәнме, мәктәп!" шигыре мисалында синоним сүзләрне табу, аңлауга юнәлдерелгән күнекмәләр булдырыла.

Исәнме, и мәктәп
Сагынып беттеңме?
Укырга килдек без,
Син безне көттеңме?
Без килгәч, бүгеннән
Бик күңелле булыр.
Классларың моннан соң
Шаулап гәрләп торыр. ( Исәнме, мәктәп)

Сагынып беттеңме=бик нык сагындыңмы[ Р.Р. Нигъмәтуллина, 2014: 8]

Сүзнең мәгънәсен аңлатуның иң нәтиҗәле алымнарыннан берсе дип тәрҗемәне саныйлар. Тәрҗемә башка ысулларга кушылып, һәрвакыт диярлек лексик төшенчәнең мәгънәсен билгеләргә ярдәм итә. Ләкин тәрҗемә интерференция күренешенә дә китерергә мөмкин. Лексик интерференция – туган телдәге һәм өйрәнелә торган телдәге сүзләрнең мәгънәләре иуры килмәү дигән сүз. Мәсәлән, я иду домой татарчага, әлбәттә, мин өйгә кайтам дип тәрҗемә ителергә тиеш. Ләкин еш кына аны рус балалары мин өйгә барам дип тәрҗемә итәләр.

Шигырьне укы. Омонимнарны мәгънәләрен аңлат биреме дәреслектә 4нче сыйныф укучылары өчен тәкъдим ителә.

Кара әле, кара:
Каен яфрак яра.
Каюм утын яра,
Кулларында-яра.
Кыям бара-бара,
Гел көнбагыш яра,

Бабай, шаулап кара

Чыбык белән яра.

Менә әйбәт чара-

Шәрәф шәрран яра!(Яра) [Җамалетдинова,2008:38].

4 нче сыйныф дәреслегендә Р. Миңнуллинның берничә шигырен тәрҗемә итәргә тәкъдим ителгән күнегүләр дә бар:

Не боимся

Ох, высота какая!

Гора у нас – крута.

На санках мы летаем…

Какая красота!

[И.Л.Литвинова, Э.Р.Садыйкова, Л.И.Гарипова, 2014:31] . Бу очракта укучылар барлык кирәкле лексиканы үзләштергән, тел берәмлекләрен урынлы файдалана beләләр дигән фикер туы, чөнки дәрестә тәрҗемә эше белән шөгыльләнү лексиканы үзләштергәч кенә бирелә. Шул ук дәреслектә татар теленнән рус теленә тәрҗемә итергә тәкъдим ителгән күнегүләр дә бар:

Бабамның да

Улы мин,

Әбинең дә

Улы мин,

Әтинең дә

Улы мин,

Әнинең дә улы мин.

Аларның уң кулы мин. (Туган илнең улы мин). [И.Л.Литвинова, Садыйкова, Гарипова, 2014:44]

Сүзне тәкъдим итү, аның турында беренчел аңлатма бирү лексиканы өйрәтү юнәлешендә әһәмиятле процесс. Сүзне үзләштерү өчен гадәти төрле күнегүләр кулланыла. Күнегүләр төрле булулары мөмкин, ләкин алар бөтенесе дә бер максатка юнәлгән: сүзләрне кулланырга өйрәтүгә.

Телне өйрәнү сүзләрне үзләштерүдән башка мөмкин түгел, әлбәттә. Методика тарихында башка телләргә өйрәтүдә иң зур урынны нәкъ лексика алып тора. Телгә өйрәтүнең кайсы гына этабын алсак та, иң башлап сүзләр өйрәнелә. Фонетикага өйрәткәндә дә, авазлар сүзләр аша килеп керәләр. Морфологияне өйрәткәндә дә, сүзнең формалары синтаксик нигездә үзләштерелә. Сөйләшү, тыңлап аңлау, уку һәм язудан торган сөйләм эшчәнлегенең төрләренә өйрәтү лексикадан башка мөмкин түгел. Шуңа күрә чит телне өйрәнгәндә, телнең лексикасын өйрәнү иң мөһим, иң әһәмиятле өлкә дип санала.

**Әдәбият**

1.Җамалетдинова З.И. Татар теле. Дүртьеллык башлангыч татар мәктәпләренең 2 нче сыйныфы өчен дәреслек.-Казан:Мәгариф,2008- 130 б.

2.Литвинов И.Л. Садыйкова Э.Р., Гарипова Л.И. Татар теле. Татарский язык. 4 сыйныф: рус телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек - Казан: Татар.кит.нәшр., 2015. - 143б.
3.Миинуллин Р. Сандугачлар туа гына... / Казан утлары. - 2008. - №8. - Б. 5-9.
4.Нигъмәтуллина Р.Р. 6 нчы класста татар теле дәресләре: рус телендә гомуми белем бирү оешмалары укытучылары өчен методик кулланма. - Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. - 127 б.
5.Харисов Ф.Ф. Заманча белем бирү технологияләре (Современные технологии обучения). - Казань: КФУ, 2015. - 62 с.

# БАШКОРТ ТЕЛЕ УКЫТЫУҘА ЯҢЫ ТЕХНОЛОГИЯЛАР КУЛЛАНУ

***Жуковская Р.К.***
***МБОУ «СОШ №16» Нижнекамского муниципального района***
***rufina.nzh@gmail.com***

***Аннотация.*** Инновации в образовании - это элементы нового, которые существенно улучшают учебно-воспитательный процесс, позволяя избавиться от недостатков, мешающих эффективному обучению и учению. Одним из основных требований, предъявляемых к обучению башкирского языка с использованием интернет-ресурсов, является создание взаимодействия на уроке — то, что принято называть в методике технологией интерактивного обучения. Преподавание башкирского языка — благодатное поле деятельности для учителя.

***Ключевые слова:*** Инновационные приемы, инновационные технологии, мультимедийные средства, интернет-ресурсы, компьютер, интерактивность, функциональная грамотность.

Предмет буларак, башҡорт теле – уҡыусыға туған теленең һүҙ сәнғәтен аңларға, яҙма һәм һөйләү телмәрен, ижади мөмкинселектәрен үҫтереүгә ярҙам итеүсе фән ул. Уҡытыусыларҙың бурысы, яңы технологияны һайлап заман менән бергә атлау. Хәҙерге заман шарттарында телдәрҙе өйрәнеү мөмкинселектәре көндән- көн киңәйә бара. Бөгөн мәктәптә уҡыусыға бер генә түгел, ике һәм унан күберәк телде үҙләштереү мөмкинлеге бирелгән. Рәсәй мәғарифын модернизациялау барған ваҡытта тыуған телдәрҙе укытыу буйынса хәл итеүсе мәсьәләләр ҙә юҡ түгел.

Башланғыс синыфтарҙан уҡ туған телде өйрәнә башлар алдынан иң тәүҙә: өндәрҙе дөрөҫ әйтергә өйрәтеү, һәр һүҙҙең мәғәнәһен аңлатыу, һөйләмдәр төҙөү һәм дә уҡыусыларҙың телмәрен үҫтереү төп ролде уйнай. Уҡытыусы, балаларҙың йәш үҙенсәлектәрен өйрәнеп, ошондай мәсьәләләрҙе сисеү юлдарын, алымдарын һәм телде үҙләштереүгә йүнәлтелгән эффектлы алымдарҙы эҙләй.

Яңы информацион-технологик осор йәш быуын башҡорттарынан хәҙерге кешегә мотлаҡ кәрәк булған белем, тәжрибә, компьютерҙы белеү, функциональ белем, үҙ тормошоңдо ҡора белеүҙе талап итә. Беренсенән, уҡытыу рус телендә алып барылған мәктәптәрҙә балаларҙы башҡортса өйрәтеүҙә төрлө психологик үҙенсәлектәр иҫкә алына.

Мәҫәлән, рус мәктәптәрендә уҡыусылар бер кимәлдә башҡорт телен үҙләштерә алмай. Башҡорт телен бер аҙ аңлай белгән һәм бөтөнләй ҙә аңламаған уҡыусылар бар. Был иһә үҙенсәлекле уҡытыуҙы талап итә. Телде өйрәнеү бурыстары итеп—башҡорт телен өйрәнеү, уны ҡулланыу, грамматик нормаларын билдәләү, башҡалар менән аралашыу, һөйләшеү…

Өсөнсөнән, бәләкәй синыф уҡыусыларының хәтерләү һәләте үҫеш ала. Улар ишетеп, күреп иҫтә ҡалдыра алалар. Дәрестә телмәр үҫтереү өҫтөндә эш алымдары ҡулланыу кәрәк: һорауҙарға яуап биреү, тиҙәйткестәр, һанашмаҡтар,

шиғырҙар, тел шымартҡыстарҙы үҙ аллы, хор менән ҡабатлау, иң мөһиме--өндәрҙе дөрөҫ әйтә белеү. Синыфта бөтә бала ла бер төрлө ҡатнашмай. Йомшағыраҡ уҡыған уҡыусылар менән йышыраҡ эшләү, телмәрҙәрен үҫтереү—уларҙы нығыраҡ йәлеп итеү—һәләттәренә ярашлы эштәр, биремдәр тәкдим итеү мөһим.

Уҡыусылар менән индивидуаль эштәр ҙә мөһим урын алып тора: синыфта уҡыусыларҙың эш төрҙәре төрлөсә була. Шунлыҡтан бер төркөм уҡыусылар менән дә шәхси рәүештә эш алып барыла. Дәрестә, айырыуса бәләкәй синыфтарҙа күргәҙмәлелек ҙур роль уйнай: сюжетлы картиналар, открыткалар, һүрәттәр, магнитофон яҙмалары, видеофильмдар киң ҡулланыла.

Мәктәптә рус телле балаларҙың күбеһе дәрестән тыш башҡортса аралашыу хоҡуғынан мәхрүм. Шуға өйрәнелгән һүҙҙәрҙе, һөйләмдәрҙе дөрес һайын төрлө формала иҫкә төшөрергә кәрәк. Грамматика өйрәнгәндә башҡорт һәм рус орфографик ҡағиҙәләрен сағыштырырға, айырмаларын билдәләргә кәрәк. Дәрес барышында уҡыусылар алдына проблемалы һорау ҡуела һәм дәрес аҙағында ошо һорауға яуап табырға кәрәклеген аңлатыла. Бындай ситуациялар уҡыусыларҙы уйланырға мәжбүр итә, танып-белеү һәләтен үҫтерә.

Түбәнерәк синыфтарҙа «Шиғриәт тулҡынында», «Урманға сәйәхәт» кеүек туҡталыштар, физминуттар өйрәнеү йәнле үтә. Берәй күнегеүҙе ярыш формаһында, төркөмләп ярышыу һымаҡ эштәр уҡыусыларҙа ҡыҙыҡһыныу уята.

Юғары синыфтарҙа уҡыусыларҙың башҡорт теле буйынса белемдәре бай. Иркен аралаша белеү, фекер алышыуҙары, телмәрҙәре үҫешкән була. Дәрестәрҙе төрләндереү буйынса индивидуаль карточкаларҙағы биремдәрҙе башҡарыу, схемалар төҙөү, үҫтереүсе система буйынса логик мәғәнәле моделдәр эшләү һәр яҡлап та логик фекерләү һәләттәрен үҫтерә. Ошо йәһәттән башҡорт теле һәм әҙәбиәте кабинентында айырым папкаларҙа уҡытыусы, уҡыусыларҙың төҙөгән моделдәре тупланып тора. Ижади эш дәфтәрҙәрендә лә уҡыусыларҙың ижади эштәре төрлөсә. Тимәк, бер уҡыусы шиғырҙы оҫта яҙһа, икенсеһе—кроссворд, ребус төҙөй, өсөнсөһө-хикәйә яҙа һ.б. Бындай эш төрҙәре уҡыусыларҙы ижади эҙләнеүгә этәрә, фекерләү ҡеүәһен, фантазияһын үҫтерә, һүҙҙең матурлығын, көсөн тоя белергә өйрәтә.

Яңы интерактив технологиялар менән функциональ грамоталылык ҡулланыу отошло. Был уҡыусыларҙа ла шулай уҡ ҡыҙыҡһыныу уята. Ком пьютер ярҙамында дәрес үткәреү, унын аша күнегеүҙәр, тестар башҡарыу, эҙләнеү уҡыусылар өсөн яңылыҡ алыу. Мәктәптәрҙә күптән Интернет селт әрҙәре тоташҡан. Ә инде Интернет селтәрҙәре аша ла мәғлүмәттәр эҙләү - хәҙерге заман уҡыусылары өсөн бөтә мөмкинлектәр ҙә булдырылған.

Берәй сараларҙа ла шулай уҡ проекторҙар менән ҡулланырға ла мө мкинлектәр етәрлек. Шулай итеп, заман менән бер юлдан атлап, яңынан яңы башҡорт теле һәм әҙәбиәтенә эффектлы юлдар эҙләгәндә һәм тапҡан да, туҡтауһыҙ камиллашҡанда ғына ыңғай һөҙөмтәләргә ирешеп була, уҡыусыларҙы һәр ваҡыт яңы технологиялар

ҡулланырға, яңы асыштар булдырырға, артабан да туған телебеҙҙе нығытыу өҫтөндә эшләргә лә эшләргә. Уҡыусылар дәрескә теләк менән килһен өсөн, унда ғәжәпләнеү, һоҡланыу, ҡәнәғәтләнеү тойғолары уятырлыҡ эш төрҙәре, төрлө алымдар ҡулланыу предметҡа ҡарата ҡыҙыҡһыныу уятасаҡ. Теләп башҡарылған, күңелгә ятыш эш иҫтә ҡала, баланың һәләтен, аңын үҫтерә. Әгәр материалды үҙләштереү ҡыйын,ялҡытҡыс, бер төрлө икән, уҡыусының күңеле һыуына, активлығы кәмей һәм телде өйрәнергә булған теләге бөтөнләй һүнергә мөмкин. Шуға күрә уҡытыусы яңы ысулдар, эш алымдары уйлап тапҡанда йәки ижади эшләгәндә генә балалар ҙа ижади фекер йөрөтә аласаҡ.

Балаларҙа башҡорт телен уҡыуға ҡыҙыҡһындырыу тәрбиәләү өсөн компьютер технологияларын ҡулланыу һуңғы йылдарҙа иң мауыҡтырғыс сара булып иҫәпләнә. Сөнки уҡыусылар,үҙҙәрен уҡытҡан уҡыусыларҙан айырмалы рәүештә, донъяны танып белеүҙә компьютерҙың мөмкинселектәре менән нығыраҡ ҡыҙыҡһына. Хәҙер был заман талабы. Тик компьютерҙы урынлы һәм дөрөҫ файҙалана белергә кәрәк.

Уҡытыу процесында компьютер ҡулланыу өлгөрөштөң сифатын күтәрергә лә ярҙам итә. Башҡорт теле һәм әҙәбиәте буйынса электрон дәреслектәрҙе, методик ҡулланмаларҙы дәрестә оҫта ҡулланыу уҡытыусыға яңы теманы аңлатыуҙы еңеләйтһә, уҡыусыға ҡыҙыҡһыныу уята.

Ғөмүмән, туған тел уҡытыусыһы уҡыусыларҙың ижади фекерләүен үҫтереү, тел шәхесен тәрбиәләү эшмәкәрлегендә әллә күпме яңы ысулдар, ҡыҙыҡлы эш төрҙәре, алымдар уйлап сығара ала. Яңылыҡтар, асыштар яһағанда, әлегә тиклем билдәле булғандарын белеү, берләштереү, таныш булғандарын күҙ уңында тоторға тейеш.

Телдә,уның һүҙҙәрендә, грамматик формаларында халыҡтың донъяуи аңлауы, менталитеты сағылыуын өйрәткән саҡта материал онотолмаҫлыҡ итеп үҙләштерелгә тейеш. Уҡытыусы өйрәнелергә тейешле материалдың йөкмәткеһенә ҡарап төрлө уйындар һайлап, уларға төрлө ҡыҙыҡһындырырлыҡ исемдәр бирә ала. Мәҫәлән, «Серле ҡумта», «Серле тоҡсай», «Кем күберәк», «Һүҙҙәр үреү», «Китек диктант», «Кире-мире», «Йомаҡ ҡойошоу», «Мәҡәл әйтешеү» һ.б. шундай исемдәр менән «донъяны таныу юлы» булған ҡыҙыҡ уйындарҙы, аҡыл операцияһының эшен һәм эҙләнеүҙе талап иткән һорау һәм мәсьәләләрҙе файҙаланырға кәрәк. «Бала тик уйында ғына туған телдең нескәлектәренә өйрәнә», телдең рухы тип атап йөрөткән нәмәне үҙләштерә»,- тигән М. Горькийҙың һүҙҙәре менән килешмәү мөмкин түгел.

## Ҡулланылған әҙәбиәт

1. .Аҙнағолов Р.F. Хәҙерге дәрес: уҡыу ҡулланмаһы. Үҙгәрешле, икенсе баҫма. — Өфө: БашДУ, 2011. С. 155.
2. Аңлайышлы дәреслектәр кәрәк. Башҡортостан гәзите, Өфө:2019.С. 4.
3. Толомбаев Х.А., Дәүләтшина М.С. Урыҫ мәктәптәренең 1-4 синыфлары өсөн “Башҡорт теле” дәреслегенә методик күрһәтмәләр. Уҡытыусы өсөн ҡулланма. – Өфө: Китап, 2001. С. 7-8.

# ТАТАР ПАРЕМИЯЛӘРЕНДӘ ТУГАНЛЫК МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕНЕҢ ЧАГЫЛЫШЫ

***Җамалетдинова Г.Ф.***
***Казан федераль университеты***
***Гайсина А.Р.***
***Чистай шәһәренең 1 нче гомуми белем бирү мәктәбе***
***gulua.gali1973@mail.ru; Gaisinaar@gmail.com***

***Аннотация.*** В статье рассматриваются специфика семейно-родственных отношений, отдельных терминов родства «АТА» (отец) и «АНА» (мать) в татарском языке. Авторы считают, что они относятся к древнейшим пластам лексики и связаны с самыми древними традициями народа.

***Ключевые слова.*** татары, язык, культура, отец, мать

«Тел һәм мәдәният» мөнәсәбәтен өйрәнүнең, бер яктан, инде күптәннән килә торган тарихы бар. Чөнки тел белемендә мәдәният белән бәйләнешләрне яктыртуга элек-электән зур урын бирелеп килә. Ләкин бу өлкәдәге гомуми һәм аерым мәсьәләләрне яктыртуга багышланаган шактый гына хезмәт булуга карамастан, әлеге проблеманы гомумтеоретик планда да, гамәли аспекттта да тикшерү әле актуаль булып кала бирә. Соңгы вакытта социомәдәни процессларның үсеше, төрле илләр һәм халыклар арасындагы мәдәни, фәнни һәм икътисади элемтәләрнең аеруча зур тизлек белән киңәя баруы, мәдәният феномены һәм тел шәхесенә карата игътибарның елдан-ел арта баруы бу проблематикага карата кызыксынуны бермә-бер арттыра.

Тел – аралашу чарасы гына түгел, ә халыкның хәтере һәм тарихы, аның мәдәнияте һәм этнос өчен традицион һәм гадәти формалардагы гамәли эшчәнлеге тәҗрибәсе дә. Тел һәм мәдәнияттә исә кешене чолгап алган реаль чынбарлык, халыкның яшәү шартлары, аның фикерләү һәм чынбарлыкны үзләштерүенең универсаль һәм шул ук вакытта үзенчәлекле характеры, менталитеты чагылыш таба. Аларны өйрәнү милли мәдәниятнең үзәгенә күз салырга ярдәм итә.

Элегрәк тел һәм мәдәният проблемалары этнолингвистика, лингвострановедение фәннәре кысаларында өйрәнелгән булса, соңгы елларда бу мәсьәләләр белән турыдан-туры лингвокультурология шөгыльләнә. Ул теге яки бу халыкның менталитетын, дөнья тел күренешен сурәтләүне нигездә концептлар ярдәмендә башкара.

Татар халкы менталитетын чагылдыруда аеруча зур әһәмияткә ия булган берничә лексик-семантик төркем булуы мәгълүм. Шуларның берсенә – туганлык мөнәсәбәтләре белән бәйле кайбер термин һәм концептларга – тукталып китүне кирәк дип саныйбыз.

Татар теленә *гаилә* сүзе гарәп теленнән кергән. Аның төп мәгънәсе: бергәләп яшәүче ир, хатын, балалар һәм якын туганнардан торган кешеләр төркеме, өй җәмәгате [1: 68].

Бер йортта гаилә булып яшәү – төрки халыклар вәкиле булган өйләнүче яшь егет өчен үз йортыңны булдыру, җәмгыятьнең аерым гаиләсе булып китү, үз өеңдә торуны аңлата. Сүзнең эчке формасы («өй-ләнү») нәкъ шуңа ишарә ясый.

Элек-электән гаилә тулы канлы тормыш итү һәм имин картлыкның бердәнбер формасы булып торган. Татарларда, башка төрки халыклардагы кебек, гаиләле булу хөрмәт ителгән, ә никахлашу зарури шарт кына түгел, мөселманнар өчен Ходай хакына башкарылучы изге гамәл дип тә кабул ителгән: *Никахлашкан зат ялгыз калган иң дини мөселманга караганда да Ходай тарафыннан күбрәк яклана* [2: 327].

Өйләнешүгә булган уңай мөнәсәбәт мәкальләрдә дә чагылыш тапкан: *өйләнү – көйләнү* – өйләнгән кешенең тормышы жайга салына; *Өйләнми картайганнан акыл сорама; Өйләнмәгәннең тамыры корыр; Өйләнү – җаныңа җавап, башыңа савап; Өйләнү белән өй салуга Алла юнь бирә һ.б.*

Гаилә учагын саклауда хатын-кыз аерым урын тота: *Йорт тоткан да хатын, йорт бетергән дә хатын; Начар гармун көй бозар, начар хатын өй бозар; Хатын булмый, өй булмас; Хатынсыз йорт – язсыз ел кебек һ.б.*

Балалар тәрбияләү процессында гаиләнең иң мөһим вазифаларыннан берсе этномәдәният кыйммәтләрен тапшыру һәм этник үзаң тәрбияләүдән гыйбарәт.

Тикшеренүчеләр этномәдәният трансмиссиясендә гаилә әгъзалары арасында рольләр бүленешенең аерым үзенчәлекләре булуын билгеләп үтәләр. Татарларда аталар шул милләткә хас булган милли үзаң формалаштыруда күбрәк катнашалар, ә аналар исә нигездә мәдәният һәм көнкүреш эчтәлеге үзенчәлеген тапшыралар [3: 125].

Татар телендә «ана» һәм «әни» дигән бер үк төшенчәне аңлатучы ике термин бар. Ана – бик күп гасырлар дәвамында кулланылучы гомумтөрки *ана (ANA)* сүзеннән [4: 16]. Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә *ана* сүзенең түбәндәге мәгънәсе бирелгән: Ана – балага карата: тудырган хатын, әни [5: 56].

Татар телендә *ана* варианты күбесенчә әдәби телдә кулланыла, ә *әни* – «ана» сүзенең алгы рәт варианты буларак формалашкан һәм узуаль мөрәҗәгать формасы булып хезмәт итә. Шулай итеп, әлеге сүзнең этимологиясе гомумтөрки *ана* сүзе белән бәйләнгән. *Әни* сүзе шуның нечкә варианты гына.

Хатын һәм ана роле ислам традицияләрендә шактый аерыла. Ана, кыз яки хатын белән чагыштырганда, гаиләдә бик зур йогынты көченә һәм абруйга ия. Бу, әлбәттә инде, татар халык авыз иҗатында да чагылыш таба: *Ана хакын уч төбендә тәбә кыздырып ашатсаң да кайтара алмассың; Ананың бер догасы җиде мулланың бәддогасына җитә; Ана җылысы – кояш җылысы; Җәннәт аналарның аяк астында* һ.б. Монда анасын кадерләгән, хөрмәт иткән кеше генә бәхеткә лаек була алуы турында ассызыклана.

Татарларда баланың тәрбиялелек дәрәҗәсе һәм холкы, аның җәмгыятьтә үз-үзен тотышы бик еш әнисе белән бәйләп карала. Бу уңайдан берничә фразеологизмга тукталып узабыз: *анасыз нәрсә* (тиргәү; анасы булса да, тәрбия күрмәгән бала турында әйтелә); *ана куеныннан чыкмаган*, шулай ук *иренендә*

*ана сөте кипмәгән* (буйга-сынга үссә дә, тормыш тәҗрибәсе күрмәгән, хезмәт белмәгән, йомшак, иркә кешегә карата әйтелә); *ана сөте белән кергән* (кечкенәдән килүче берәр сыйфат турында әйтелә) һ.б. Гомумән, татар лингвомәдәниятендә *ана сөте* төшенчәсе аеруча мөһим урын алып тора. Ул халык авыз иҗатында да, матур әдәбият әсәрләрендә дә бик еш очрый. Мәсәлән: *ана сөте кебек хәләл* (берәр мал керү, кадер-хөрмәт күрүнең, яки мирас тиюнең бик урынлы булуы турында); *сөт (ана сөте) белән кергән соңгы сулыш белән чыгар* (ата-ана тәрбиясенең кеше гомеренә җитәрлек тәэсире турында).

Шулай итеп, *ана* татар халкы аңында игелек кенә түгел, изгелек, тугрылык белән тиңләнә, ана мәхәббәте көче галәм колачын ала, кояш җылысы белән тиңләштерелә, ә ана тәрбиясе алган кеше гомере буе әхлакый таләпләргә тугъры калыр, аларны төгәл үтәр.

Башка күпчелек төрки телләрдәге кебек үк татар телендә «ата» төшенчәсе *ата* (*АТА*) термины аша бирелә [4: 16]. Шунысы аерым игътибарга лаек: «ата» һәм «ана» сүзләре борынгы төрки язма ядкарьләребездә очрый. Мисалга XI гасырга караган М.Кашгарыйның «Диване лөгатет-төрк» һәм «Котадгу билиг»не китерергә мөмкин.

Татар телендә *ата* сүзенең мәгънәсе түбәндәгечә бирелә: Ата – гаиләдә: балалары булган ир кеше; әти [5:81]. Хәзерге көндә татар телендә *әти* дигән алгы рәт варианты ешрак кулланыла.

Күчмә һәм күчемсез милекнең бердәнбер хуҗасы булган ир-ат һәм ата кеше татар җәмгыятендә элек-электән гаилә тормышының төп мәсьәләләрен хәл итүдә өстенлекле хокукларга һәм гаиләдә кагылгысыз абруйга ия булган. Гаиләдә җитәкчелек һәм күзәтеп, тикшереп тору вазифасын нәкъ менә ир һәм ата башкарган.

Татар халкында иң хөрмәт ителгән нәрсәләрнең берсе – хезмәт. Традицион халык педагогикасында сабый чактан ук хезмәткә өйрәтү гаилә тәрбиясенең мөһим бурычы санала. Бала тууны зур бәйрәм буларак кабул итеп, аңа түбәндәге теләкләрне яудырганнар: *Атасы кебек уңган булсын; Анасы кебек тырыш булсын һ.б.*

Татар гаиләсендә ата улларын тәрбияләү өчен, ә ана кызлары өчен җавап биргән. Балаларны кече яшьтән үк хезмәткә өйрәткәннәр, алар, әти-әниләренә сабый чактан ук булышып килә: *Өч яшьлек малай атага булышыр, өч яшьлек кыз анага булышыр һ.б.*

*Ата* сүзенең «күпне күргән, азган, чыкылдап торган, төзәтеп булмаслык» дигән тагын бер коннотатив мәгънәсе бар, ул мәгънә фразеологиядә аеруча күп кулланыла, мәсәлән: *ата төлке* – бик хәйләкәр кеше, *ата карак* – караклар башлыгы һ.б.

*Ата-ана* парлы сүзе, вербөтен мәгънә төзеп, гомумән, фразеологиядә бик еш очрый. Татар теленең паремиологик фонды ата-аналарны хөрмәт итәргә, алар турында кайгыртырга өнди: *Алты көн ач калсаң да, атаңны кунак ит; Алтын-көмешнең искесе булмас, ата-ананың бәһасе булмас; Ачтан үлсәң дә, ата-анаңны ташлама; Ата – йортның матчасы, ана – йортның өрлеге, балалар – стенасы һ.б.* Әлеге тел берәмлекләрендә ата һәм ананың тигез хөрмәт ителүе, балалар тәрбияләүдә аларның тигез бурычлары тәкрарлана.

Без күзәтү ясаган тел берәмлекләре мисалында кыска гына түбәндәге нәтиҗәләрне ясарга мөмкин: татар телендә туганлык атамаларын белдерүче төп сүзләр башка төрки халыклардагы бу мәгънәне белдерүче сүзләр белән бер тамырдан; әлеге сүзләрнең бик күп еллар дәвамында шактый гына төрки халыклар тарафыннан шушы мәгънәдә кулланылуы мәгълүм; татарларда, башка төрки халыклардагы кебек, ата-ана һәм гаиләгә аеруча зур ихтирам белән карала.

**Әдәбият**

1. Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге / Төзүчеләр: Мәхмүтов М.И., Хәмзин К.З., Сәйфуллин Г.Ш. 2 томда. – Казан: Иман, 1993. – Т. 1. – 448 б.

2. Татары. – М.: Наука, 2001. – 583 с.

3. Этнография татарского народа / Под ред. Д.М.Исхакова. – Казань: Магариф, 2004. – 287 с.

4. Әхмәтьянов Р. Татар теленең кыскача тарихи-этимологик сүзлеге. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2001. – 272 б.

5. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. 3 томда. Том I. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1977. – 475 б.

# ЯҢАРТЫЛГАН ФЕДЕРАЛЬ ДӘҮЛӘТ БЕЛЕМ БИРҮ СТАНДАРТЫ ШАРТЛАРЫНДА БАШЛАНГЫЧ СЫЙНЫФЛАРДА ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЛӘРЕН ПРОЕКТЛАШТЫРУ

***Җамалетдинова З.И.***
***Өстәмә һөнәри белем бирү дәүләт автоном мәгариф учреждениясе***
***«Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты»***
***z.zamaletdinova@mail.ru***

***Аннотация.*** В статье рассматривается вопросы преподавания уроков родного (татарского) языка в условиях реализации обновленного ФГОС НОО и ФОП НОО. В ней представлены приемы и способы проектирования урока в начальной школе на основании Федеральной рабочей программы по учебному предмету «Татарский язык», приведен образец урока по татарскому языку в первом классе.

***Ключевые слова:*** обновленный Федеральный государственный образовательный стандарт, Федеральная рабочая программа, планируемые результаты, этапы урока, содержание урока.

Яңартылган Федераль дәүләт белем стандарты гамәлгә керү белем бирү процессын оештыруга шактый гына үзгәрешләр кертте. Барлык үзгәрешләр дә укучының шәхси үсешен күздә тотып кертелгән. Ә белем бирү процессы дәрестә һәм дәрестән тыш эшчәнлек аша алып барыла. Булган белем-күнекмәләргә нигезләнеп, укучыларның танып-белү, фикерләү, анализлау, дөньяны киң күзаллау сәләтен үстерү белем бирүне оештырганда үзәктәге төп проблема булып тора. Әлбәттә, иң элек без укучыга тиешле белемне дәрестә бирәбез, ә инде дәрестән тыш эшчәнлектә алган белемнәрне тирәнәйтәбез, киңәйтәбез, үстерәбез.

Яңартылган Федераль дәүләт белем бирү стандартының 5 нче пунктында башлангыч гомуми белем бирү программаларын үзләштерү нәтиҗәләренә ирешүдә, укучы шәхесен системалы һәм гармонияле үстерүне тәэмин итүдә системалы-эшлекле якын килү методы тора диелгән. Бу метод укучыга хәзерге җәмгыятьтә яшәү өчен дә, мәктәптә уңышлы уку өчен дә, шулай ук гомере буе үзлектән белем алуына уңышлы алым булып тора[1:5].

Системалы-эшлекле алымда төп урынны «эшчәнлек» категориясе алып тора, эшчәнлек нәтиҗәгә юнәлтелгән система буларак карала.

Диалогик принципка нигезләнгән эшлекле якын килү укучыларның актив хезмәттәшлеге, мәгълүмат алмашу, төрле карашлар турында фикер алышу процессында гамәлгә ашырыла. Шулай итеп, дәрестә укытучының төп бурычы — барлык укучыларны уку эшчәнлегенә җәлеп итү, чөнки яңартылган Федераль дәүләт белем бирү стандартының 26 нчы пунктында дәрес эчтәлеге, дәрестәге эшчәнлек гомуми белем бирү программаларын үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләренә ирешүгә юнәлдерелгән дип әйтелгән.

Бу таләпләрне исәпкә алып, яңартылган Федераль дәүләт белем бирү стандарты шартларында башлангыч сыйныфларда татар теле дәресләрен нәтиҗәле оештыру өчен һәрдаим укучылар белән тыгыз эшчәнлек алып бару күздә тотыла.

Дәресенең эчтәлеген планлаштырганда түбәндәге таләпләргә игътибар итү кирәк:

1) Дәреснең максатлары һәм бурычлары.
2) Планлаштырылган нәтиҗәләр.
3) Дәреснең кыскача эчтәлеге.
4) Уку эшчәнлеген оештыру төрләре.
5) Дәреснең төрле этаплары өчен укыту биремнәре.
6) Дәрес эчтәлеге һәм дәрестәге эшчәнлекнең тәрбияви потенциалы.
7) Белем бирү нәтиҗәләрен бәяләү өчен диагностик материаллар.

Татар теле дәресен Федераль эш программасы нигезендә проектлаштыру иң мөһим таләпләрнең берсе. Эш программасында аңлатма язуы, программа эчтәлеге, планлаштырылган нәтиҗәләр, тематик планлаштыру бүлекләре бирелгән.

Уздырыласы дәреснең программада тоткан урынын үзләштереп, дәресне оештыру методларын, укучылар эшчәнлегенә бирелгән характеристиканы исәпкә алып, дәресне проектлаштыру уңышлы нәтиҗәгә китерә.

Алга таба тәкъдим ителгән татар теле дәресе үрнәге татар мәктәпләре өчен ана (татар) теле буенча Федераль эш программасына нигезләнеп төзелгән.

**Татар теле,1 нче сыйныф.**

**Тема:** Тел – аралашу чарасы.

**Максаты:** татар теленең орфоэпик һәм интонацион таләпләрен саклап, телнең аралашу чарасы булуын аңлау күнекмәсе формалаштыру.

**Бурычлар:**

1. Дәреслек һәм аның төзелеше һәм эчтәлеге белән танышу аша телгә кызыксыну уяту.
2. Уку мәсьәлсен кую һәм чишү юлларын күнегүләр системасы аша ачу.
3. Адымлы нәтиҗәләр аша дәреснең темасын ачу.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

**Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр:**

– тарих һәм мәдәниятнең бер өлеше булган туган (татар) телен өйрәнү аша үз Ватаныңа карата кыйммәтле мөнәсәбәтләрне барлыкка китерү;

– туган (татар) тел системасы турында башлангыч күзаллаулар булдыру.

**Метапредмет нәтиҗәләре:**

*Регулятив универсаль уку гамәлләре* (РУУГ):

*Укучыларның уртак эшчәнлек осталыклары формалашу*:

– кыска сроклы максатларны (шәхси һәм күмәк эшчәнлек белән уку мәсьәләләрен чишкәндә катнашуны исәпкә алып) стандарт (гадәти) тәкъдим ителгән планлаштыруның форматы нигезендә, арадаш адымнарны бүлү;

– уртак эшчәнлекнең максатын кабул итү, күмәкләшеп шул максатка ирешү гамәлләрен билгеләү.

*Үзоешу күнекмәләре формалаштыру:*

– уку эшчәнлеге уңышының (уңышсызлыкларының) сәбәпләрен билгеләү.

*Танып – белү универсаль уку гамәлләре* (Т-б.УГГ):

*Төп тикшеренү гамәлләре*:

– укытучы ярдәмендә максатны формалаштыру максатын кабул итү, күмәкләшеп шул максатка ирешү гамәлләрен билгеләү.

*Мәгълүмат белән эшләү күнекмәләре:*

– уку мәсьәләсенә туры китереп, график, текст форматындагы мәгълүматны булдыру һәм анализлау:

*Коммуникатив универсаль уку гамәлләре (КУУГ):*

– куелган бурыч нигезендә сөйләм төзү;

– үз фикереңне төгәл һәм аргументлы итеп әйтә белү;

*Предмет нәтиҗәләре (*ПН*):*

– татар теленең орфоэпик һәм интонацион таләпләрен саклап, фикереңне әйтү;

– сайлап алынган гамәлләр эзлеклелеген булдыру;

– хәрефләрне, хәрефләр кушылмасын, иҗекләрне, сүзләрне, җөмләләрне гигиена нормаларын саклап аңлаешлы итеп язу [2:11-17].

**Тәрбиянең максатчан ориентирлары:**

*Гражданлык-патриотик тәрбия:*

– үзенең кече ватанын, туган ягын белүче һәм яратучы, туган иле – Россия, турында күзаллаулары булу;

*Фәнни танып белү кыйммәтләре:*

– танып белү мәнфәгатьләре, активлык, инициативалылык, кызыксынучанлык һәм танып-белүдәге мөстәкыйльлек (шул исәптән, туган (татар) тел) өйрәнүгә танып -белү кызыксынуы).

*Функциональ грамоталылыкны формалаштыру* (ФГ):

– уку ситуациясендәге эшчәнлегеннән тормыш ситуациясендәге эшчәнлеккә күчү сәләте формалаштыру.

**Электрон белем чыганаклары**: электрон дәреслек

| № т/б | Эшчәнлекнең төре | Укытучы эшчәнлеге | Укучылар эшчәнлеге | Планлаштырылган нәтиҗәләр |
|---|---|---|---|---|
| I. Мотивлаштыру –ориентлаштыру этабы | | | | |
| 1. | Мотивлаштыру. | *Әңгәмә үткәрү.*<br>– Сезнең кулыгызда нинди дәреслек? Исемен һәм авторын әйтегез.<br>Автор сезгә нинди | Дәреслек белән танышу.<br>Сорауларга җавап бирү. | *Шәхескә кагылышлы*:<br>тарих һәм мәдәниятнең бер өлеше булган туган (татар) телен өйрәнү аша үз Ватаныңа карата кыйммәтле мөнәсәбәтләрне |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | киңәшләр бирә? | | барлыкка китерү |
| 2. | 1 нче бүлек белән танышу. | *Бүлек эчтәлеге белән эш*<br>– Дәреслекнең алдагы битен карагыз. Бу биттә сез өйрәнәсе беренче бүлектәге темалар исеме бирелгән. Укып чыгыгыз.<br>– Темаларның исемнәрен әйтегез һәм ул темаларны өйрәнгәндә ничек уйлыйсыз сез нәрсәләр белерсез? | Тел турындагы бүлекнең эчтәлеге белән танышу.<br>Темаларның исемнәрен һәм аларның эчтәлеген фаразлау.<br>*1 нче нәтиҗә:*<br>Бу бүлек тел һәм сөйләм турында. Телдән һәм язма сөйләмне аерырга өйрәнербез. | *Шәхескә кагылышлы*: туган (татар) тел системасы турында башлангыч күзаллаулар булдыру.<br>*Метапредмет нәтиҗәләре (РУУГ):*<br>– кыска сроклы максатларны (шәхси һәм күмәк эшчәнлек белән уку мәсьәләләрен чишкәндә катнашуны исәпкә алып) стандарт (гадәти) тәкъдим ителгән планлаштыруның форматы нигезендә, арадаш адымнарны бүлү.<br>*Предмет нәтиҗәсе:*<br>– татар теленең орфоэпик һәм интонацион таләпләрен саклап, фикереңне әйтү |
| 3. | Уку мәсьәләсен кую. | *Уку мәсьәләсе кую өчен шартлар тудыру*<br>– Дәреслектәге уку мәсьәләсен укыгыз. Разил Вәлиевның “Туган тел” шигыре белән танышу.<br>– Дәреслектәге беренче шигырь белән танышыгыз, исемен һәм авторын әйтегез.<br>–Шигырь нәрсә турында?<br>–Сездә дәреслек авторы һәм Разил Вәлиев шигырен укыгач нинди теләк туды?<br>–Димәк, без ана (татар) теле дәресендә нәрсәләргә өйрәнербез? | Шигырьне уку, сорауларга җавап бирү.<br>*2 нче нәтиҗә:*<br>Татар теле дәресләрендә без туган телебездә грамоталы язарга, фикеребезне башкаларга җиткерергә өйрәнербез, туган телебезнең бик күп серләренә төшенербез.<br>*3 нче нәтиҗә:*<br>– Тел аралашу өчен кирәк.<br>– Туган (татар) теле дәресендә татар телендә аралашырбыз.<br>– Чөнки безнең | *Төп тикшерену гамәлләре*:<br>укытучы ярдәмендә максатны формалаштыру.<br>*Предмет нәтиҗәсе*:<br>– татар теленең орфоэпик һәм интонацион таләпләрен саклап, фикереңне әйтү. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | –Тел ни өчен кирә?<br>–Туган (татар) теле дәресендә сез нинди телдә аралашырсыз?<br>–Ни өчен туган тел дәресендә татар телендә аралашырсыз?<br>–Димәк, без бүген дәрестә нишләрбез? | туган (ана) телебез – татар теле.<br>**Уку мәсьәләсе (УМ):** Тел аралашу чарасы булганын күнегүләр аша үзләштерербез. | |
| 4. | Матур язу<br>күнегүләре | *Эш дәфтәрендә матур язу күнегүләре белән эшләү тәртибен аңлау*<br>Эш дәфтәрен ачыгыз. Нинди график элементлар бирелгән?<br>– Ул элементлар кайсы хәрефләрдә бар?<br>– –Нинди сүзләр бирелгән?<br>– Җөмләне укыгыз. Күчереп язу тәртибен искә төшереп күчереп языгыз. | Укучылар график элементларның язылышын искә төшерәләр, аларның кайсы хәрефләрдә барлыгын, күчереп язу кагыйдәләрен әйтәләр.<br>*Күчереп язу кагыйдәләре:*<br>1.Җөмләне укы.<br>2. Җөмләдә сүзләр санын билгеләгез.<br>3. Сүзләрне иҗекләргә бүл.<br>4.Сузык авазлар астында кызыл нокталар куй.<br>5.Җөмләдә баш хәреф булса, аның астына сыз.<br>6. Сүзләрне иҗекләп әйтеп яз. | *Предмет нәтиҗәсе:* хәрефләрне, хәрефләр кушылмасын, иҗекләрне, сүзләрне, җөмләләрне гигиена нормаларын саклап аңлаешлы итеп язу. |
| II.Уку мәсьәләсен чишү этабы | | | | |
| 4. | 1 нче күнегү. | *1 нче күнегү белән эш*<br>– 1 нче күнегүнең биремен укыгыз.<br>– Ничә бирем?<br>– Ничә бирем телдән? Ничә бирем язма? | Укучылар күнегүнең биремен эзлекле башкара.<br>Төшеп калган сүзләр: татар теле – анам теле, бабам теле, заман теле. | *Предмет нәтиҗәсе:* сайлап алынган гамәлләр эзлеклелеген булдыру. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | – Төшеп калган сүзләрне ничек таптыгыз?<br>– Димәк, аралашканда нәрсәгә игътибар итәсез? | Төшеп калган сүзләрне яңа фикер белдергәнне билгеләп таптык.<br>*4 нче нәтиҗә*: аралашканда әйтеләсе фикернең мәгънәсенә игътибар итәбез | |
| 5. | 2 нче күнегү | *Мәкаль эчтәлеген аңлату алымын куллану*<br>– 2 нче күнегүнең биремен сез ничек башкарырсыз?<br>– Сезгә нәрсә ярдәм итәр?<br>– Мәкальләр эчтәлегендә ничә фикер?<br>– Кайсы сүзләр мәкальнең төп эчтәлеген күрсәтә? | – Укучы биремне башкару өчен 4 нче нәтиҗәдән файдалану алымын аңлата.<br>– Мәкальләр эчтәлегендә 3 фикер:тел – белемле булу өчен ачкыч, акыллы гамәлләр күрсәтергә, белемгә омтылырга баскыч. Икенче мәкальдә сүзләрне урынлы, мәгънәсен туры китереп сөйләшкәндә аларны телнең матурлыгы диләр.<br>– Ачкыч, баскыч,тел күрке.<br>*5 нче нәтиҗә*:<br>Мәкальләрнең төп эчтәлеген ачарга аерым төп эчтәлекне эченә алган сүзләр ярдәм итә. | *Коммуникатив универсаль уку гамәлләре:*<br>куелган бурыч нигезендә сөйләм төзү;<br>*Предмет нәтиҗәсе*:<br>– татар теленең орфоэпик һәм интонацион таләпләрен саклап, фикереңне әйтү. |
| 6. | 3 нче күнегү | *Укытучы укучыларга сорауларга җавапны мөстәкыйль язарга, дөреслеген парлап тикшерергә тәкъдим итә.* | Укучылар сорауларга җавап яза, парлап дөреслеген тикшерә.<br>*6 нчы нәтиҗә:*<br>Тел – аралашу | *Укучыларның уртак эшчәнлек осталыклары формалашу:* уртак эшчәнлекнең максатын кабул итү, күмәкләшеп шул максатка ирешү гамәлләрен билгеләү. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | – Сез тел турында фикерегезне бер җөмлә белән әйтегез.<br>– Ничек белдегез? | чарасы.<br>Ысул:<br>• телнең аралашу вакытында кулланышын күзәттек;<br>• аралашканда фикергә игътибар иттек;<br>• телнең төп мәгънәсен ачыкладык, нәтиҗә ясадык. | *Предмет нәтиҗәсе*:<br>татар теленең орфоэпик һәм интонацион таләпләрен саклап, фикереңне әйтү.<br>*Функциональ грамоталыкны флормалаштыру:* уку ситуациясендәге эшчәнлектән тормыш ситуациясендәге эшчәнлеккә күчү сәләте формалаштыру |
| 7. | 4 нче күнегү | *Укытучы биремне мөстәкыйль эш өчен тәкъдим итә.* Укучылар күнегүне сыйныфта яки өйдә мөстәкыйль башкаралар.<br>– Биремне укыгыз. Кем эшли алам ди, кулларыгызны күтәрегез.<br>– Рәхмәт, һәркайсыгыз мөстәкыйль эшләгез.<br>Тикшерү:<br>– Рәсемнәргә карагач, нинди фикер туды?<br>– Сез аралашканда нинди мәгълүмат бирерсез?<br>– Рәсемнәрне җөмләләр белән тоташтырырга нәрсәгә игътибар иттегез? | Укучылар мөстәкыйль эшчәнлеккә әзерлекләрен күрсәтә.<br>– Рәсемнәрне карагач туган ягыбыз, туган телебез турында сүз барганын белдек.<br>– Без Казан, татарларының туган теле, милли ризыклары, милли киемнәре турында сөйләшербез.<br>– Рәсемнәрне һәм җөмләләрне тоташыру өчен аларның эчтәлегенә игътибар иттек. | *Мәгълүмат белән эшләү күнекмәләре:* уку мәсьәләсенә туры китереп, текст форматындагы мәгълүматны булдыру һәм анализлау |
| 8. | 5* нче күнегү | *Укытучы 5* нче күнегүнең максатын аңлата*<br>– 5* нче күнегүгә игътибар итегез. | Укучылар күнегүнең бирелешен күзәтә, башка күнегүләр белән чагыштыра. | *Предмет нәтиҗәсе*:<br>татар теленең орфоэпик һәм интонацион таләпләрен саклап, |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Башка күнегүләрдән ул нәрсә белән аерыла?<br>– Нинди фикерләр бар?<br>– Укытучы: «*» тамгасы белән бирелгән күнегүләр теләк буенча башкарыла. Алар укучыдан дәрестә алынган белемне яңа шартта куллануны таләп итә.<br>– Без бүлекләрне үтеп бетергәч, сезнең «*» тамгасы белән эшләгән күнегүләр буенча нәтиҗә ясарбыз. | *7 нче нәтиҗә:*<br>5* нче күнегү «*» тамгасы белән бирелгән. Андый күнегүләрне укучы ирекле, теләк буенча башкара. | фикереңне әйтү. |
| III. Рефлексив – бәяләү этабы | | | | |
| 1. | Рефлексив кабатлау. | *Дәрескә нәтиҗә ясау*<br>– Нәрсә белдек?<br>– Ничек белдек?<br>– Дәреснең кайсы өлеше сезгә җиңел бирелде?<br>– Дәреснең кайсы өлешендә сез кыенлык кичердегез?<br>– Ни өчен?<br>– Сезгә ул авырлыкны җиңәр өчен нишләргә кирәк? | Укучылар сорауларга җавап биреп, дәрескә нәтиҗә ясый.<br>*8 нче нәтиҗә*:<br>Дәрестә уку материалын аңлау өчен адымлап, үз эшчәнлегеңне контрольдә тотарга, нәтиҗәләрне уку мәсьәләсе белән бәйләргә кирәк. | *Метапредмет нәтиҗәләре (РУУГ*):<br>*Үзоешу күнекмәләре формалаштыру:*<br>– уку эшчәнлеге уңышының (уңышсызлыкларының) сәбәпләрен билгеләү.<br>*Предмет нәтиҗәсе:*<br>– татар теленең орфоэпик һәм интонацион таләпләрен саклап, фикереңне әйтү. |
| 2. | Бәяләү. | *Укучылар эшчәнлеген бәяләргә өйрәтү*<br>– Кем бүген дәрес материалын аңладым, ди, кулларыгызны күтәрегез.<br>– Ни өчен шундый | Укучылар дәрестә үз эшчәнлекләрен бәялиләр. | *Коммуникатив универсаль уку гамәлләре:* үз фикереңне төгәл һәм аргументлы итеп әйтә белү;<br>*Предмет нәтиҗәсе*:<br>татар теленең орфоэпик һәм интонацион |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | нәтиҗә ясыйсыз?<br>– Кем дәрес материалын аңлап бетермәдем, ди?<br>– Кем дәрес материалын тулысынча аңламадым, ди? | | таләпләрен саклап, фикереңне әйтү. |
| 3. | Модельләштерү | Дәрестә алган белемнәрегезне кыскача гомумиләштереп схемада күрсәтегез. | Укучылар дәрестә алган белеменәрен модельләштерәләр.<br><br> | *Мәгълүмат белән эшләү күнекмәләре*:<br>уку мәсьәләсенә туры китереп, график, форматтагы мәгълүмат булдыру<br>*Предмет нәтиҗәсе:*<br>сайлап алынган гамәлләр эзлеклелеген булдыру |

## Әдәбият


1. Федеральный государственный образовательный стандарт начального общего образования (утвержден Приказом МП РФ от 31.05. 2021 г. № 286) URL: https://fgosreestr.ru/educational_standard/federalnyi-gosudarstvennyi-obrazovatelnyi-standart-nachalnogo-obshchego-obrazovaniia-2 (дата обращения: 10.02.2024).

2. Федеральная рабочая программа учебного предмета «Родной (татарский) язык» для 1–4 классов начального общего образования для общеобразовательных организаций с обучением на родном (татарском) языке. — URL: https://static.edsoo.ru/projects/fop/index.html#/sections/100200346 (дата обращения: 08.02.2024).

# СИНОНИМЫ В ВЫРАЖЕНИИ ПАЖЕЛАНИЙ В ТАТАРСКОЙ РЕЧИ

***Замалетдинов Р.Р., Денмухаметова Э.Н., Нурмухаметова Р.С.***
***Казанский федеральный университет***
***sovet.rus16@gmail.com, denmukhametova@gmail.com, rsagadat@yandex.ru***

***Аннотация.*** В материале представлены лексические единицы, составляющие синонимичные пары в пожеланиях татарской речи. В рамках прагматического подхода в изучении лексических единиц пожеланий рассматриваются как лингвистические, так и экстралингвистические параметры речевых действий, анализируемых как инструмент социального воздействия на собеседника.

***Ключевые слова***: синонимия, татарский язык, татарская речь, пожелания, поздравления.

Лексический состав татарского языка, как и любого тюркского языка, богат на слова синонимы, которые появились по разным причинам, в том числе благодаря тонкому чутью народа той или иной ситуации и для передачи смысловых оттенков лексических единиц и их сочетаний. Некоторые из них имеются и в родственных языках, но большинство различаются, так как полностью понятны лишь тому менталитету народа, в чьей речи они появились. Благодаря этим лексическим единицам можно достичь апогея выразительности речи, выразить тонкий намек, не обижая собеседника, и отомстить, не причиняя вреда и т. д. Синонимические отношения единиц татарского языка являются одним из интересных объектов исследования как для лингвистов, филологов, так и для социологов, психологов и этнографов. Вопросы лексической синонимии в теоретическом и практическом плане уже рассматривались в многочисленных трудах отечественных и зарубежных исследователей. В них исследуются как общие вопросы развития языковой системы и описываются частные формы обогащения того или иного языка, изучаются изменения в лексическом фонде того или иного языка исходя из экстралингвистических и интералингвистических факторов речи, даются лингвокультурные и социокультурные характеристики лексическому составу языка в связи с вышеуказанными причинами. Синонимичные единицы татарского языка изучены и в историко-лингвистическом аспекте, и в сравнительном и сопоставительном плане, и в лингвокультурологическом аспекте] и др. Несмотря на многочисленные труды, область исследований синонимов не исчерпана. В данной работе слова синонимы рассматриваются как лексические единицы, выражающие пожелания и определяющие тончайшие оттенки татарской речи, и ведь лексическая синонимия в татарской речи на примере пожеланий исследуется впервые.

Объектом данного исследования выступают лексические едтницы, зафиксированные в текстах пожеланий на татарском языке. Предмет

исследования - синонимические связи между лексем литературного языка и их вариативностью в устной речи.

Цель работы - выявление особенностей слов синонимов в определении перформативной парадигмы речевого акта «пожелания» в татарском языке.

Исходя из поставленной цели, сформулированы следующие задачи работы: дать определение и характеристику речевому акту "пожелание" и узнать основные свойства отличающие его от других единиц речевого этикета; рассмотреть доминантные особенности коммуникативного поведения, реализующие речевой акт пожелания, в тюркской культуре; выявить семантические особенности лексических единиц, используемых в разных контекстах пожеланий; расмотреть особенности вариативности устойчивых выражений с семантикой пожелания, определить возможности взаимозаменяемости таких синонимов в потоке речи.

Источником исследования является словарь синонимов татарского языка, сборник текстов и сайтов поздравлений и пожеланий, так же фактический материал исследования взят из Национального корпуса татарского языка "Туган тел" [http://litcorpus.antat.ru/index.htm] и Корпуса татарской художественной литературы [http://litcorpus.antat.ru/index.htm].

В рамках исследования в основном применялся описательный метод. Для определения хронологии и последовательности языковых процессов использовался сравнительно-исторический метод. Для анализа частотности и регулярности словоупотребления лексических единиц применен статистический метод. Также методологическую базу исследования составляют: подход, определяющий единство деятельности и сознания; аксиологический, культурологический, герменевтический подходы, позволяющие интерпретировать лексико-семантические особенности лексической синонимии в татарской речи.

Пожелания относятся к экспрессивным речевым актам, т.к. их объединяет единая выполняемая ими функция выражения отношения говорящего к определенной ситуации или поведению адресата в соответствии с нормами, принятыми в данном обществе. В полной мере выполняют эту функцию и пожелания, целью которых является выражение чувств и отношения говорящего с намерением вызвать чаще всего положительную реакцию адресата. Таким образом пожелание как действие, связанное с реакцией на поведение людей и предназначенное выражать межличностные отношения, принадлежит к классу экспрессивов. Прежде чем дать определение речевому акту пожелания и определить круг высказываний, реализующих данный речевой акт, имеет смысл обособить речевой акт пожелания от акта поздравления, так как эти речевые действия чаще всего сопутствуют друг другу. В некоторых ситуациях пожелания в татарском языке соответствуют поздравлениям в русском или в других языках. Например, поздравления на Новый год, День рождения. Но существуют и такие варианты как "Нәүрүз мөбәрәк булсын!/ Пусть будет благословенным Навруз!; Җомга мөбәрәк булсын!/ Пусть будет благословенным пятница!" Данные высказывания

являются косвенным речевым актом поздравления, хотя обладают первичной иллокутивной силой пожеланий. Несмотря на то, что две эти языковые единицы используются преимущественно как поздравления, функционировать они могут в обоих качествах: выступает в качестве пожелания после выражения поздравления.

Таким образом, речевой акт поздравления - это вежливое речевое действия, которое реализуется говорящим с целью выразить свою радость по поводу настоящего события, соответствующего интересам адресата.

В ходе исследования было проанализировано примерно 3400 высказываний на татарском языке. Выявлено, что разница между пожеланиями и поздравлениями лежит во временной референции. Несмотря на то, что повод для их реализации может быть одним и тем же, относятся они к разным аспектам данного события. Высказывая пожелание, говорящий выражает надежду на благополучие в жизни адресата в будущем, поздравлением же говорящий дает понять адресату, что он радуется вместе с ним по поводу настоящего приятного события. Выражаемую говорящим в обоих случаях симпатию можно охарактеризовать при поздравлениях как "радость вместе с адресатом" и при пожеланиях как выражение надежды говорящего. Таким образом, речевой акт пожелания - это речевое действие, которое реализуется говорящим с целью выразить надежду на определенное положение дел в жизни адресата в будущем с тем, чтобы проинформировать его об оценке говорящим свойств или действий адресата или ситуации в целом.

Древние народы много веков назад считали, что мысль материальна. Считалось, что слова обладают таинственной магической силой, способной оказывать влияние на судьбу человека. Эти воззрения находят отражение в возникновении различного рода речевых формул проклятий и благопожеланий, представляющих собой жанры ритуальной речи, не утратившие своей силы у многих современных народов. Поэтому, тюркские народы верят, что слова проклятия или оброненные в сердцах негативные пожелания влекут за собой болезни, различные беды и даже смерть. И напротив, слова доброго пожелания и благословения привлекают по отношению к тому, кому они адресованы, счастье и благополучие.

Отношение к слову на ранней стадии развития тюркского общества было таким же трепетным, как и к любому окружающему его предмету, всему живому вокруг. Согласно представлениям древних тюрков, с правой стороны человека стоит добрый ангел, а с левой - злой. По этой причине, вставая с постели, обуваясь или снимая обувь, следовало начинать с правой ноги, в противном случае человека ожидали неудачи. Под влиянием этих воззрений слово правый у татар, как и у многих тюрков, получило значение всего позитивного, справедливого. У тюркских народов слово un (правый) является синонимом удачи, успеха в предстоящих делах: уң аяктан тор/ вставай с правой ноги; уң аягыңны ки /обувайся с правой ноги;уң аяктан чык/ выходи с правой ноги; уң кул белән ал /бери правой рукой; юлың уң булсын /удачи в пути; эшегез уң булсын/ да сопутствует вам удача в делах.

С развитием общественного сознания слово сохраняет свойства психологического воздействия на человеческое сознание, обнаруживая незримое сходство с магией слова в древности. Слова добрых пожеланий, благословения, пожеланий здоровья направлены на привлечение в адрес получателя счастья, успеха в делах, благополучия и используются в наши дни преимущественно в силу языковой традиции. К ним относится следующие выражения - синонимы: провожая человека в дальний путь, желать ему благополучие: хәерле сәгатьтә булсын /в добрый час – юлың уң булсын / в добрый путь; аk юллар / белого пути - юлыңа ак җәймә/ белой тропинки тебе.

Можно услышать такие пожелания как, пожелания-поздравления, тосты, пожелания-предписания, благословения. Хотя высказанные пожелания в основном выражаются в честь кого-либо или по какому-либо случаю, событию, существуют клише формы, используемые в готовом виде. В составе таких форм встречаются и фразеологические единицы. Например, аавызыңа бал да май/ твоими устами да мед пить; јйомшак сүз// яхшы сүз – җылы сүз- доброе слово; тәмле төшләр – татлы төшләр /приятных сновидений; тыныч йокы - спокойной ночи и другие.

Татары, как представители восточной нации, любят выражать свои пожелания с красноречием, множеством эпитетов, сравнений. В их числе есть такие, которые превратились в устойчивые выражения и зафиксированны в словарях фразеологизмов. Например, саф күңелдән - от всей души // ихлас күңелдән – от чистого сердца (в значении искренне);ак бәхетләр теләү –желать безоблачного счастья или его синоним керсез бәхетләр язсын – пусть будет чистым счастье (желать большого счастья); аяягында нык тор – твердо стой на ногах// аягыңа бас – встань на свои ноги (в значении накопи капитал) и др.

Так как татары являются в основном проповедниками Ислама, в их речи, в том числе и пожеланиях, часто встречаются такие синонимы как аk / белый, пакь/ чистый, керсез/ чистый. Например желают аk бәхетләр/белого счастья; пакь күңел/ чистой души; керсез мәхәббәт / чистой любови и др.

Выявлено, что существует несколько основных ситуаций применения стандартных клишированных пожеланий в татарском языке. Например, по тематической линейке существуют следующие предпосылки пожеланий, где ярко видны синонимичные варианты.

Воспитанность говорящих ярко проявляется поздравлении. Слово kotliym/поздравляю часто опускается, как и в русском языке: бәйрәм белән/с праздником; Яңа ел белән/ С Новым годом; туган көнең белән/ С днем рождения; Җиңү көне белән /С Днем Победы.

При рождении ребенка поздравление сопровождается следующими пожеланиями: озын гомерле булсын/ пусть будет долголетним; тәүфигы белән тусын / пусть родится порядочным; мөбәрәк булсын /усть будет величавым.

Поздравления с обновkой также сопровождаются пожеланиями типа котлы булсын/ пусть будет счастливым),җылы тәнендә тузсын/ пусть износится на твоем теплом теле; өстәүле мал булсын/ пусть будет одежда с добавлениями; рәхәтен күрергә язсын / пусть придется испытать удовольствие;

игелеге белән булсын/ пусть будет с добротой, с добром; өстеннән өстәлсен /пусть добавится; өстеңдә тузарга язсын /пусть доведется износить его на себе.

При поздравлении имеются и слова синонимы, выражающие степень добрых пожеланий: чын күңелдән тәбрик итәм (kотлыйм)/ от чистой души поздравляю; чын йөрәктән тәбрик итәм / от чистого сердца поздравляю.

Добрые пожелания всегда имеют место в разговоре. При виде обедающих обычно говорят: тәмле булсын/ пусть будет вкусным; ашларыгыз (чәйләрегез) тәмле булсын / пусть будет вкусной ваша еда (чай).

Если кто-то начинает первый работу, то ему говорят: кулың җиңел булсын / пусть будет легкой твоя рука; kул-аягың җиңел булсын /пусть будут легкими твои рука-нога; авызыңнан җил алсын/ пусть ветер унесет из твоего рта плахое.

При виде работающих иногда говорят Алла куәт бирсен / пусть аллах даст силы; Алла ярдәм бирсен/ пусть аллах даст помощи; куәтегез күп булсын/ пусть вашей силы будет много; эшләр уңсын/ пусть дела будут удачными. Начало самой работы сопровождается синонимичными выражениями типа Аллага тапшырдык/ передали Аллаху; тапшырдык /передали; хәерле сәгатьтә / в добрый час.

Пожелание долголетия выражаются синонимичными репликами: йөз яшә/ живи сто; мең яшә/ живи тысячу; күп яшә /живи долго; озын гомерле бул/ будь долголетним.

Известно и то, что выражая надежду на будущее исполнение пожелания, говорящий при этом не побуждает адресата к какому-либо действию и не берет на себя ответственность за его осуществление.

В исследуемом материале были выявлены как синонимичные отношения среди фразеологизмов с разными компонентами, так и среди устойчивых выражений, где изменен (добавлен, опущен) лишь один компонент. Например, ихтирам күрсәт // хөрмәт күрсәт //ригая кыл // кадер күрсәт – окажи уважение, где меняется компоненты, однако семантика полностью сохраняется. В примерах истә тот - запомни// истә сакла – оставь в памяти // истә калдыр - сохрани в памяти, где меняется глагольный компонент фразеологизма, а значение также полностью сохраняется.

Пожелания в конкретных ситуациях речевого общения реализуются в дискурсе, который характеризуется адресованностью, контекстностью и динамикой, т.е. является сложным коммуникативным событием, находящемся в непосредственной зависимости от ряда экстралингвистических факторов - установок, целей, личностных и социальных характеристик интерактантов, ситуативного контекста.

Дискурс характеризуется определенной структурой, сегменты которой могут варьироваться в зависимости от внешних или внутренних модификаторов. Особые различия проявляются в структурах устного и письменного дискурсов, что обуславливается их характеристиками. Устный дискурс обладает большей спонтанностью, в случае письменного дискурса у коммуниканта больше времени на обдумывание стратегии достижения цели,

поэтому основное различие между устным и письменным дискурсом лежит в их структуре.

Примеры татарского устного дискурса были рассмотрены на примерах диалога в художественных произведениях. Зафиксированные примеры показали, что синонимичные лексические единицы во время диалога приобретают дополнительные оттенки семантики, которые не зафиксированы в словарях. Например, илһам чыганагы – источник вдохновения. В диалогах можно встретить следующие вариации: илһам коесы – ключ вдохновения // зихен тулылыгы – полната мысли// илһамлану – вдохновляться // илһам чыганагы – источник вдохновения. Это объясняет широту использования лексем и их зависимость от контекста.

Проведенное исследование позволило выявить основные особенности лексических единиц с семантикой пожелания, входящих в состав активной лексики современной татарской речи. Исследование и наблюдение синонимических связей между этими лексемами позволили сформулировать следующие выводы:

1. Несмотря на общетюркское начало, в зависимости от экстралингвистических и интералингвистических факторов каждый язык меняется и вступает в разные взаимоотношения с другими, поэтому в появлении синонимичных отношений между лексемами, выражающих пожелания, имеют места лексемы с разных языков, даже целые устойчивые выражения со компонентами иноязычной лексики.

2. Основную массу синонимов в пожеланиях татарского языка, все же составляет общетюркская лексика с разными оттенками семантики, где отражается национальная специфика, ментальные особенности татар.

3. Речевое поведение на татарском языке обуславливается опытом индивида, который зависит от исторического и культурного контекстов и формируется моральными, социальными нормами, а также находится под влиянием особенностей национальной культуры. Традиция желать кому-либо что-либо со временем претерпевают большие изменения, однако основные клише в пожеланиях сохраняются , и они выражаются разными лексическими единицами- синонимами..

Таким образом, синонимическая система татарского языка, как одного из тюркских языков развивается и меняется, которая отражается как в устной, так и в письменной речи. Об этом мы можем утверждать и относительно лексического фонда, зафиксированного в словарях и корпусах татарского языка. Общетюркский лексический фонд, как единая система является относительно устойчивой, но новшества в общественной, социальной жизни, прогрессивные технологии вносят свои коррективы и в эту систему. Поэтому появления новых синонимов не должно никого удивлять, а должно помощь умело выбирать стилистически верные варианты.

## Литература

1. Ханбикова Ш., Сафиуллина Ф. Синонимнар сүзлеге.- Казан: Хәтер, 1999.- 256 б.
2. Котлау һәм теләкләр. – Казан: Ихлас, 2009. – 248 б.
3. Татарча теләкләр. //https://wpoz.ru/pozhelaniya-na-tatarskom-yazyke/ (дата обращения 16.09.2023)
4. Татарча котлаулар // protatar.ru/pozdravleniya-muzhchine-na-tatarskom-yazyke/ ( дата обращения 05.10.2023)

# КИЛӘЧӘК БАЛАЛАРЫН ТӘРБИЯЛӘҮ

***Заһретдинова Г. Г.***
***Тукай районы Татарстан поселогы***
***golsina-1970@mail.ru***
***Хәертдинова Х. Г.***
***Лениногорск шәһәре***
***halisa2011@yandex.ru***

***Аннотация.*** В статье рассматриваются вопросы воспитания молодого поколения.

***Ключевые слова:*** воспитание, татарский язык, Р.Фахретдинов.

Татар халкының бөек галиме Ризаэддин Фәхреддин "Дөньяга килгән сәгать белән балалар тәрбиягә мохтаҗлардыр" дип язган. Бу фикер белән килешми мөмкин түгел. Һәр гаилә үзенең баласын тәрбияле, матур гадәтләргә ия итеп күрәсе килә. Аңа ничек ирешергә соң? Бу сорау бик күпләрне борчый, аңа җавапны әби-бабайлар да, әти-әниләр, тәрбияче, укытучылар да, галимнәр дә эзли, тапкан җавапларын тормышта сынап карый.

Тәрбия, тәрбияләү, тәрбияче сүзләрен еш ишетергә туры килә. Нәрсә сон ул тәрбия? "Тәрбия – акрынлык вә тәртип белән камиллек булдыру димәктер" дип җавап бирә безгә галимебез үзенең "Әдәбе тәгълим" исемле китабында. Баланы тәрбияләү өчен кем, нәрсә кирәк? - дигән сорау да туа. Аңа да җавап әзер: "Тәрбияле аналар һәрвакыт балаларының холыкларын күркәм итәргә бик тырышырлар". "Алтыннан да кыйммәтле, оҗмах нигъмәтләреннән дә кадерле булган нәрсә - тәрбияле баладыр. Ата һәм ана өчен тәрбияле бала кебек олы байлык һич булмас. Тәрбияле бала дөньяда җанга шатлык һәм ахирәттә йөзгә аклык китерер. Тәрбияле бала – дөнья байлыгына да бирелми һәм бер дәүләт патшалыгы белән дә алыштырылмас – аны һәркем яратыр һәм мактап телгә алып сөйләр, ни сораса да бирерләр.

Тәрбиясез баланы бер кеше дә яратмас, йомыш кушмаслар, бәяхас хурларлар вә кимсетерләр генә". Кайсы әти-әнинең үз баласын тәрбиясез итеп күрәсе, яки башкаларга күрсәтәсе килсен икән? Андый кеше юктыр ул, булырга да мөмкин түгел. Чөнки бала - гаиләнең дәвамчысы, аларның күңел көзгесе, ә көзгедән барыбызның да матурлыкны гына күрәсебез килә. Ә менә борын-борын заманнардан килгән тәҗрибә шуны күрсәтә, дөньяда ничә кеше булса, шулкадәр холык, шулкадәр төрле кеше яши. Хәтта бер карында яткан балалар гына түгел, бер тамчы судай бер-берсенә охшаган игезәкләр дә төрле була. Шуңа да карамастан, һәр ата-ана үз баласын һәрьяктан камил шәхес итеп күрергә тели, шуңа омтыла, тырыша. Аларга ярдәмгә ашыгучылар да бихисап, гаиләдә әби-бабайлар да бар бит әле, ә алар буыннар дилбегәсен тотучылар, күңел матурлыгын баетучылар, рухи азык бирүчеләр. Буыннан-буынга, гасырдан-гасырга сакланып калган гореф-гадәтләр аша тәрбия орлыклары чәчүчеләр дә алар.

“Тәрбия – акрынлык вә тәртип белән камиллек булдыру димәктер... Тәрбиясе булмаган җирдә гүзәл ашлык җитешмәгән кебек, тиешле тәрбия бирелмәгәндә гүзәл кеше дә җитешмәс. Шулай икән, тәрбия иң кирәкле бер эш булачактыр”, дигән юллар безнең фикеребезне дәлилли кебек.

“Барча кешеләрне дөньяга китерүчеләр аналардыр. Моны үзегез ачык беләсез. Ләкин бу кешеләрдән кайсы усал, кайсы яхшы, кайсы әдәпле, кайсы белемсез булмакталардыр. Халыкның (кешеләр, адәм балалары) яхшы вә усал булмакталарында күп вакытта аналарның катышы буладыр, - дип язган Р.Фәхреддин “Тәрбияле ана” китабында. - ... Аналарның хезмәтләре иң авыр вә иң мәшәкатьле хезмәттер, аны язып бетерерлек, тел илә сөйләп бәян кыйлырлык түгелдер...” , - дигән юллар бернинди бәхәс тә уятмый, без бу фикерләрне тулаем кабул итәбез, аларны дәлилләп тә торасы юк. Бу юлларны укучы, я тыңлаучы күңелендә шик-шөбхә уянмыйдыр, чөнки баланы багучы, караучы, тәрбияләүче, авырса, җанын бирергә әзер торган аналар булмаса, тормыш туктап калыр иде. Балалар бакчаларында, мәктәпләрдә, башка уку-укыту йортларында эшләүчеләрнең дә иң күбесе хатын-кызлар, алар да аналар бит.

Бала үсү барышында дөнья белән таныша башлый, аның кечкенә куллары әнисенә үреләә, матур бизәкле елтыравыклы уенчыкларга күзе тиз төшә, аларны тотып карыйсы, “кабып карыйсы” килә. Димәк, ул беренче минутларыннан матурлыкны, гүзәллекне таный, аны үзенеке итәсе килә. Шул минуттан алып ул үзе дә, эчке дөньясы да матурлыкка байый.

“Кешенең матурлыгы – аның тәрбияле, эшчән, намуслы булуында, олыларны олы итеп, кечеләрне кече итеп яши белүендә” дип яза Риза Фәхреддин “Балаларга үгет-нәсыйхәт” әсәрендә. Игътибар итсәк, бу юлларда кешедә булган гүзәл сыйфатлар бер-бер артлы саналып кителә, димәк, алар һәр кешедә дә булырга тиешле сыйфатлар. Чынлап та, кешенең тышкы матурлыгы гына җитми, эчке матурлык, зәвык та бик кирәк, аларны булдыру өчен, балалар бакчаларында тәрбияләнгән вакытта, мәктәптә уку елларында тәрбиячеләр, укытучылар зур көч куялар, бу сыйфатларны булдыру өстендә армый-талмый көч-хезмәт куялар, тәрбия сәгатьләре алып баралар, эти-әниләр белән әңгәмәләр оештыралар.

Матурлык дөньяны үзгәртә дигән фикер яши. Матур булу гана җитми, аның янында янәшәдә кешенең күңел чисталыгы, ярдәмчеллек, изгелек эшләргә әзер булуы да камил шәхес өчен кирәкле сыйфатлар бит. Олыларны кадерләп, кечеләрне хөрмәт итеп яши белгән шәхес тәрбияләргә кирәк. Аңа ничек ирешергә соң? Аларны булдыру өчен күп көч куярга да бәлки кирәкмидер, кешелек кануннары белән үзең дөрес яшәсәң, үз тәҗрибәң белән дә баланы тәрбияләп була. «Балаларны изге итү юлы ничек? Изге балалар күктән килмиләр, бәлки гаиләләр эчләрендә җитешәләр. Аның юлы исә яшь вакытлардан башлап, яхшы тәрбия бирүдер. Бу ата вә ана өстендә иң олуг бурыч… Балаларны яшь вакытларыннан башлап, мөхмәл тоту, бозык кешеләр кулларына бирү, урам балалары берлә йөртү тиешсез эш. Балалар һәртөрле язу язылуы кабил булган ак кәгазь вә яки хәртөрле нәрсәнең сурәте күрелергә

мөмкин булган көзгеләрдер. Шунын өчен мөмкин кадәр яхшы язу язылу вә мәргүб рәсемнәр төшерелү лязим. Монларның тәрбияләренә тәмам бирелү, яхшы кеше булып җитешүләре өчен бөтен иждихадны сарыф итү тиешле». “Изге балалар күктән килмиләр, бәлки гаиләдә җитешәләр. Аның юлы яхшы тәрбия бирүдә. Бу эш ата-аналар өстендә иң олуг бурыч. Балаларның тәрбияләренә тәмам бирелү, яхшы кешеләр булып җитешүләре өчен бөтен иҗтиһатны сарыф итү тиешле” дигән җавапны галимнең 1916 нчы елда ук язган “Җәвамигуль –кәлим шәрхе” әсәреннән табабыз. Безне бүген борчыган сораугa йөз ел элек үк инде җавап бирелгән, ә сораулар бүген дә бер-бер артлы туып кына торалар. Димәк, тәрбия өлкәсендә сораулар ничәнче гасырда яшәвебезгә карамастан булган, бар, булачак та әле. [3:602].

Ризаэддин Фәхреддин үзенең тормышын тәрбия өлкәсенә багышлый, бик хезмәтләр яза. Инде күптән бакыйлыкта булуына карамастан, аның хезмәтләре тәрбиячеләр, укытучылар, зыялы ата-аналарның өстәл китабына әверелде. Бик күп еллар элек үк бөек фикер иясе, күренекле мәгърифәтче, мәшһүр педагог, тарихчы, язучы, дин әһеле, галим Ризаэддин Фәхреддин: “Балаларыгызны үзегезнең заманыгыздан башка бер заман өчен укытыгыз, чөнки алар сезнең заманыгыздан башка бер заманда яшәү өчен дөньяга килгәннәр,” – дип язып калдыра. Аның бу үтә файдалы киңәше бүгенге көндә дә бик актуаль яңгырый. Алдан күрү сәләте белән язылган хезмәтләре киләчәк заманда яшәячәк балалар, алар һәрчак яшьләр, эти-әниләр, тәрбиячеләр һәм укытучылар өчен язып калдырылган алтын кагыйдә кебек яңгырый. Алар бүгенге көндә безне борчыган сорауларга җавап биреп кенә калмыйча, алда туасы көннәрдә дә актуальлеген югалтмыйча, киләсе гасырлар кешеләренә дә хезмәт итәрләр, аларның сорауларына да җавап бирерләр.

Р.Фәхреддин – күпкырлы талантлы шәхес. Ул тарих, философия, җәмгыять белеме, педагогика, логика, психология, әдәбият, тел белеме, библиография, сәнгать, география, этнография, археология, археография, генеология, эпитафия, медицина, нумизматика, юриспруденция, астрономия, халык авыз иҗаты, дин тарихы һәм башка фәннәр белән кызыксынган һәм алар буенча күпсанлы хезмәтләр язып калдырган. Күренекле шәхеснең язган хезмәтләрен өйрәнеп, киләчәк буыннарга түкми-чәчми җиткерә алсак иде дигән фикердә без.

Галим Фәхретдиннең көн күргән, яшәгән, иҗат иткән чоры тарихи вакыйгаларга бай була: япон сугышы, беренче урыс инкыйлабы, караңгы реакция, Беренче бөтендөнья сугышы, Октябрь түнтәреше, интервенция һәм гражданнар сугышы, ачлык, большевиклар золымы кебек җәберле-каһәрле елларны эченә ала. Шундый сәяси-иҗтимагый тотрыксызлык еллары булса да, ул үзенең халкын агартуга багышлаган кыйбласыннан тайпылмый.

Кызганычка каршы, без яшәгән XXI гасыр башында да шундый афәтләр очраштыра, без балаларны нәкъ Р.Фәхреддин әйткәнчә, “Балаңны укыт, тәрбия һәм әдәп өйрәт, калганын үзе өчен үзе тырышыр” (“Җәвамигуль – кәлим шәрхе” Казан: “Иман”, 1995. – 439 бит) шигаре астында тәрбияләргә тиеш.

Без, балалар бакчасында тәрбияче, мәктәптә балаларга белем бирүче

укытучы буларак, үз бурычларыбызны балаларга ана телен өйрәтү, туган телебезгә мәхәббәт тәрбияләү белән беррәттән, рухи яктан бай, милли үзаңлы балалар, укучылар тәрбияләүдә дә күрәбез. Үзебезнең хезмәтебездә, белем һәм тәрбия эшләрендә Ризаэддин Фәхреддин әсәрләрен, язмаларын актив кулланып, аны балалар күңеленә җиткерүгә үз өлешебезне кертәбез.

"Киләчәк буын яшьләребез өчен авыру килеш көн–төн сәгатьләр үткәреп язып утырдым, өметләнәм: хезмәтем сынык күңелләргә шифа һәм якты нур булыр,"- дигән өметтә калган Р. Фәхреддинов. Бу юлларга җавап итеп шуны әйтәсе килә: киләчәк буынны тәрбияләүдә Р. Фәхреддинов язып калдырган хезмәтләр югалмас, алар яшь буынны тәрбияләүдә маяк кебек барасы юлларыбызны яктыртып торыр.

2024 нче ел илебездә Гаилә елы дип игълан ителде. Тәрбиячеләр, укытучылар, әти-әниләр бердәм булганда киләчәк буын вәкилләре тиешле тәрбия алып, илебезнең якты киләчәген төзүдә актив катнашырлар дигән теләктә калабыз.

**Әдәбият**

Әмирхан Р. Ризаэддин Фәхреддин – тәрбияче. //Мәгариф. - № 12, 2005.- Б. 52-53

Фәхреддин Р. Милли әдәп сагында. - //Мәгариф. - №8, 1994.- Б. 57-58

Фәхреддин Р. Җәвамигуль кәлим шәрхе. – Казан: Иман, 1995. - 602 б.

Хәйри Ә. Ризаэддин Фәхреддин – педагог. // Мәгариф. - № 1, 2005. - Б. 58-60

Хәйри Ә. Ризаэддин Фәхреддин – педагог. // Фән һәм мәктәп. - № 12, 2005.- Б. 13-18

# УПРАЖНЕНИЯ, НАПРАВЛЕННЫЕ НА ОБУЧЕНИЕ АКАДЕМИЧЕСКОМУ АНГЛИЙСКОМУ ЯЗЫКУ ДЛЯ ВИРТУАЛЬНОЙ АКАДЕМИЧЕСКОЙ МОБИЛЬНОСТИ

***Замалиева А.И.***
***Казанский федеральный университет***
***albina.zamalieva.kpfu@gmail.com***

***Аннотация.*** В данной статье описаны упражнения в рамках подготовки участников международной академической мобильности. Результаты проведенного исследования позволяют сделать вывод о том, что важно обучать студентов академическому английскому языку.

***Ключевые слова:*** виртуальная академическая мобильность, предметно-языковое интегрированное обучение, преподавание иностранных языков

Согласно А.Н. Щукину упражнения призваны закреплять, активировать учебный материал, а также предназначены для контроля за качеством его усвоения. Автор подразделяет упражнения на языковые, речевые и условно-речевые [4: 230].

Языковые упражнения предназначены для усвоения обучающимися значения языковой формы. В результате выполнения таких упражнений у обучающихся формируются фонетические, лексические и грамматические навыки. В качестве примера видов таких упражнений можно назвать: имитативные, подстановочные, на заполнение пропусков, на конструирование фразы из структурных элементов и другие [4: 231].

Речевые упражнения предназначены для развития и совершенствования речевых умений на основе имеющихся знаний навыков. В качестве примера видов таких упражнений можно назвать: вопросно-ответные, условная беседа, описание, дискутивные упражнения, устный рассказ и другие [4: 231].

Условно-речевые упражнения направлены на имитацию речевой коммуникации в учебных условиях [1: 20]. В качестве примера таких упражнений можно назвать имитативные, подстановочные, трансформационные и репродуктивные [2: 168].

В рамках имитативных упражнений обучающиеся получают заданный образец и употребляют его в соответствии с речевой ситуацией. В рамках подстановочных упражнений обучающиеся подставляют другую лексическую единицу в отрабатываемую структуру. В рамках трансформационных упражнений обучающиеся изменяют порядок слов, лицо и время глагола, падеж или число существительного и другое. В рамках репродуктивных упражнений обучающиеся воспроизводят формы, усвоенные в предыдущих упражнениях [2: 168].

По мнению И.Ю. Бартеневой упражнения должны быть связаны между собой и образовывать систему. Автор выделяет следующие характеристики системы упражнений:

- взаимообусловленность упражнений - каждое упражнение учитывает материал предыдущего упражнения;

- доступность и последовательность упражнений - переход от работы над формированием отдельных навыков и умений к практике в определенном виде речевой деятельности;

- повторяемость речевых действий и языкового материала - в рамках системы упражнений отрабатывается определенный языковой материал и определенное количество речевых действий;

- коммуникативная направленность упражнений - речевые навыки и умения, формирующиеся в упражнениях, позволяют общаться при помощи языка [1: 21].

При разработке упражнений, направленных на обучение академическому английскому языку для виртуальной академической мобильности, опирались на идеологию методики интегрированного предметно-языкового обучения CLIL.

По мнению Л.Л. Салеховой, К.С. Григорьевой, М.А. Лукояновой владение академическим языком, понимание сложного материала, когнитивная деятельность и языковое обучение нуждаются в постоянном контроле и систематизации [3: 45].

Система упражнений подразделена на пять групп, каждая из которых направлена на формирование необходимой компетенции в контексте данного исследования.

Первая группа упражнений предназначена активировать имеющиеся знания обучающихся по изучаемой теме (activating). Например, предлагается такое упражнение как продолжить предложение (finish the sentence).

Вторая группа упражнений ориентирована на понимание материала (guiding understanding). Например, упражнение интервью (interview as input).

Третья группа упражнений направлена на развитие языковых навыков обучающихся (focus on language). Например, упражнение список академических слов (academic word list), бинго (bingo), «найти лишнее» (odd one out), табу (taboo).

Четвертая группа упражнений направлена на развитие устной речи обучающихся (focus on speaking). Например, упражнение очевидец (eyewitness), «докажи это» (prove it), ранжирование карточек (ranking cards), собеседование (job interview).

Таким образом, данные упражнения возможно использовать для обучения академическому иностранному языку в рамках подготовки студентов к виртуальной академической мобильности.

**Литература**

1. Бартенева И. Ю. К вопросу о классификации упражнений в методической литературе // Альманах современной науки и образования. – 2010. - № 2 (33), часть 2. С. 19-22.

2. Резникова, Г.А. Система упражнений для формирования языковых и речевых навыков и коммуникативных умений при обучении грамматике

неродного языка // Лингводидактические проблемы обучения иностранным языкам в школе и вузе: межвуз. сб. науч. тр. / под ред. Л.Н. Борисовой. - Белгород, 2003. - Вып.2.- С. 166-169.

3. Салехова Л. Л., Григорьева К. С., Лукоянова М. А. Педагогическая технология двуязычного обучения CLIL: учебно-методическое пособие. – Казань: КФУ, 2020. – 101 с.

4. Щукин А. Н. Обучение иностранным языкам: Теория и практика: учебное пособие для преподавателей и студентов. 2-е изд., испр. и доп. – М.: Филоматис, 2006. – 480 с.

# ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ПАРЛЫ СҮЗЛӘРГӘ ӨЙРӘТҮ

***Ильясова Г.Р.***
***Казан федераль университеты***
***dvebr@mail.ru***

***Аннотация.*** В данной статье рассмотрена проблема методики преподавания парных слов в начальной школе на уроках татарского языка. Общее лексическое значение парных слов с синонимическими компонентами в татарском языке значительно шире, чем значения компонентов, обозначающих типы: пара слов может обозначать целый тип. Именно поэтому изучение и запоминание парных слов татарского языка зачастую представляют собой сложности, в особенности для учащихся, изучающих татарский язык как государственный.

***Ключевые слова:*** парные слова, татарский язык, методика преподавания татарского языка, смысловые типы**.**

Парлы сүзләрнең – төрки телләрнең сүзьясалыш һәм лексик системасының үзенчәлекләренең берсе. Парлы сүзләр башка лексик берәмлекләрдән, барыннан да элек, ике компонентлы булулары белән аерылып торалар: ата-ана, көн-төн, мал- туар, савыт-саба һ.б. Алар сөйләмдә мәгънәне я көчәйтеп (экспрессия), я киңәйтеп, я гомумиләштереп киләләр. Мәсәлән, «кием-салым» парлы сүзе киемнәрнең гомум аталышы булып тора. Төрки телләрдәге парлы сүзләрне махсус өйрәнүче С.Н.Муратов аларда компонентларның мәгънәләре берегүен фразеологик берәмлекләргә караганда тотрыклырак дип карый [1: 10]. Татар телендәге парлы сүзләрнең катлаулы характеры (төрле генетик чыгышлы сүзләрнең парлануы, синонимик/антонимик компонентлы парлы сүзләрнең шактый булуы, архаик компонентлы парлы сүзләр һ.б.), бу төр сүзләрнең телдә күп санда булуы татар теле дәресләрендә парлы сүзләрне өйрәтү эшен катлауландыра. Татар телен дәүләт теле буларак өйрәнүче башка милләт балаларына телне өйрәтү процессында парлы сүзләрне аңлау, истә калдыру, дөрес язарга өйрәнү, сөйләмдә куллану эше аеруча катлаулы мәсьәләләрнең берсе булып тора. Нигездә, парлы сүзләр сүзьясалыш бүлеген өйрәтү кыссаларында өйрәнелә, бу теманы махсус өйрәнүгә сәгать саннары чикле. Парлы сүзләр Шуңа күрә дә татар теле дәресләрендә парлы сүзләрне өйрәнү мәсьәләсе бүгенгәчә актуаль булып кала.

Мәктәптә хәзерге татар телендә сүзясалышын укытуның максаты – кушымчаларның конкрет формаль һәм семантик үзлекләрен, мәгълүм булган сүзләр нигезендә яңа сүзләр ясау процессын, сүзләр структурасын һәм сүз ясалышы системасын өйрәнү [2: 47]. Татар телен чит тел буларак укыту методикасы хәзерге татар теленең сүзьясалышы үзенчәлекләрен өйрәтүнең махсус методларын булдыруны таләп итә.

Татар телендәге сүз ясалышы – телнең иң катлаулы системаларының берсен тәшкил итә. Бу система тамыр һәм тамырдаш сүзләр, кушымчалар, сүзләр парлашуы һәм сүзләр кушылуы форматларыннан, сүз ясау чылбырларыннан һәм парадигмалардан, сүз формалаштыру төрләреннән һәм модельләреннән, сүз ясау ояларыннан, сүз формалаштыру ысулларыннан тора. Әлеге системаның структурасы бәйләнеш, мотивация, гетерогенлек, бер структура, синонимия һәм антонимия мөнәсәбәтләреннән тора. Бу күрсәткечләрне исәпкә алып, безгә татар теле дәресләрендә парлы сүзләрне өйрәнү үзенчәлекләрен ачыкларга мөмкинлек бирә.

Мәктәптә татар теленең парлы сүзләрен өйрәтү процессында татар телен чит тел буларак укыту методикасының үзенчәлеге бар. Сүзьясалышы бүлегенең бу темасын өйрәнү татар теленең үзенчәлекләрен генә түгел, ә татар һәм башка телләрнең сүз ясалышы системалары арасындагы бәйләнешне исәпкә алып үткәрелсә, нәтиҗәлерәк булачак. Мәсәлән, татар телендәге парлы сүзләрне укытуны рус теленең яки башка төрки телнең сүзьясалышы системасы белән янәшә куеп аңлатырга мөмкин. Бу очракта бер яктан, тыгыз бәйләнешле, төрле структуралы телләрне аерырга, икенче яктан, чагыштырма телләрнең парлы сүзләре системасында охшаш һәм аермалы якларны исәпкә алу мөһим.

Татар телендәге парлы сүзләрнең формалашу үзенчәлеген – парлы сүзләрнең формалашу парадигмаларын, чылбырларга һәм ояларга кушылу процессын өйрәтү эше чагыштырыла торган телдәге охшаш күренешләр белән янәшә куеп алып барылырга тиеш. Мәсәлән:

1. *Тәкъдим ителгән сүзләрдән парлы сүзләр ясагыз:*

*җиләк – ?, туган – ?, хатын – ?, дус –?, явым – ?, ипи – ?, кадер – ?, ата – ?, иртә - ?, көн – ?, ?к – ?, савыт – ?*

Тәкъдим ителгән сүзләр: *тумача, кыз, иш, хөрмәт, төз, имеш, саба, ана, төн, кич, бар, төшем.*

Шул рәвешле, укучылар туган телләрендәге парлы сүзләр белән чагыштырганда, сүз формалашу дәрәҗәсендә өйрәнелә торган татар телендәге парлы сүзләр үрнәкләрен аңларга тиеш. Бу очракта, ике телгә дә хас булган универсаль, типологик үрнәкләрне һәм татар теленә генә хас булган уникаль үзенчәлекләрне дә исәпкә алырга кирәк. Бер-берсенә туры килгән фактлар татар телендәге парлы сүзләрне өйрәнгәндә уңай тәҗрибә буларак кулланылырга мөмкин. Бер-берсенә туры килмәгән яки өлешчә туры килгән күренешләр безгә иң зур кыенлыклар тудырган һәм икенче телне укытканда максатчан тырышлык таләп иткән моментларны исәпкә алырга мөмкинлек бирә. Бу максаттан түбәндәге күнегүне башкарырга мөмкин:

2. *Г.Тукайның “Шүрәле” поэмасыннан өзек белән танышыгыз. Парлы сүзләрне табыгыз. Аларның мәгънәсе аңлаешлы булмаса, “Татар-рус сүзлеге”ннән табып, өйрәнегез:*

*Билгеле, бу кап-кара урманда һәр ерткыч та бар,*
*Юк түгел аю, бүре; төлке – Җиһан корткыч та бар.*
*Һәм дә бар монда куян, әрлән, тиен, йомран, пошы,*
*Очрата аучы булып урманда күп йөргән кеше.*

*Бик куе булганга, монда җен-пәриләр бар диләр,*
*Төрле албасты, убырлар, шүрәлеләр бар диләр.*
*Һич гаҗәп юк, булса булыр, - бик калын, бик күп бит ул:*
*Күктә ни булмас дисең, - очсыз-кырыйсыз күк бит ул…*

*Үз-үзегезне тикшерегез: җен-пәриләр (джин + пери) – нечистая сила, очсыз-кырыйсыз (бесконечный + бескрайний) – безграничный.*

Рус һәм татар телләре – төрле системалы телләр. Рус теленең структурасы флектив, ә татар теле – агглютинатив. Бу телләрнең сүз формалаштыру системалары бөтенләй башка. Алар грамматик төзелеше, сүз төзелеше механизмнары, сөйләмдә кулланылышы белән аерылып торалар. Шуңа күрә, бу телләрдә парлы сүзләр ясалышының үзенчәлекләрен ачыклау һәм аларны укыту практикасында исәпкә алу – фәнни мәсьәлә.

Шулай итеп, татар тел белемендә парлы сүзләрне өйрәнү проблемасы буенча булган әдәбиятны анализлау күрсәткәнчә, бу юнәлештә эш бик аз башкарылган. Татар теле дәресләрендә парлы сүзләрне өйрәтү тәртибе турында кайбер фикерләр алга таба да өйрәнелүне таләп итә, чөнки бүгенге көндә парлы сүзләр актив ясалуын дәвам итә, алар арасында компонентлары рус теленнән алынмалардан гыйбарәт булган парлы сүзләр саны да арта бара. Шуңа күрә дә, безнең фикеребезчә, мәктәптә татар телен дәүләт теле буларак өйрәнүче укучыларга парлы сүзләрне өйрәтү эше беренче чиратта аларның туган телләре белән янәшә куеп, чагыштырма планда алып барылырга тиеш. Моның өчен дәресләрдә “Татар-рус телләре сүзлеге”н актив рәвештә куллану, әдәби әсәрләрнең тәрҗемәләре белән эшләү сорала.

**Әдәбият**


1. Муратов С.Н. Устойчивые словосочетания в тюркских языках. – М.: Восточная литература, 1961. – 131 с.
2. Хангилдин В.Н. Татар теле грамматикасы. – Казан: Тат. китап.нәшр, 1959. – 335 б.

# МИКРООБУЧЕНИЕ КАК ЭФФЕКТИВНЫЙ МЕТОД РАЗВИТИЯ ПЕДАГОГИЧЕСКОГО МАСТЕРСТВА

***Ильясова Л.Г.***
***Казанский федеральный университет***
***lily_ilyasova@mail.ru***

***Аннотация.*** Для формирования базовых навыков преподавания будущим учителям необходима соответствующая и эффективная модель обучения. В статье описан метод микрообучения в процессе педагогического образования, приведены возможности и перспективы использования метода для контроля уровня сформированности профессиональной компетенции, практических навыков будущих учителей и педагогов. Микрообучение – это исключительная возможность для учителей-стажеров использовать теоретические знания в реальных учебных ситуациях, при которых различные навыки преподавания отрабатываются в тщательно контролируемых условиях.

***Ключевые слова:*** микрообучение, будущий учитель, профессиональные компетенции, практические навыки, педагогическое образование

Профессия учителя является одной из самых важных и сложных. Благополучное будущее нашего общества зависит от качества образования, которое мы даем молодому поколению, и оно начинается с профессии учителя. Учителя играют, на наш взгляд, решающую роль в формировании сознания молодых людей и их будущего, поскольку оказываемое ими влияние выходит далеко за пределы классной комнаты.

Эффективное преподавание – нечто большее, чем просто передача информации обучающимся, требующее сочетание знаний, энтузиазма, сочувствия, мотивации и предполагающее создание увлекательной и интерактивной образовательной среды. Эффективный и успешный учитель способствует искренней любви к обучению.

В современном образовательном процессе большое внимание уделяется модернизации процесса обучения. В отечественных и зарубежных исследованиях, в ходе которых выделяется процесс совершенствования обучения, отмечается необходимость перехода от простого чтения преподавателем материала к увеличению длительности практических занятий при подготовке студентов-педагогов, а также сближения практического компонента обучения с профессиональной деятельностью [9].

Основные аспекты, на которые стоит полагаться при обучении будущих педагогов, – это теоретическая основа и практическая база, а именно: понимание о предметах, процессах, явлениях и научное познание о взаимодействии с предметами, процессами и явлениями [3]. Иными словами, эмпирическое знание в отличие от теоретического, которое представляется и

воспринимается как содержательный образовательный компонент, система правил и закономерностей, служит основой рационального решения практических проблем.

Перед начинающими учителями стоит множество проблем. Полагаем, что разрешение этих проблем является важным и актуальным для лучшей подготовки специалистов к их будущей карьере. Совершенствование педагогического мастерства возможно при помощи различных современных и инновационных методов и подходов.

Микрообучение — это технология обучения будущих учителей, при которой активизируется учебно-познавательная деятельность в структурируемом педагогическом контексте с учетом контролируемых и моделируемых условий. В основе данного метода лежит имитационное моделирование учебного процесса для «отработки» педагогических навыков будущих учителей и получения конструктивной обратной связи. Такой формат обратной связи помогает начинающим учителям выделить как можно больше положительных и отрицательных качеств своей деятельности и повторно показать более высокий результат преподавания [8].

Отечественные методисты уже описывали данный метод как эффективное средство пролонгирования знаний и приобретения опыта для расширения возможностей в профессиональной деятельности педагога. А.А. Вербицкий отмечает, что, несмотря на многочисленные реформы и обсуждения образовательной парадигмы, нам не хватает знаний о реальном переходе к современной образовательной системе, поэтому проблема организации учебной работы студентов все еще остается актуальной. В данном случае технология микрообучения может стать действенным приемом, который способен привести к модернизации традиционной модели получения знаний при подготовке будущих преподавателей [1, 2, 4]. Таким образом, микрообучение определяется как система контролируемой практики, которая позволяет сосредоточиться на определенном поведении при обучении, переходя от менее сложного к более сложному за счет «ограничения» определённого навыка преподавания, сокращения времени урока и количества участников [5, 6, 7].

Рассмотрим основные стадии разработки и проведения микроурока (см. Рис. 1):




Рисунок 1 – Этапы микрообучения

При разработке микроурока и постановке его цели необходимо придерживаться всех этапов, отраженных на Рис. 1. Данная технология не только поможет более успешно подготовиться к проведению и анализу микроурока, но и позволит снизить уровень стресса обучающихся, так как совместное обсуждение и рефлексия уроков направлена на устранение ошибок и недочетов в педагогической деятельности. Технология микрообучения, где руководитель выступает в роли «посредника», направляя студентов-стажеров в моделировании и учебной симуляции, помогает совершенствовать педагогическое мастерство будущих преподавателей.

Микрообучение можно использовать для развития широкого спектра базовых педагогических навыков, например: тайм-менеджмент, мотивация, выбор материала, стрессоустойчивость, критическое мышление, модуляция речи, умение управлять аудиторией и вниманием обучающихся, моральная подготовка к предстоящему уроку и многих других. Микрообучение является технологией, позволяющей будущим педагогам развивать педагогическое мастерство, а отработка вышеперечисленных навыков, в свою очередь, является неотъемлемой частью получения эмпирических знаний и опыта преподавания.

Абсолютная преданность делу, упорный труд и страсть к профессии – необходимая основа для того, чтобы стать учителем. Осуществление образовательного процесса с применением метода микрообучения является одной из методик, подтвердивших свою эффективность при подготовке будущих педагогов. Усовершенствование данного метода и дальнейшее его использование на практике поможет разработать эффективную современную методику для развития педагогического мастерства обучающихся.

## Литература

1. Вербицкий А.А. Иноязычное образование в контексте профессии // Вестник МГЛУ. Образование и педагогические науки. – 2018. – № 2 (796). С. 126–141.
2. Вербицкий А.А. Преподаватель вуза в контексте реформы образования // Вестн. Воронежского гос. техн. ун-та. – 2013. Т. 9, – № 5–2. – С. 4–10.

3. Плигин, А.А. Образовательная технология и обучение педагогов основам ее проектирования //Школьные технологии. – 2008. – № 2. – С. 9–16. 6
4. Сластенин В.А. Педагогика: учеб. пособие для студентов высш. пед. учеб. Заведений / В.А. Сластенин, И.Ф. Исаев, Е.Н. Шиянов. – М.: Академия, 2002. – 576 с.
5. Allen, D. Micro-teaching: A Description of Stanford, London, W – URL: https://eric.ed.gov/?id=ED019224 (дата обращения: 15.01.2024).
6. Buch, M.B., Third Survey of Research in Education. – URL: https://osre.ncert.gov.in/images/survey/Third_Survey/ch1_small.pdf (дата обращения: 22.01.2024)
7. Flanders, N.A. Analyzing Teaching Behaviour. – URL: https://www.worldcat.org/title/analyzing-teaching-behavior/oclc/120093 (дата обращения: 22.02.2024)
8. Morrison B. Teacher Training in Chinaand the Role of Teaching Practice. Available at:http://sunzil.lib.hku.hk/hkj/view/45/4500089/pdf (дата обращения: 22.02.2024)
9. Pinskaya M., Ponomareva A., Kosaretsky S. Professional Development and Training for Young Teachers in Russia. – URL: https://cyberleninka.ru/article/n/professional-development-and-training-for-young-teachers-in-russia (дата обращения: 10.01.2024)

# ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ЗАМАНЧА ТЕХНОЛОГИЯЛӘР ҺӘМ ИННОВАЦИОН АЛЫМНАР КУЛЛАНУ

***Ишмөхәммәтов И.Ш.***
***Түбән Каманың 13нче гимназия-интернаты***
***Ilham_1974@mail.ru***

***Аннотация.*** Сегодня информационно-коммуникативные технологии плотно входят во все сферы нашей жизни, в том числе и в образовательный процесс. Компьютерные технологии широко используются на уроках, ни одно школьное мероприятие не обходится без мультимедийных презентаций, а урок – без использования инновационных образовательных ресурсов. Так как основная цель обучения – воспитание творческой, активной личности, умеющей учиться и совершенствоваться самостоятельно. Использование ИКТ – это эффективное средство оптимизации умственного развития учеников. Новые информационные технологии открывают большие возможности расширения образовательных рамок по каждому предмету, и татарский язык не является исключением.

***Ключевые слова:*** инновация, современные технологии, образование, средства обучения, компьютер, мультимедиа, приемы, интерактивная доска, Интернет.

Соңгы елларда Россия һәм Татарстан мәгариф системасы зур үзгәрешләр кичерә. Бу үзгәрешләрнең асылы “заманча укыту” (яңача белем бирү) төшенчәсе белән бәйле. Бүген яңача укыту – заман таләбе. Яңача белем бирүдә заманча технологияләр зур һәм мөһим роль уйный. Цифрлаштыру шартларында укучыларның кызыксынуын арттыру механизмнарының берсе – белем бирү процессында мәгълүмати технологияләр куллану.

Элек укытуның нәтиҗәсе булып, укытучы өйрәткән барлык тармак буенча алган белем, күнекмә, осталыкка ия булган укучы саналса, хәзерге көндә укытуның нәтиҗәсе булып билгеле бер өлкәдә төпле белемле шәхес тора.

Укыту процессын технологияләштерү идеясе атаклы педагог А.С. Макаренко хезмәтләрендә үк ачык чагыла. Ул XX гасырның 30 нчы елларда ук үзенең “Педагогик поэма” китабында: “Барлык производство да технологик логикага корыла, безнең педагогик производство гына, күбесенчә, сүз белән аңлатуга, укытучының үзе теләгәнчә үгет-нәсихәтенә нигезләнә”, – дигән тәнкыйди фикер әйткән.

Академик М.И. Мәхмүтов фикеренчә, “уку бурычларын уңышлы үтәү өчен укучы һәм укытучыларның алдан планлаштырылган үзара бәйле, эзлекле эшчәнлеген технология дип атыйлар” [3: 88]. Билгеләмәдән күренгәнчә, инновацион педагогик технология нигезендә эшләү – укытучының “иҗат җимеше” генә түгел, ә алдан проектлаштырылган эшчәнлекнең эзлеклелеген бозмыйча эшләү. Алдан планлаштырылган эшчәнлек эзлеклелеген бозмыйча

эшләгәндә, уку бурычы уңышлы хәл ителә (материалны үзләштерү – нәтиҗә гарантияләнә).

Бүгенге көндә уку-укыту эшчәнлеге заманча технологияләрдән башка була алмый. Татар теленә, әдәби әсәрләргә карата кызыксыну уяту кече яшьтән үк, балалар бакчасыннан, гаиләдән башланса, ныклы эшчәнлек башлангыч сыйныфлардан башлана һәм өлкән сыйныфларда дәвам иттерелә, тагы да үстерелә. Бу чорда укытучы, иң беренче чиратта, укучыларда укуга карата кызыксыну уяту максатын куярга һәм үз эшчәнлегендә бу максатка ирешү методларын, алымнарын өйрәнеп, аларның базасын булдырырга тиеш. Билгеле, бу эш бүгенге көн таләпләренә туры китерелеп, яңа технологияләр кулланып оештырыла. Димәк, һәр укытучыдан заман сулышын тоеп, үз белемен өзлексез камилләштерү, укыту-тәрбия өлкәсендә иҗади якын килеп эшләү сорала. Без заман белән бергә барырга, яшәештәге барлык яңалыклардан хәбәрдар булырга, яңа буын балаларына төпле белем һәм тәрбия бирер өчен яңа технологияләрне яхшы белергә, аларны тирәнтен өйрәнергә һәм үз эшчәнлегебездә актив куллануга ирешергә тиешбез. Заманча педагогик технологияләрне дөрес кулланып эш итү белем бирүнең иң уңышлы юлларын билгели, укучыларга бүгенге көн таләпләренә туры килә торган төпле белем бирү юлларын күрсәтә.

“Күп белдерүгә караганда, аз белдереп, эзләнү орлыгы салу һәм эзләгәнен үзе табарга юллар күрсәтү – мөгаллим бирә ала торган хезмәтләрнең иң кадерлесе, иң зурысыдыр,” – дигән язучы һәм галим Г. Ибраһимов. Бүгенге көндә дә заманча технологияләрнең асылын Г.Ибраһимовның шушы фикере тәшкил итә. Чөнки заманча технологияләр кулланып эшләү – ул укучыда фәнгә кызыксыну уяту, аның танып белү активлыгын үстерү һәм укучының иҗади мөмкинлекләрен камилләштереп, белемнәрен тирәнәйтү дигән сүз.

Татар теле һәм әдәбияте дәресләрендә заманча педагогик технологияләрнең кулланылуын өйрәнеп түбәндәге фикергә килергә мөмкин: нәкъ менә шушы заман технологияләрен куллану укучыларга мәгълүматны үзләштерүдә, фикерләү сәләтен үстерүдә, рефлексиядә, дөрес бәяләүдә, үзләрен шәхес итеп танытуда зур ярдәм итә. Инновацияләр укыту, тәрбия бирү процессын тагы да ныграк яхшырту, аның җитешсезлекләрен бетерү өчен кулланыла.

Аларга түбәндәгеләрне кертергә мөмкин: инновацион җиһазландыру, инновацион алымнар, инновацион технологияләр.

Бүгенге көндә *инновацион җиһазландыру* – ул мультимедиа чаралары. Мультимедиа чаралары белән укучылар һәм укытучылар да иркен куллана ала. Монда шулай ук Интернет челтәре һәм компьютер программаларын да өстәргә мөмкин.

*Инновация алымнары*н файдалану шулай ук уңышлы нәтиҗәләр бирә. Бүген кулланылган күпчелек алымнар моңа кадәр дә булган. Аларны күз уңыннан ычкындырмый, системалы рәвештә даими кулланырга кирәк.

*Инновацион технологияләр* техника белән генә эш дигәнне аңлатмый. Мәсәлән, хәзерге көндә безнең күпчелек методист-галимнәребезнең тырышлыгы укучыларга телне мөстәкыйль өйрәнү программаларын төзү өчен

юнәлтелгән. Моның өчен төрле мультимедиа системалары, программалары төзелә. Мәсәлән, Learningapps.org программасы – ул укучыларга да, укытучыларга да уңай булган интерактив модульләрдән тора.

Компьютер технологияләренең өстенлеге исә – ул күргәзмәлелек, мәгълүматларның график сурәтләнеш, стереотавыш, анимация берлегендә бирелүе.

Укучыларга татар телен һәм әдәбиятын укытуга кызысыну тәрбияләү өчен компьютер хәзерге шартларда иң кирәкле техник чара дип санала. Ләкин компьютерны дөрес һәм урынлы файдалана белергә кирәк. Дәрес буена компьютер яки интерактив такта куллану бик үк дөрес булмый. Һәр нәрсәне чама белеп, компьютерның дәрестә куйган максатка ирешүдә эшне ничек җиңеләйтүен ачыклап куллану кирәк.

Компьютер ярдәмендә татар теле дәресләрендә бер төркем мәсьәләләрне хәл итәргә була: лексиканы өйрәнү (компьютер сүзлекләрен файдалану), дөрес әйтелеш өстендә (татар теле дәреслекләреннән, тавыш язу программаларын файдалану), төрле электрон күнегүләр эшләү, сөйләмнәр һәм текстлар төзү, редакторлау һ. б. татар әдәбияты дәресләрендә компьютерны куллану түбәндәге эш төрләрен үз эченә ала: яңа материал аңлатканда, компьютер ярдәмендә күп мәгълүмат бирергә, төрле фото, күргәзмәләр күрсәтергә мөмкин (язучылар, шагыйрьләр турында фотосурәтләр, видеофильмнар, видеороликлар күрсәтү, әдипләр үзләре укыган шигырьләрне тыңлау, биографияләренә кагылышлы видеоматериалларны күрсәтү, әдәби әсәр мотивлары буенча төшерелгән спектакль-кинофильмнардан өзекләр күрсәтү һ. б.), укыган әсәр эчтәлеге буенча иҗади эшләр башкару (компьютер презентацияләре әзерләү, видеороликлар төшерү, видеофильмнар, фотосурәтләр төшерергә мөмкин).

Мәгълүмати-коммуникатив чаралар укыту процессын тамырдан үзгәртә: дәрес темпын арттыра, укучыларга мөстәкыйль рәвештә күбрәк эшләргә ярдәм итә, балалар тарафыннан теманың үзләштерелү дәрәҗәсен тикшерергә, һәрбер укучы белән дифференциаль эшчәнлек алып барырга булыша.

***Ключевые слова:*** Иноязычное общение, средства массовой информации, коммуникативная компетенция, аутентичные материалы

Иноязычное общение является важным навыком в эпоху глобализации, поскольку позволяет человеку взаимодействовать с представителями разных стран и культур. Одним из эффективных способов обучения иноязычному общению является использование материалов медиа. Такие ресурсы, как фильмы, новости, литература, предоставляют обучающимся возможность взаимодействовать с современными реалиями, предоставляя таким образом иной
опыт, который может привлечь внимание изучающего иностранный язык. Поскольку средства массовой информации могут работать не только в пределах одного региона или страны, именно в этом источнике информации мы можем столкнуться с разнообразием диалектов, сленга, идиоматических выражений, которые способствуют не только развитию навыка иноязычного общения, но и обмену культурным опытом. Это позволяет учащимся получить более широкое представление о языке. В данном случае мы непосредственно работаем с аутентичным материалом, который может включать в себя афиши, анкеты и вопросники, проездные и входные билеты, карты, схемы, вывески, этикетки, новости, подкасты и т.д. [1: 844] Новикова отмечает, что данный процесс положительно влияет на личностно-эмоциональное состояние обучающихся, способствует формированию межкультурной и лингвострановедческой компетенции и повышает коммуникативнопознавательную мотивацию. [2: 74]

Коммуникативный подход, который лежит в основе обучения иноязычному общению предполагает активное вовлечение обучающихся в

коммуникативную деятельность, аналогичную реальным ситуациям. В контексте обучения с использованием материала СМИ, обучающие могут слушать и смотреть, и слушать различные источники информации, будь то новостные сводки, структурированный материал из газеты или документальная работа по произошедшему социальному или политическому событию.

Например, учащийся может ознакомиться с материалом и сделать выводы из полученной информации. Таким образом, обучающийся совершенствует не только разговорную речь на иностранном языке, но и развивает свои навыки аудирования.

Нельзя не отметить интеграцию мультимедийного подхода при обучении общению, поскольку он включает в себя использование различных видео, фото и аудио материалов, которые мы можем обнаружить в различных источниках средств массовой информации. Данное свойство и преимущество так же способствует активному вовлечению обучающихся в образовательный процесс.

Кроме того, в процессе обучения устному иноязычному общению по медиаматериалам также могут использоваться технологии. Обучающиеся могут взаимодействовать с различными приложениями и онлайн-платформами для улучшения своих коммуникативных навыков. Большое количество иностранных новостных агрегаторов имеют собственные приложения со структурированным материалом и сообщениями, с возможностью выбора не только раздела (например политика или экономика) и темы, но и уровня языка, позволяя таким образом обучающемуся выбрать наиболее подходящий материал для него материал как по интересу, так и сложности.

В эпоху глобализации умение общаться на иностранных языках становится все более важным. Используя материалы иноязычных СМИ, обучающиеся могут эффективнее развивать свои навыки иноязычного общения. Научившись использовать различные контексты, которые можно обнаружить в речах политиков, высказываниях известных личностей или строго организованных сообщениях журналистов, учащиеся могут овладеть не только структурой организации монолога или диалога, но и пониманием культуры носителей, что так же тесно связано с языком.

**Литература**

1. Валеев А.А. Кондратьева И.Г. Факторы успешного обучения иноязычному профессиональному общению // Современные проблемы науки и образования. – 2014. – № 6. – URL: https://science-education.ru/ru/article/view?id=16318 (Дата обращения 10.02.2024)
2. Новикова О.В. К вопросу об использовании аутентичных текстов профессиональной направленности в процессе обучения английскому языку // Язык и текст. – 2022. – Т. 9. – № 3 – С. 72–77.

# ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ СТУДЕНТЛАРНЫ ТЫҢЛАП АҢЛАУГА ӨЙРӘТҮ АЛЫМНАРЫ

***Мөгътәсимова Г.Р.***
***Казан федераль университеты***
Gulnaz-72@mail.ru

***Аннотация.*** В статье рассматривается проблема формирования навыков аудирования на старшем этапе обучения татарскому языку. Особое внимание уделено вопросам использования аутентичных видеоматериалов на уроках татарского языка. Автором обоснована важность использования видеоматериалов на уроках татарского языка, определен их дидактический потенциал, а также предложен комплекс упражнений на основе художественного фильма, направленный на формирование аудитивных навыков у обучающихся старших классов.

***Ключевые слова:*** татарский язык, обучение, аудирование, навыки аудирования, видеоматериал, видеофильм.

Күп кенә белгечләр фикеренчә, иң авыры – сөйләшү һәм тыңлап аңлау күнекмәләрен үзләштерү. Тыңлап аңлау сөйләшү белән һәрвакыт янәшә. Тыңлап аңларга өйрәнмичә торып, сөйләшеп китеп булмый. Әлеге күнекмәләр уңышлы аралашуның алшартын тәшкил итә. Студентларның тыңлап аңлау күнекмәләре, кагыйдә буларак, начар формалашкан була.

Шулай итеп, бу тема – татар теленә өйрәтү методикасында иң актуаль темаларның берсе, чөнки тыңлап аңлаудан башка сөйләшү, аралашу мөмкин түгел. Тыңлап аңлауны бәяләп бетермәү исә студентларның тел әзерлегенә бик тискәре йогынты ясарга мөмкин. Моннан тыңлап аңлауга өйрәтү проблемасының мөһимлеге һәм актуальлеге ачык күренә. Хәзерге уку-укыту процессында тыңлап аңлауның күләмен һәм әһәмиятен арттырырга кирәк. Укучыларда татар телен өйрәнүгә карата теләк формалаштыру һәм уку материалын үзләштерүнең кабул ителерлек дәрәҗәсенә ирешү өчен, укытучы укыту процессына заманча алымнар, методлар һәм чаралар кертергә тиеш.

Укучыларны телдән сөйләмне аңларга өйрәтү – коммуникатив методикада татар теленә өйрәтүнең иң мөһим максатларының берсе. Сөйләм эшчәнлегенең әлеге үзенчәлекле төренә максатчан рәвештә өйрәтергә кирәк. Бу максатларга ирешүдә аутентик аудио- һәм видеоматериаллар зур әһәмияткә ия. Татар теле дәресләрендә төрле видеоматериаллар кулланырга мөмкин. Мәсәлән, реклама роликлары, танылган кешеләр белән әңгәмәләр, мультфильмнар, яңалыклар, документаль фильмнар, телетапшыруларның өзекләре һәм башка бик күп нәрсәләр. Төрле видеофильмнарны дәрестә куллану методикасы татарча сөйләмне иркен кабул итәргә һәм дөрес сөйләргә өйрәтә. Аудио һәм видео белән эшләгәндә, дәреснең туксан проценты сөйләшү практикасына нигезләнгән. Акрынлап, этаптан этапка таба сөйләм күнекмәләрен һәм тыңлап аңлауга өйрәтүнең эчтәлеген катлауландыру күздә тотыла.

Татар телендәге теләсә кайсы фильм уңайлы һәм нәтиҗәле дидактик материал була алыр иде. Мондый технологияләрне татар теле дәресләрендә куллану укучыларның сөйләм күнекмәләрен үстерергә булыша, сөйләмне тыңлап аңлауны һәм хәтта сүзләрне дөрес әйтергә өйрәтүне нәтиҗәле итә.

Фильм ул өстәмә мәгълүмат чыганагы гына түгел. Дәресләрдә мондый чараларны куллану укучыларның игътибарын һәм хәтерен ныгытуга йогынты ясый. Сыйныфта караганда, бергәләп танып белү эшчәнлеге даирәсе барлыкка килә. Бу вакытта фильмның мәгънәсен аңларга тырышып утырып, укучылар да игътибарлырак була. Шулай итеп, ирексез игътибар ирекле хәлгә күчә, ә игътибарның көче хәтергә тәэсир итә. Болар барысы да материалны истә калдыру дәрәҗәсенә уңай йогынты ясый.

Әмма фильмны кабызып куйдык та карап чыктык дип кенә уйлау дөрес булмас. Видеоматериалларны дәресләрдә куллану файда китерсен өчен, аларны бары тик карау гына җитми. Бу эшчәнлеккә алдан ныклап әзерләнергә кирәк. Иң элек сайланган фильмның укучыларның белем дәрәҗәсенә, программа һәм укыту планына туры килү килмәвен билгеләү уңышлы булыр иде. Фильмны укучыларга күрсәткәнче карап чыгып, лексик һәм грамматик яктан анализларга, күрсәтү максатын ачыкларга да кирәк. Телдән фикер алышу яки инша язу яисә башка төрле эшләр күрсәтү максаты булып тора ала. Фильмны дидактик материал буларак куллануыбызны истән чыгармаска кирәк.

Әмма, тәҗрибә күрсәткәнчә, аудиториядә нәфис фильмны тулысынча карау нәтиҗәле түгел. Бу, беренче чиратта, фильмның озынлыгы 90 минут яки тагын күбрәк һәм тел мәгълүматы күләменең дә шактый булуына бәйле. Боларны бер дәрестә эшләп бетерү һич мөмкин түгел. Шуңа күрә нәфис фильмны өзекләргә бүлеп карау уңышлырак. Өзекләрнең эчтәлеге мәгънәсе буенча шартлы төгәлләнгән диалог яки персонажларның полилогларын тәшкил итәргә тиеш. Шул ук вакытта барлык нәфис фильмнарның да педагогик практика өчен яраклы булмавын онытмаска кирәк. Тыңлап аңлау компетенциясен булдыру практикасында кулланылырга мөмкин булган нәфис фильмнарны, аерым өзекләрне сайлаганда, кайбер критерийларны исәпкә алу уңышлы булыр иде. Мәсәлән, геройларның сөйләме хәзерге татар сөйләменә туры килергә, нәфис фильмның сюжеты реаль тормыш вакыйгаларын чагылдырырга, өзек персонажларның сөйләменә максималь дәрәҗәдә бай булырга тиеш.

Татар теле дәресләрендә нәфис фильмнарны куллану коммуникатив һәм аудитив компетенцияне нәтиҗәле формалаштыруга ярдәм итә дигән фәнни фаразның дөреслеген практикада тикшерү өчен, эксперимент уздырып карадык. Аның барышында «Инсаф» фильмына биремнәр эшләнде һәм тикшерелде. Режиссёр Фәрит Дәүләтшинның «Инсаф» фильмы Рабит Батулланың «Кичер мине, әнкәй» пьесасына нигезләнеп төшерелгән. Бу картинада Бахчисарай авылында яшәүче малайның тарихы сурәтләнелә. Инсаф зур суммага лотерея ота. Әлеге хәбәр тирә-якка бик тиз таралып өлгерә. Шушы мизгелдән малайның тормыш юлы кинәттән яңа борылыш ала.

Барлык биремнәр барыннан да элек фильмның эчтәлеге һәм геройлар сөйләшә торган җанлы татар теле белән җентекләп танышуга юнәлтелгән. Моннан тыш, күп кенә күнегүләрнең лексикологик юнәлеше бар. Ул татар телендә күзәтелә торган кызыклы процессларга игътибарны юнәлтә.

Педагогик тәҗрибә барышында, фильмны караганчы, студентларга түбәндәге эшләр тәкъдим ителде: фильмның мәгънәсен аңлау өчен кирәк булган яки укытуның бу этабында файдалы булырга мөмкин яңа лексик берәмлекләр белән таныштыру, студентларны кызыксындыру, темага, фильм вәзгыятенә кертеп җибәрү, темага караган белемнәрне активлаштыру һәм башкалар. Шулай ук карар алдыннан фильмның исеме, төшерелгән елы һәм режиссеры турында да фикер алыштык. Нәкъ менә фильмны караганчы эшләнә торган биремнәр татар сөйләмен тыңлап кабул итү күнекмәләрен булдырырга һәм ныгытырга ярдәм итә.

Киләсе этап инде ул – фильмны карау. «Инсаф» фильмы 1 сәгать 14 минут дәвам итә, шуңа күрә без аны берничә өлешкә бүлеп карадык. Әгәр кыска метражлы фильм булса, аны тулысынча һәм, әлбәттә, бергә карау яхшырак. Бу этапта түбәндәге биремнәрне эшләп булыр иде. Мәсәлән, өзекне бер тапкыр карагач, рольләрне билгеләп һәм тавышны ябып куеп, экрандагы вакыйгаларны тавышландыру; иң кызыклы урында фильмны туктату һәм вакыйгаларның алга таба ни рәвешле дәвам итүе турында сөйләшеп алу. Тагын бер кызыклы бирем – фильмдагы геройларны тасвирлап бирү, ягъни студентлар персонажларның тышкы кыяфәте, характеры, гадәтләре турында сөйләргә тиеш.

Өченче этапның максаты – фильмны аңлауны тикшерү. Шул максаттан чыгып, фильмдагы проблемалы мәсьәләләр буенча гомуми фикер алышу үткәрелде. Әле тагын ошаган өзекне персонажларның берсе исеменнән сөйләргә дә мөмкин. Бу вакытта укучылар үз фикерләрен әйтергә, чагыштырырга, тәнкыйтьләргә, бәхәсләшергә, бер-берсе белән сөйләшергә өйрәнәләр.

Әлеге эксперимент күрсәткәнчә, «Инсаф» фильмы материалы белән эшләгәндә, студентлар үзләренең актив сүзлек байлыгын тулыландырдылар һәм ныгыттылар; проблемалы мәсьәләләр буенча фикер алышканда, телдән сөйләм күнекмәләре үсте.

Шулай итеп, татар теленә өйрәтү процессында видеоматериалларны куллану укытучы эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген сизелерлек арттырырга сәләтле, чөнки видеоматериаллар аутентик аралашуы үрнәкләрен тәшкил итә, реаль аралашу даирәсен тудыра, татар теле материалын үзләштерүне тагын да җанлырак, кызыклырак, проблемалы, ышандыргыч һәм эмоциональ итә.

Тыңлап аңлауга өйрәткәндә, төрле видеоматериалларны куллануның мөһимлеген ассызыкларга кирәк. Аларны куллану һәркем өчен аңлаешлы, кызыклы, нәтиҗәле, уңайлы белем бирү мохите булдыра, укучылар һәм укытучыларга иҗади яктан үсәргә мөмкинлек бирә, укучыларда татар телен өйрәнүгә теләк формалаштыра.

**Әдәбият**

1. Бричева М.М., Берсирова С.А., Нещеретова Т.Т., Сасина С.А., Схаляхо Е.Н. Использование художественных фильмов в процессе обучения иностранным языкам // The Scientific Heritage. – 2020. – С. 38-40.

2. Гуняшова Г.А. Использование видеоматериалов в обучении аудированию на уроке иностранного языка // Вестник КемГУ. – 2015. – № 2-3. – С.34-37.

3. Фатхуллова К.С., Мугтасимова Г.Р. Укучыларның татар телендә аралашу осталыгын үстерү // Языки культуры в контексте исторического наследия: к 100-летию со дня рождения Э. Р. Тенишева : сб. ст. по материалам Всерос. науч.-практ. конф. (г. Пенза, 21–23 апреля 2021 г.) / под ред. Ж. З. Туктарова, В. Ф. Мухамеджановой, Г. Х. Самочкиной. – Пенза : Изд-во ПГУ, 2021. – С.174-178

# ИНТЕРАКТИВ УКЫТУ ЫСУЛЛАРЫН ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ КУЛЛАНУ

***Мөхәмәтҗанова Э. Р.***
***Дүртөйле районы Мәскәү урта мәктәбе***
***amineva1960@mail.ru***

***Аннотация.*** В статье актуализируется проблема реализации интерактивных методов обучения в школе, также рассматриваются различные интерактивные формы и методы обучения на уроках родного языка.
***Ключевые слова:*** интерактивные методы, диалог.

Интерактив укыту ысуллары – ул танып-белү эшчәнлеген оештыруда махсус эш формасы, аның төп максаты - диалог коруның уңайлы шартларын булдыру. Уку процессының шарты булып, укытучының һәм укучыларның диалогка нигезләнгән үзара бәйләнешкә керүе тора. Дәрес барышында һәркем аралашырга, шәхесара төрле мөнәсәбәтләргә керергә, эшчәнлек башкарырга тиеш. Дәрес никадәр җанлы һәм кызыклы – укучыда фәнгә карата уңай мотивация шулкадәр югары. Моны булдыручы – остаз, һәр баланы эшчәнлеккә җәлеп итүче. Диалогта катнашу – ул тыңлау, ишетү, сөйләшү генә түгел, ә аңлау да таләп итә. Димәк, кызыклы, конструктив диалог төзергә өйрәнергә һәм өйрәтергә кирәк.

Интерактив ысуллар уку мотивациясен арттыруга, белемне тирәнәйтүгә, иҗади сәләтне, аралашучанлыкны үстерүгә ярдәм итә һәм үз позициянне белдерергә мөмкинлек бирә. Балаларның үз-үзләренә хөрмәте, ышанычлары арта. Тирә-яктагы кешеләрнең фикерләренә һәм эшләренә карата ихтирам, түземлелек тәрбияләү бик мөһим. Җәмгыятьтә кешеләр белән аралаша белү, килешүләр төзү, командада эшләү кебек сыйфатлар югары бәяләнә. Интерактив ысуллар җаваплылыкны бүлергә, максатлар куярга, дөрес методлар сайларга, ситуацияне анализларга ярдәм итә, шулай ук иҗади фикер йөртүне үстерә, эшләнгән эштән канәгатьлек хисе бирә.

Интерактив методларга уен (эшлекле уен, рольләргә бүлешеп уйнау, психологик тренинг), парлы һәм төркем эшләре, «карар агачы», «баш мие штурмы» (брейнсторминг), «гомуми дискуссия», «түгәрәк өстәл», дебатлар, диспутлар, форумнар, проектлар, кейслар, семинарлар, ассоциацияләр, «Аквариум», «Блум ромашкасы», «Кар бөртеге» технологияләре керә. Укучыларның танып-белү эшчәнлеген активлаштыру һәм укучыларда уңай мотивация булдыру дәреснең һәр этабында тормышка ашырылырга тиеш. Укучыларны кызыксындыруны тәэмин итә торган кайбер нәтиҗәле алымнарга күзәтү ясап китик.

Дәрес башында «фаразлау агачы»н кулланырга мөмкин, анда дәреснең темасы – «агач кәүсәсе», «яфраклар» - дәрескә фаразлар, «ботаклар» - аргументлар. Мәсәлән, «Алмашлыклар» темасын өйрәнгәндә лингвистик әкият сөйләнә, анда укучылар агач моделен төзиләр. «Лексика» бүлеген өйрәнгәндә,

дәресне «Сүз болыты» алымы белән башлау урынлы, анда ачкыч сүзләр яшерелә. Шулай ук дәресне өч фазалы структура: чакыру, фикерләү, рефлексия нигезендә төзү дә уңай нәтиҗә бирә. «Чакыру» этабында табышмаклар, башваткычлар, лингвистик биремнәр бирергә була. «Фикерләү» ситуациясендә сингапур укыту методы элементларын кулланырга мөмкин, анда укучылар элемтәгә кереп, хезмәттәшлек итәләр һәм команда булып өлгерәләр. Икешәр һәм дүртәр төркемнәрдә укучылар буталчык логик чылбырлар, интеллект карталары, график кластерлар, таблицалар, дәрес темасы буенча дөрес һәм дөрес булмаган раслаулар булдыра алалар.

Парларда эш - хезмәттәшлек һәм үзара ярдәм күрсәтү өчен иң яхшы форма. Монда укучылар бер-берсен тикшерә, яңа материалны ныгыта, үткәннәрне кабатлый ала. Төркемдә укучылар «Ишикава диаграммасы» буенча эшли алалар, «Фишбоун», «Күрше өчен сүзлек диктанты» модельләрен төзи алалар.

Рефлексия этабында укучылар «Кластер» ысулын эффектив кулланып төп сүзне табалар, дәрес моделен эшлиләр.

ПАМН-формула (П-позиция ( «Мин уйлыйм,... »); А – аңлатма (яки нигезләү); М - мисал («мин моны ... мисалында исбатлый алам»); Н – нәтиҗә («моннан чыгып, мин нәрсә турында нәтиҗә ясыйм») – катлаулы мәсьәләләр турында фикер алышканда кулланыла.

Һәр укучы үз эшчәнлеген график формада «Бәяләү тәрәзәсе» методы буенча башкара ала, ул «Шунда ук куллана алам», «Бөтенләй аңлашылмый», «Яхшы аңлашыла», «Беркайчан да куллана алмыйм» дигән бүлекләрдән тора. Шул рәвешле, туган тел дәресләрендә яңа материалны һәм кагыйдәләр үзләштерүне җайга салырга мөмкин.

Укучыларның уңышлы сөйләм активлыгының нигезе булып традицион булмаган дәрес формалары тора, алар барышында укучылар белемнәрен киңәйтәләр, бу исә укучыларга фикер алышуда актив катнашырга мөмкинлек бирә.

Интерактив укыту технологиясе нигезендә туган тел буенча биремнәрне үтәгәндә, проблемалы ситуацияне үзенчә күрү, аннан чыгу мөмкинлеген формалаштыру өчен шартлар тудырыла; үз позицияләреңне, тормыш кыйммәтләреңне нигезләү; башка карашны тыңлау сәләте, хезмәттәшлек итү сәләте, үз оппонентларына карата толерантлык күрсәтеп, парың белән аралашу кебек үзенчәлекләр үсә, үзара аңлашу, хакыйкать эзләү юлларын бергәләп табу процессында катнашу мөһим роль уйный.

Шулай ук туган тел дәресләрендә интерактив технологияләр кулланганда метапредмет һәм предмет бәйләнешләр генә түгел, шәхси компетенцияләр формалаштыру да бара, бу исә үсетерелешле укыту технологияләрен тулысынча гамәлгә ашырырга мөмкинлек бирә.

**Әдәбият**

1.Вислобоков Н. Ю. Технологии организации интерактивного процесса обучения // Информатика и образование. - 2011. - N 6. - С. 111-114.

2. Воронкова О. Б. Информационные технологии в образовании: интерактивные методы. – Ростов н/Д: Феникс, 2010. - 315 с.
3.Ермолаева М.Г. Интерактивные методики в современном образовательном процессе. - М.: Просвещение, 2014. - 42 с.
4.Кажигалиева Г.А., Васенкова М.В. О принципах и методах технологии интерактивного обучения русскому языку в средней школе // Педагогика. – 2005. - №2.

# ТАТАРҺӘМ КЫТАЙ ТЕЛЛӘРЕНЕҢ ЛЕКСИКАСЫН ЧАГЫШТЫРЫП ӨЙРӘНҮ
## (ике телнең «ризык» лексикасы мисалында)

***Мөхәммәтшина А.Ф.***
***Казан федераль университеты***
*alisafaizovna99@mail.ru*

***Аннотация.*** Китай и татары имеют богатые культурные традиции и исторические связи. Они отражаюся во многих сферах, а также в языке. В данной статье рассматриваются лексические параллели китайского и татарского языков.

***Ключевые слова:*** пищевые традиции, татары, Китай, тюркские народы.

Хәзерге вакытта без кешелекнең яңа мәдәниятнең туу чорын кичерәбез. Өченче меңьеллык мәдәнияте мәдәниятләр синтезыннан гыйбарәт. Яңа чорның башы – фәндә иң кызыклы һәм сәнгатьтә кешелек дөньясы туплаган күп гасырлык иң яхшы рухи тәҗрибәне берләштерүчеербөтен мәгълүмати мәдәни киңлек булдыру вакыты. Бүгенге көндә, халыкларның, телләрнең һәм мәдәниятләрнең үзара катнашуы, керешеп китүе моңарчы күрелмәгән колачка ирешкәч һәм чит мәдәниятләргә карата түземлелек тәрбияләү, аларга карата кызыксыну һәм ихтирам уяту, башка мәдәниятләрнең кирәгеннән артык булуына, җитешсезлегенә яки бөтенләй булмавына ачу хисләрен җиңү проблемасы беркайчан да булмаганча кискенләшкәч, билингвизм проблемалары мәдәниятара аралашуда аеруча актуаль булып кала [1: 26].

Дөньяның тел һәм мәдәни картиналары төшенчәсе чит телләрне өйрәнүдә мөһим роль уйный. Чыннан да, чит мәдәниятнең интерференциясе аралашуны туган телдән ким булмаган дәрәҗәдә катлауландыра. Чит телне өйрәнүче әлеге тел ияләре мәдәниятенә үтеп керә һәм аңа салынган мәдәният йогынтысына дучар ителә. Туган тел һәм туган тел дөньясының беренчел картинасына өйрәнелә торган тел дөньясының икенче картинасы өстәлә [1: 47].

Көннән-көн популярлашып барган кытай теленә килгәндә, генеалогик классификациядә кытай теле кытай-тибет телләре гаиләсенә карый, иң зур һәм күпсанлы халык сөйләшә торган төркем булып тора. Ә татар теле төрки телләрнең кыпчак төркеменә керә. Димәк, бу ике тел – ике төрле төзелешле система, шунлыктан алар арасында уртаклыкларга караганда аермалар күбрәк булуы табигый.

Әмма телгә кадәр бу ике халыкның борынгы тарихын искә алырга кирәк. кытайлар тарихи яктан татарлар белән урта гасырлардан ук таныш була. борынгы төркиләр – хуннар – безнең эрага кадәр III гасырдан Кытай чикләрен борчыйлар. Күчмә халыклардан берникадәр сакланыр өчен Кытай Бөек Кытай диварын төзергә мәҗбүр була. кытайлылар күченеп йөрүчеләрдән сан ягыннан күбрәк булуы белән генә түгел, ә ул вакыттагы көчле икътисады һәм армиясе белән дә аерылып торган. Күчмәләрнең өстенлеге аларның мобильлеге булган. Алар нигездә һөҗүмнәр белән шөгыльләнгәннәр, чөнки Кытай товарларына,

аерым алганда, ефәк һәм ашлыкка мохтаҗ булганнар. Алар ирекле сәүдәне саклар өчен, салым түләп, күчеп йөрүчеләрдән чикләрне ачуны өстен күргәннәр.

Танылган Кытай тарихчысы Ван Го Вэй үз эшләрендә төрки халыклар белән күрше яшәүләре турында сөйли. Ул түбәндәгечә яза: «Татарларда барлык кешеләр дә батыр һәм намуслы. Кытай җирләренә якынрак булганнарны “югары тәрбияле” дип атаганнар. Алар тары чәчә беләләр, аны яссы төбе булган балчык казаннарда пешерәләр һәм ашыйлар. Фарсы галиме Рәшит әд-Дин эшләрендә искә алынучы татарларны «монголлар исемен күптән түгел генә алган халыклардан» дип яза. Татарларның роле Бөек Ефәк юлындагы сәүдә белән бәйле рәвештә әһәмиятле була. Ганьсуй татарлары Кытай һәм Турфан (Синьцзян) арасында сәүдәдә арадашчы буларак урнашканнар. [4: 67]. Борынгыдан бәйләнештә булган әлеге халыкларның охшашлыклары булмыйча мөмкин түгел. Еш кына без теге яки бу телдә охшаш сүзләр очратабыз. Бигрәк тә ризыкка кагылышлы лексиканы әйтергә кирәк. Кытайларга да, татарлар өчен дә ризык – кыйммәтле әйбер, аны хөрмәт итәргә кирәк дигән аксиома буыннан-буынга сакланып килә. Бу – беренче уртак сыйфат.

Ризык атамаларын да истән чыгармаска кирәк. Бүгенге көндә татарларның үз итеп яшәгән күренешләре чынлыкта нәкъ менә тарихы бай булган кытайлылардан килгәне гаҗәп. Әлеге үрнәкләрнең иң күренеклесе – чәй. Үз тормышын әлеге эчемлексез күз алдына китерә алмый торган халыкка бүген гомумән аны кулланмый торган халыктан керүе тагын да ышанмаслырак күренеш. Кытайларда чәй безнең эрага кадәр өченче гасырда барлыкка килә. Бер риваять буенча, чәйне император Шэнь Нунь очраклы рәвештә ачкан, чәй агачының яфраклары император эчкән кайнар суга эләккән. Ул эчемлекнең тәмен ошатып, чәйне дәвалау максатларында куллана башлаган дип әйтелә. Вакыт узу белән чәй Кытай халкы арасында тарала башлый, аны медицина максатларында гына түгел, ә сусауны басу һәм энергияне арттыру ысулы итеп саныйлар. Кытайда махсус чәй фабрикалары барлыкка килә, анда чәй яфраклары җыела, киптерелә һәм сату өчен эшкәртелә. Бүгенге көндә исә кытайлылар инде чәй әзерләү тантанасын үзләренең гореф-гадәтләре белән таныштыру, кызыксындыру юлы буларак кына күрәләр [3: 67].

Татарларга исә чәй бары тик XVII-XIX гасырларда гына тарала, әмма бүгенге көнгә кадәр кытай теленнән килгән исеме *(茶 – chá)* генә сакланып калмый, ә һәр кешенең тормышында тотрыклы урын алып тора.

Татарларда шактый популяр булган икенче ризык – “манты” Кытай халкының 馒头 га *(mántou)* якын. Бу очракта без моны бертөрле әйтелешле булган ризык итеп кенә түгел, ә кыяфәте, әзерләү ысулы да үзара охшаш булуны күз алдында тотабыз. Кытай теленнән тәрҗемә иткәндә, 馒头 сүзе *“тутырмалы баш”* дигәнне аңлата, ягъни “эчендә ни дә булса тутырылып, баш формасында ясалган ризык”. Төрки халыкларда да, Кытайда да аларның формасы бер, икесе дә парда пешерелә, әмма эчлеге белән аз гына аерыла. Безнең халыкта – ит һәм бәрәңгедән булса, кытайларда ул баллы эчлек (персик,

кабак, сакура һәм роза кайнатмасы һ.б.) Белән дә, тозлы эчлек (гөмбә, доуфу, кәбестә) белән дә әзерләнергә мөмкин, ә ит һәм бәрәңге беркайчан да кулланылмый. Кытай халкында ит белән бәрәңге гомумән сирәк очрый торган кушылма.

Кайбер хезмәтләрдә шулай ук “пилмән”не дә кытайлылырадна килгән дип билгелиләр. Пилмән кемнең милли ризыгы дигән бәхәсләр һәм фикер каршылыклары бүгенге көнгә кадәр яши.

- Урал алдында яшәүче фин-угор халыклары (удмуртлар, коми-пермяклар).

Пилмәнне нәкъ менә алар уйлап такан дип санарга кирәклекнең иң төп дәлиле булып «пельнянь» сүзе хезмәт итә. Ул «колак-икмәк»дип тәрҗемә ителә. Пилммән чыннан да колак кебек күренә. Ул кыш көне гади капчыкта, салкын базда бик яхшы саклана. Пешерү процессы дә бик җиңел. Урал пилмәннәре түбәндәгечә әзерләнә торган ризык. Ит катгый пропорциядә формалаша: сыер ите – 45%, сарык ите – 35%, дуңгыз ите – 20%. Фаршка тагын борыч һәм күп күләмдә суган өстәлә. Шуңа күрә һәр пилмән эчендә тәмле шулпа була. Пилмәнне парда пешергәннәр, суда яки шулпада пешерү булмаган.

- Кытайлылар.

Пилмән сүзе фин-угор сүзе булса да, бу ризык кытайлыларның традицион яңа ел ризыгы булып санала. Цзяоцзы кытайларга ашарга яраклы эчлекләр белән әзерләнә. ә формасы буенча цзяоцзы тәңкәгә охшаган, аларда хәтта уртада тишек бар. Ул тишек муллык символы, сәламәтлек һәм байлык теләге. камырны традицион рәвештә онны суда болгатып ясыйлар. Ләкин эчлеге төрле: ит, яшелчәләр, суган белән йомырка, яшелчәләр белән ит. Бүгенге көндә Кытайда пилмәннәрне кыздыралар, элегрәк исә парда пешерү таралган булган. Шулай ук пилмән сүзенә охшаш борынгырак сүз дә бар икәне ачыклана – 平面 *(píngmiàn)* – «эчлеге булган токмач» дигәнне аңлаткан.

- Себерлеләр.

Камырның иң нечкә катламы һәм ваклаган боз өстәлеп тутырылган ризык. Һәм салкында саклавы җиңел. Камырга төрелгән фарш, тоз һәм боздан гына ясыйлар. россиянең европа өлешендә кабул ителгәнчә, сарымсак һәм суган юк, бары тик борыч өстиләр. камыр әзерләү өчен су белән он гына алына. тоз салынмый. онны тау итеп өяләр, ә тирәсенә бозлы су салалар. кул белән салкын камырны болгаталар. ярты сәгать тирәсе тимиләр, дымлы сөлге белән каплап куялар. эчлеге өчен өч төрле ит кулланыла: сыер ите, дуңгыз ите (сало белән сайлана), поши ите. шулай ук тозсыз, сугансыз һәм башка тәмләткечләрсез пешерелә.

Хәзерге глобализация чорында ике һәм аннан артык тел белү мөһим. Бу халыкларны берләштерә, алар арасындагы киртәләрне җимерә. Моннан тыш төрле милләт кешеләренең бер-берсен аңлавына мөмкинлек бирә. Күптеллелек нигезендә укыту гомуми тел әзерлеген һәм махсус фән максатларында чит телләрне белүне камилләштерергә, предметларны тирәнәйтергә һәм мәдәниятара укыту өлкәсен киңәйтергә, шулай ук чит телне өйрәнүдә мотивацияне арттырырга ярдәм итә. Балаларга икенче телне өйрәткәндә аларны шулай ук әлеге халыкның мәдәнияте һәм тарихы белән дә таныштыру зарур. Ә

ике телнең охшаш якларын табып өйрәнү бу процессны тагын да кызыграк һәм нәтиҗәлерәк итә.

**Әдәбият**

1. Власов В.А. Многоязычие как лингводидактический фактор методике обучения иностранным языкам и культурам. – Пятигорск: ПГЛУ, 2003. – 278 с.
2. Әхәтов Г.Х. Татар теленең лексикасы: (педагогия институтлары һәм колледжлары студентлары өчен кулланма). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1995. – 93 б.
3. Похлёбкин В. В. Еда Ее история, свойства и употребление. – М.: Центрполиграф, 2004. – 121 с.
4. Рашид-ад-Дин. Джами ат-таварих. Сборник летописей. – М.: издательство АН СССР, 1960. – 349 с.

# «ТАТМЕДИА-JUNIOR» МЕДИАРЕСУРСЛАРЫН ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ КУЛЛАНУ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ [1]

***Мубаракшина А.Р.***
***МБОУ «Многопрофильный лицей №186 «Перспектива»***
***Aliya-891163@mail.ru***

***Аннотация.*** Современные дети растут в эпохе гаджетов, ИКТ-технологий. При поддержке руководства Республики Татарстан реализуется множество медиа-проектов для детей на татарском языке. В свою очередь данные медиаресурсы необходимо включать и в процесс обучения. Детей могут заинтересовать интересные медиаматериалы Татмедиа-Junior, которые в наиболее доступной форме освещают татарскую культуру, быт, классическую и современную литературу, также природу, животный мир родного края и др. Применение данных медиаресурсов на уроках играет большую роль в мотивации ребенка уже с начальных классов к использованию родного языка не только на уроках, но и в повседневной жизни.

***Ключевые слова:*** Татмедиа-Junior, «Бәби сүз», «Беләсем килә», «СалаваTIK», интерактив методика, инновацион технология, ми штурмы, сүзләр болыты, кроссворд, ребус, пазл, интервью.

Заманча укыту методикасында репродуктив ысуллар сирәк кулланыла, аларны инновацион технологияләр алыштырды. Татар телен укыту методикасы бүгенге ИКТ технологияләр чорында гасырдан артык тарихы булган традицион укыту ысулларының интерактив алымнар белән үрелеп үсешенә йөз тотты. Укучыны татарча тыңларга, аңларга, фикерләүгә һәм сөйләшүгә алып чыга торган кызыклы медиаресурсларга ихтыяҗ туды. Шул уңайдан, Татмедиа-Junior татар яшьләре өчен тәкъдим иткән яңа форматтагы видео-контент мәктәп яшендәге балалар өчен уңышлы санала. Социаль экспериментлар, интеллектуаль бәйге, Татарстан буйлап сәяхәт, фольклор, классик һәм заманча җырлар һ.б. юнәлешләрне яктырткан яшьләрнең медиа-проектлары арасында башлангыч сыйныфта татар теле дәресләрендә кулланырга мөмкин булган күп кенә кулланма материаллар бар. Татар милли журналистикасының максаты татар яшьләренә карарга кызыклы һәм мәгълүматлы тапшырулар эшләү булса, татар теле укытучысының шул тапшырулар нигезендә балада ана теле предметына карата мотивация булдыру һәм татар сөйләмен көндәлектә куллануга этәрү.

Башлангыч сыйныфта укучы рус телле балаларга татар телен укытуда уңышлы проектлар булып, нигездә, «Салават күпере» журналы редакциясенең «Бәби сүз», «Беләсем килә», «СалаваTIK» материаллары тора. Шул ук вакытта «Сабантуй» журналы редакциясе эшләгән «Шәвәлидән сора», «Тәҗрибә», «Идел» журналы редакциясенең «Социаль эксперимент», «Сораштыру» тапшыруларыннан да аерым бер фрагментларны кисеп күрсәтергә мөмкин.

[1] Мәкалә ТР Фән һәм мәгариф министрлыгының «Безнең яңа укытучы» гранты проекты нигезендә языла.

Шулай да башлангыч сыйныфларның яшь үзенчәлегенә туры килгән медиаресурларны «Салават күпере» журналы редакциясе тәкъдим итә.

**«Бәби сүз»** тапшыруларын башлангыч сыйныф укучыларының яшьтәше Зөбәйдә алып бара [1]. Бу, беренче чиратта, дәрестә укучылар арасындагы киеренкелекне юкка чыгарырга, укучы белән алып баручының җиңел «элемтәгә» керүенә китерә. Тапшыру табышмак, викторина, сорау-җавап рәвешендә төшерелгән. Зөбәйдә төрле темаларга кагылышлы сорауларны биргәндә, экранга кызыклы рәсемнәр чыга, укучы, үзе дә сизмәстән, Зөбәйдәнең сорауларына җавап эзләп, җавап бирергә ашыга. Күп очракта, бала тапшыруны алып баручы сорауларына җавап биреп утырганда, аның белән татарча әңгәмә корганын сизми дә кала. Режиссер бик кызыклы алым файдалана: экран каршында утыручыга җавапны уйлап табар өчен берничә секунд буш вакыт бирелә, шуннан соң гына Зөбәйдә «Әйе, дөрес» дип, җавапны әйтә, үзе белән берлектә җавапны кабат кабатларга чакыра, экранга дөрес җавап иҗекләргә бүленгән рәвештә һәм сүз басымы куелып чыга. «Бәби сүз» башлангыч сыйныфлар яхшы белергә тиешле күп төрле темаларны колачлый. Анда төсләр, формалар, саннар, уенчыклар, савыт-саба, кыргый/ йорт хайваннары, кошлары, агачлар турындагы белемнәрне кечкенә Зөбәйдә тест формасында тикшерә. Тапшыруны карачы бала дөрес җавапны сайлап алырга һәм кабатларга тиеш. Дәрестә бу төр видеоларны караганнан соң, интерактив алымнардан «кар йомгагы», «карусель» алымнарын куллану отышлы. Ул пассив лексиканы активка күчерергә, укучыга үзара диалог корырга ярдәм итә.

**«Беләсем килә»** проектында төрле темага кагылышлы һәр бала белергә тиешле мәгълүматны диктор иплән һәм ашыкмыйча җиткерә [2]. Җөмләләр гади һәм җиңел аңлаешлы. Аудирование өчен җайлы материал. Шулай да бу тапшыруларда мәгълүмат күп. Рус телле балага әлеге ресурсларны тәкъдим итәр өчен алдан ук сүзлек белән эшләү мөһим. Тән әгъзалары, яшелчәләр, ризыклар, ярмалар, ел фасыллары, агачлар, чәчәкләр, бөҗәкләр, кошлар, кыргый җәнлекләр, диңгез хайваннары һ.б. темаларны яктырткан 2-3 минутлык видеолар кечкенә балалар өчен кызыклы сюжетлы рәсемнәр белән баетылып бирелә. «Беләсем килә» тапшыруындагы иң төп фикерне отып калу, төп лексиканы истә калдыру, кабатлау, ныгыту максатыннан «футбол тубы» алымы, кроссворд алымнарын куллану отышлы. «Шакмак» алымы төп мәгълүматны аңлау, анализлау, диалогка керү, монолог сөйләүгә дә этәрергә мөмкин.

«**СалаваTik**» проекты җырлары, иң беренче чиратта, сыйныфта уңай-психологик халәт тудыра, музыка бала күңеленә уңай йогынты ясый [3]. Җырны тыңлау – аудированиенең бер төре, җырны акустик яктан кабул итү булса, караокэ форматында җыр сүзләренең экранга чыгуы ишетеп кенә түгел, күреп, укып аңлауга да китерә. Шул ук вакытта җыр текстын клипның сюжеты да баета, эчтәлеккә эмоциональ төсмер өсти – сүзләрне аңламаган рус телле баланың төсле картиналар, әкият персонажлары, таныш геройлар аша текстның ни турында икәнен уйлап табуына юл ача. Балалар нәкъ клипта күргән хәрәкәтләрне кабатлый, үзеннән дә өстәп яңаларын уйлап таба, дустын көлдерергә тырыша, шулай итеп дәрескә күтәренке күңелле рух өсти. Татар

теле дәресләрендә Салаватик җырларын татар мәдәнияте белән таныштыру максатында гына түгел, сөйләм һәм язма күнекмәләрне ныгыту өчен, аерым алганда, телнең фонетик, лексик, грамматик кагыйдәләрен искә төшерү, кабатлау, тирәнәйтүдә төрле биремнәрдә кулланырга мөмкин. Салаватик җырларын фонетик күнегүләр эшләгәндә еш кына карточкалар белән парлар, йә төркемнәрдә эшләү уңайлы. Лексик күнегүләр эшләгәндә, җыр сүзләрендә очраган метафора, чагыштырулар белән эшләү баланың тел байлыгын гына түгел, фикерләү сәләтен дә арттыра. Морфологик күнегүләр эшләгәндә дә тиешле җавапны балалар әйтеп кенә калмыйлар, хәрәкәтләр ярдәмендә дә нәкъ клиптагыча кабатлап күрсәтәләр.

Әдәби уку дәресләрендә укучыларга Татмедиа-Junior тапшыруларын өй эшенә өстәмә материал итеп тә бирергә мөмкин. Күп очракта бала, видеоматериалдагы мәгълүматны үзләштереп, алып баручы, диктор, җырчы ролендә башкарырга әзерләнеп килә. Әлеге проектлар татар халкының мәдәнияте, сәнгате, бай мирасына, татарларның көнкүрешенә, туган як табигатенә карата кызыксынуны арттыра, аерым бер лексика ярдәмендә татар теленең милли картинасын күзаллауны булдыра. Шәһәр шартларында татар телен өйрәнүче балаларга мәгълүматны җиңел үзләштерергә мөмкинлек тудыра.

**Әдәбият**


1. Бәби сүз: «Салават күпере» // https://www.youtube.com/results?search_query=бәби+сүз (дата обращения 10.02.2023)
2. Беләсем килә: «Салават күпере» // https://www.youtube.com/results?search_query=беләсем+килә (дата обращения 10.02.2023)
3. СалаваTIK: «Салават күпере» https://www.youtube.com/results?search_query=салаватик (дата обращения 10.02.2023)

# ПРИЁМЫ ФОРМИРОВАНИЯ ЧИТАТЕЛЬСКОЙ ГРАМОТНОСТИ У ДЕТЕЙ МЛАДШЕГО ШКОЛЬНОГО ВОЗРАСТА НА УРОКАХ АНГЛИЙСКОГО ЯЗЫКА

***Муллина Е. М.***
***Казанский федеральный университет***
***lenochka_mullina@mail.ru***

***Аннотация.*** Статья представляет собой исследование, посвященное приемам, используемым для развития читательской грамотности у детей младшего школьного возраста на занятиях по английскому языку. Работа с текстами на уроках английского языка представляется как ключевой элемент в формировании интереса к языку, повышении мотивации к изучению и улучшении умений в области чтения.

***Ключевые слова: ч***итательская грамотность, читательская грамотность на английском языке, приемы читательской грамотности, иностранный язык.

Когда дети переходят в начальную школу, это не просто изменение, а важный поворот в их жизни. На этой стадии формируются ключевые навыки, необходимые для успешного обучения и самостоятельной работы. Чтение играет значительную роль в этом процессе, поскольку через чтение дети усваивают новые знания, что впоследствии помогает им развивать умение самостоятельного обучения. Поэтому крайне важно, чтобы каждый первоклассник приобрел надежные навыки чтения, которые послужат фундаментом для их личного образования.

Чтение - это комплексное умение, включающее как понимание содержания, так и технические навыки. Это не просто расшифровка текста, а важный аспект, который необходимо развивать на протяжении всей жизни в различных областях деятельности и взаимодействия.

В процессе обучения чтению на иностранном языке дети улучшают свои навыки правильного произношения и различения звуков, слов, фраз и предложений на изучаемом языке, а также развивают умение сохранять правильную интонацию. Кроме того, ученики усваивают основные грамматические правила изучаемого языка, научившись распознавать лексику и грамматику в текстах и аудиоматериалах, применяя их в устной речи. Они также осваивают навыки чтения вслух, способны читать как вслух, так и бесшумно, используя различные методы.[5]

Во время чтения ученики могут столкнуться с различными трудностями как на родном, так и на иностранном языке. Переход в среднюю школу может быть вызовом из-за сложностей в технических аспектах чтения, например, непонимания содержания на иностранном языке. Одной из проблем чтения на английском являются его орфографические и графические особенности. Например, из 26 букв английского алфавита лишь четыре имеют сходство с русскими по форме и звучанию.[1]

Дополнительной сложностью является произношение гласных, их сочетаний и определенных согласных букв, которое может меняться в зависимости от их положения в словах.

Также в английском языке встречаются случаи, когда слова не произносятся согласно общим правилам. В таких ситуациях рекомендуется учащимся ознакомиться с материалом несколько раз и запомнить его. Поскольку им приходится помнить специфические правила и правильное произношение слов, скорость чтения снижается.

В начале обучения ученики знакомятся с буквами английского алфавита, учатся соотносить звуки с буквами, начинают читать вслух и беззвучно отдельные слова, фразы и короткие тексты на основе учебного материала.[3]

Стоит также упомянуть Евгения Ивановича Пассова – выдающегося методиста современности, автора множества трудов по методике обучения иностранным языкам, развитию устной речи, планированию занятий и созданию учебных комплексов для успешного изучения новых языков.[2]

При обучении иностранному языку используются четыре основных вида учебно-речевой деятельности: Рецептивные – это аудирование и чтение. Продуктивные – это говорение и письмо.

В рамках учебной практики чтение представляет собой один из компонентов. Необязательно, чтобы все школьники испытывали страсть к чтению. Ключевой задачей учителя является создание увлекательной и захватывающей обстановки во время чтения текстов на уроке английского языка для возбуждения интереса учеников.

Главная цель обучения в начальной школе должна быть нацелена на развитие умения читать с пониманием, стремясь к полному осмыслению информации в текстах, в том числе и на уроках английского языка.

Итоги изучения основной учебной программы начальной школы в метапредметной области должны показывать способность к осознанному чтению текстов различных стилей и жанров в соответствии с поставленными целями, а также умение формировать устное высказывание в процессе общения и составлять тексты как устно, так и письменно на различные учебные темы.[3]

Учитывая это, важно рассмотреть понятие "смысловое чтение". В примерной основной образовательной программе начальной школы смысловое чтение означает понимание цели чтения и выбор подходящего метода в соответствии с этой целью, умение извлекать нужную информацию из текстов различных жанров, умение отличать важные детали от второстепенных, способность понимать и оценивать тексты разных стилей (включая художественные, научные, публицистические и деловые), а также осознание и адекватная оценка лексических средств, используемых в средствах массовой информации.

Читательская грамотность учеников начальной школы представляет собой сформированное умение осуществлять осознанное и целенаправленное чтение. Рассмотрим различные типы чтения на английском языке, направленные на понимание смысла текста. Согласно С.К. Фоломкиной, можно

выделить несколько видов чтения в зависимости от уровня понимания содержания текста и его осмысленности.

Стоит более детально рассмотреть каждый из методов чтения.

1. Сканирующее чтение (skimming) - это прием, который используется для получения общего представления о тексте. Основная цель этого метода - понять основное содержание текста. Обычно его используют для первичного ознакомления с материалом, чтобы определить, содержит ли он необходимую информацию и стоит ли более детально изучать его.

2. Чтение для основной идеи (reading for the main idea) - это форма аналитического чтения, при которой учащийся изучает весь текст без специфической цели извлечения определенной информации. Такое чтение часто называется "чтением для себя", поскольку не предполагает последующих задач. Основная цель этого вида чтения - понять главную идею текста.

3. Детальное чтение (detail reading) - это метод, который предполагает внимательное и глубокое понимание всей информации, представленной в тексте, а также критическое мышление об этой информации. Подчеркнутый аспект детального чтения заключается в понимании всех деталей, содержащихся в тексте.

4. Чтение для конкретной информации (reading for specific information) – это подход к чтению, направленный на поиск определенных и значимых данных. Его главная цель состоит в быстром обнаружении в тексте нужной информации, такой как факты, описания, числовые значения и другие детали. В учебной практике целевое чтение применяется для выполнения заданий, связанных с текстом.[6]

В процессе обучения чтению в учебных учреждениях основной акцент делается на развитии и улучшении умений чтения как важной составляющей речевой деятельности, а не просто на использовании различных методов чтения, которые служат средством достижения общей цели.

**Литература**

1. Никитенко З.Н. Формирование универсальных учебных действий – приоритет начального иноязычного образования // Иностранные языки в школе. 2010. №6. С. 47

2. Пассов Е.И. Основы методики обучения иностранным языкам / Москва: Рус. яз., 1977. 216 с

3. Рогова Г.В., Верещагина И.Н. Методика обучения английскому языку на начальном этапе в общеобразовательных учреждениях. Москва: Просвещение, 2000. 105 с..

4. Современная филология: материалы II Междунар. науч. конф. Уфа: Лето, 2013. С. 4-7. / URL https://moluch.ru/conf/phil/archive/78/3222/ (дата обращения: 08.01.2024).

5. Уфимцева О.В. Развитие учебной иноязычной лексической компетенции в процессе изучения иностранного языка будущими специалистами по связям с общественностью: дис. … канд. пед. наук. Урал. гос. пед. ун-т. Екатеринбург, 2014. - 19 с.

# ИСПОЛЬЗОВАНИЕ МЕДИА ТЕКСТОВ ПРИ ИЗУЧЕНИИ АНГЛИЙСКОГО ЯЗЫКА

***Мухарлямова Л.Р., Мосеев А.Ю.***
***Казанский федеральный университет***
***mukharlyamova@mail.ru* , wilkio58@gmail.com**

***Аннотация.*** Использование медиа текстов на занятиях английского языка возрастает с каждым днем. Это объясняется тем, что медиа тексты приближают обучающихся к реальным информационным источникам. Авторы отмечают особенности работы с такого рода текстами при изучении английского языка, указывают принципы использования средств массовой информации, дают рекомендации преподавателям при работе с медиа текстами.

***Ключевые слова:*** медиа тексты, медиа материалы, СМИ, методика обучения иностранным языкам, изучение английского языка.

Основными источниками информации на данный момент являются такие средства коммуникации, как интернет, газеты, телевидение, радио. Одними из первых таких средств можно отметить газеты. Как пишет А.Н. Васильева, среди всех средств массовой информации особенно важная роль принадлежит газете. Это связано как с самой широкой повседневной доступностью газеты, так и с огромным диапазоном многопрофильного выбора, и с информационной оперативностью газеты [1].

Нельзя не отметить динамику роста использования средств массовой информации на занятиях английского языка. При помощи информационных технологий преподаватели могут использовать различные медиа для обогащения языковой среды своего класса, ускорения обучения и усвоения предмета, а также формирования интереса к самому предмету [3].

Использование такого инструмента, как аутентичные источники информации на занятиях иностранного языка не является новинкой в сфере образования и имеет под собой долгую историю. На смену книгам и древним трудам приходили газеты и журналы, а их постепенно заменяли телевидение, средства медиа из Интернета, такие как подкасты, блоги, авторские видеоматериалы, научно-популярные сообщения.

«Тексты массовой информации, или медиа тексты, являются сегодня одной из самых распространенных форм бытования языка» [2: 7].

«Представляя собой прекрасный образец современного английского речеупотребления, медиа тексты включены в учебники самых различных уровней и направлений» [2: 246]. Применение медиа материалов на занятиях иностранного языка может быть эффективно на различных уровнях владения языком. Перед обучающимися могут представать различные задачи вроде критического анализа представленного текста или понимания и передачи прочитанного.

Во время создания занятия с использованием медиа текстов преподаватель имеет дело с такими факторами как объем текста (количество символов или слов), тема и содержание статьи, уровень владения языком у обучающихся. Таким образом перед учителем предстает широкий выбор из задач, которые можно поставить перед обучающимися, от понимания прочитанного до письменного рассуждения на заданную тему.

Преподаватели не должны избегать использования медиа материалов в классе только потому, что они сложны для учащихся. Существует несколько способов сделать материалы полезными для разных уровней учащихся. Очень важным моментом, повышающим успешность использования медиа материалов в аудитории, является тщательная проработка заданий. Несмотря на сложность текста, задания должны соответствовать уровню учащихся.

Преподаватели должны предпринять все необходимые шаги для эффективного использования медиа ресурсов. Средства обучения должны подбираться в соответствии с возрастным уровнем учащихся. Существуют общие принципы использования средств массовой информации:

1. Структурирование: Средства массовой информации необходимо встроить в саму образовательную программу так, чтобы они органично дополняли методический материал, а не заменяли его.
2. Подбор: Средства массовой информации должны быть правильно подобраны и скоординированы преподавателем.
3. Планирование: Средства массовой информации должны быть доступны в соответствии с потребностями учебной программы.
4. Опыт: Материалы англоязычных СМИ должны взаимодействовать напрямую с опытом обучающегося.
5. Приготовление: материал должен быть изменен так, чтобы он соответствовал уровню владения языком у обучающегося.
6. Оценивание: Средства массовой информации должны регулярно оцениваться с точки зрения их использования, влияния на обучение и их функций.

Исходя из вышеописанного, мы можем сформулировать следующие рекомендации работы с медиа текстами:

- Предложить учащимся прочитать отрывки из газетных статей и обобщить информацию.
- Попросить обучающихся поразмышлять над тем, что они знают о медиа текстах.
- Дать учащимся заголовок и показать сопровождающую его фотографию.
- Попросить обучающихся предугадать сюжетную линию.
- Позволить учащимся использовать лексику во время действия.
- Побуждать обучающихся следить за смыслом всего текста, а не стараться понять каждое слово.
- Облегчить учащимся понимание сложности текста, угадывание низкочастотной лексики и т.д.

- Разделить обучающихся на группы и попросить их прочитать короткую статью. Прочитайте статью вместе, составьте вопросы по статье и обменяйтесь статьей с другой группой, которая предоставила вопросы. После того как каждая группа ответит на вопросы, посадите учеников в пары, по одному от каждой группы, чтобы обсудить их ответы.

Средства массовой информации могут быть использованы для различных типов обучающихся (визуальные, аудиальные и кинестетические). Обучающиеся взаимодействуют с различными техническими средствами и цифровыми носителями.

Использование газет, брошюр, анкет соискателей и новостных выпусков дает учащимся возможность аутентичного обучения на реальных носителях. Такой инструмент способен отображать происходящие события, позволяют оценивать и работать с повседневной информацией и проследить взаимосвязь того, что было изучено в школе с тем, что происходит в мире и в обществе. «Особенная роль аутентичных СМИ в методике преподавания ИЯ заключается в том, что они максимально приближают обучающихся к реальным информационным источникам и «погружают» в мир актуальных событий» [3: 407].

Для развития навыков критического мышления преподаватели могут использовать средства массовой информации. Таким образом, при наблюдении преподавателей, обучающиеся могут вступать в оживленные дискуссии, развивая при этом навыки понимания и осознания прочитанного текста, создавать собственные медиапроекты на основе уже существующих. И в результате обучающиеся будут способны осмыслить уже существующий опыт медиа текстов и сформировать свои медиа, при этом развивая навыки владения языком.

## Литература

1. Васильева А.Н. Газетно-публицистический стиль речи. / А.Н. Васильева. – М.: Русский язык, 1982. – 200 с.
2. Добросклонская Т.Г. Вопросы изучения медиатекстов (опыт исследования современной английской медиаречи) / Т.Г. Добросклонская: Монография. – М.: Едиториал, 2005. – 288 с.
3. Пиванова Ю.Е. Важность применения материалов СМИ при обучении иностранному языку [Текст] / Ю.Е. Пиванова // Молодой ученый. – 2018. – № 20 (206). – С. 407-408.

# КОММУНИКАТИВ ТЕХНОЛОГИЯЛӘР НИГЕЗЕНДӘ СӨЙЛӘМ ТЕЛЕН ҮСТЕРҮ


***Нәбиуллина Г.Ә.***
***Казан федераль университеты***
***GuzelNab2@yandex.ru***



***Аннотация.*** Сөйләм үстерү эшчәнлегенең төп максаты информацион-коммуникатив технологияләр, уен-ситуацияләр, күрсәтмәлелек кулланып, сөйләмгә өйрәтү, аралашу теләге тудыру. Болар барысы да балаларның сүз байлыкларын, сүзләрне отып калу аша хәтерен, зиһенен үстерә һәм иң мөһиме, аралашуда катнаша белү күнекмәсен үстерә.



***Төп төшенчәләр:*** Мәктәпкәчә тәрбия, Яңартылган Федераль дәүләт белем бирү стандартлары, коммуникатив технологияләр, бәйләнешле сөйләм.


Мәктәпкәчә яштәге балаларны дөрес итеп сөйләшергә**,** үз фикерләрен дөрес итеп әйтә белергә өйрәтү, сүз байлыкларын арттыру – балалар бакчасының төп бурычларыннан берсе булып тора. Чөнки тел киләчәктә баланың барлык фәннәр буенча белем алуына юл ача, аның фикер йөртү сәләтен үстерә һәм акыл үсешенә уңай йогынты ясый.

Белгәнебезчә, баланың теле ана теле белән ачыла, аның ярдәмендә әйләнә-тирә дөнья белән мөнәсәбәткә керә, аң-белем дәрәҗәсе үсә, дөньяга карашы да киңәя бара. Туган телгә, әти-әнигә, туганнарга, милләтеңә карата ихтирам хисләре тәрбияләү, әхлак кагыйдәләрен, рухый кыйммәтләрне аңлау, үзләштерү, үз ана телеңнән башлана. Фикер ияләре дә ана телен «тәрбия коралы» дип атыйлар. Баланың аңы үсү, белеме арту, чынбарлыкны танып белүе, чын кеше булып тәрбияләнүе аның үз туган телен яхшы белүенә бәйләнгән. Шуңа күрә балаларны ана теленә өйрәтү, аны үз телендә иҗат итә белергә, әдәби һәм мәдәни байлыкларыбыз белән кызыксыну, хөрмәт тәрбияләү эшен мәктәпкәчә яшьтән үк башлау зарури.

Сөйләм – ул сенсор системасы, хәтер, фикерләү, фантазия, эмоцияләр белән тыгыз бәйләнгән эшчәнлекнең аерым төре. Бу процесслар, кече һәм мәктәпкәчә яшьтә актив үсеш ала.

Баланы аралашу һәм мәдәният чарасы буларак сөйләм осталыгына өйрәтү – төп бурыч. Димәк, балаларның сөйләме тирә-юньдәгеләргә аңлаешлы булырга, яшьтәшләре һәм өлкәннәр белән аралашуда кыенлыклар тумаска тиеш. Тәрбияче-педагогның төп максаты – балаларда аралашу, сөйләшү теләге булдыру, ирекле аралашу, дәрес-шөгыльләрдән тыш сөйләм активлыгын булдыру.

Балалар бакчаларында сөйләм үстерү методикасы түбәндәге бурычларны үз эченә ала: сөйләмне аралашу чарасы буларак үзләштерү; актив сүзлекне баету; авазларны дөрес әйтү культурасын үстерү; бәйләнешле сөйләм үстерү; иҗади сөйләм телен үстерү; матур әдәбият белән танышу; фонематик ишетү сәләтен камилләштерү, авазларны ишетеп аера белү, анализлау күнекмәләрен булдыру.

Сөйләшә белү – иң беренче чиратта, тиешле сүзлек запасына ия булу. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның актив сүзлеген баету телнең төп сүзлек фонды хисабына бара. 2 яшьтә бала сүзлегендә 270-300 сүз 2,5 яшьтә 400-500 сүз булса, 3 яшьтә 1000-1500 сүзгә җитә. Балалар лексикасын киңәйтү-үстерү өчен, комплекслы-тематик планлаштыру ярдәмендә уңай шартлар тудырыла. Әйтик, «кыш» темасы өйрәнелә икән, балалар сүзлеге дә әлеге тема кысаларында тулыланырга һәм активлашырга тиеш.

Баланың сүзлек запасы арттыру өчен, яңа сүзләрне кабатлау, активлаштыру өчен, сүзле уеннар, дидактик һәм ситуатив уеннар, мини викториналар ярдәмгә килә. Сюжетлы-рольле уеннар вакытында да балаларның сүзлек запаслары байый, балалар дөрес җөмләләр кулланып сөйләшергә өйрәнәләр. Мондый юнәлештәге эш төрләре балаларның иҗади фикерләүләрен һәм образлы күзаллауларын активлаштыра.

Сөйләмнең “Аваз культурасы” дигән төшенчә киң мәгънәдә кулланыла. Ул үз эченә яңгырашлы сөйләмне (ягъни аваз әйтелешен) характерлый торган әйтелеш сыйфатларын (интонация, темп һ.б.), алар белән бәйләнешле сәнгатьлелекнең туры килүен (мимика), шулай ук аралашу культурасы элементларын ала. ФДББСта бу мәсьәлә «сөйләмнең тавыш һәм интонацион культурасын, фонематик ишетүне үстерү» дип атала һәм туган телнең интонацион төзелешен, басым системасын, сүзләрнең әйтелешен һәм аңлаешлы итеп сөйләү, шигырьләр уку күнекмәләрен үзләштерүне күз алдында тота.

Һәр бала авазларны төрле темпта үзләштерә, әмма биш яшькә кадәр һәр сәламәт бала туган телнең барлык авазларын дөрес әйтергә тиеш. Бу гамәлдә расланып бетмәскә мөмкин, чөнки сөйләмгә тәэсир итүче башка күп төрле факторлар бар. Бу – сөйләм тирәлеге, ата-аналарның озак вакытлар аның теле белән сөйләшүләре, бала сөйләменә өлкәннәрнең игътибарсызлыгы һ. б.

Кагыйдә буларак, бәйләнешле сөйләм ике өлештән тора: диалог һәм монолог. Аның өчен төзелеш материалы булып сүзлек һәм сөйләмнең грамматик төзелешен үзләштерү тора. Грамматик төзелеш – сүзләрне үзгәртү, аларны җөмләләргә берләштерү, баланың олылар сөйләмен тыңлап аңлау сәләте. Моннан тыш, балаларга катлаулы төзелешле җөмлә калыпларын үзләштерергә ярдәм итүче махсус сөйләм күнегүләре үткәрергә мөмкин.

Балаларның иҗади сөйләмен үстерү дә мөһим бурычларның берсе. Моның өчен гади кыска хикәяләр төзеп сөйләү, шигъри фразалар язуда катнашу, әкият сюжетында яңа борылышлар уйлап табу кебек эш төрләре тәкъдим итәргә мөмкин һ.б.

Сәнгатьле итеп сөйләргә өйрәнү барышында, баланың сүз байлыгы арта, бала дөрес, аңлаешлы итеп сөйләргә өйрәнә. Сүзлек фонды яңа сүзләр белән баетыла.

Бәйләнешле сөйләм үстерү матур әдәбият белән таныштыру аша да гамәлгә ашырыла. Әти-әниләр өйләрендә балаларга кызыклы әкиятләр укыса, татарча тапшырулар караса, бу әлбәттә сөйләм үстерүгә уңай йогынты ясар иде. Төп проблема шунда ки, китап күп гаиләләрдә кыйммәт булудан туктаган, балалар өйдә уку-тыңлау тәҗрибәсен ала алмыйлар. Бу хәлне үзгәртү тәрбияче

педагоглардан да тора. Китап балаларның юлдашы булырга, аларның яраткан шөгыленә әверелергә, әдәбият, китап белән кызыксыну салынырга тиеш. Әдәби әсәрне укыганнан соң, сюжеты буенча әңгәмә оештырырга мөмкин. Укылган әсәр нигезендә инсценировкалар, уеннар үткәрү балаларның әдәбиятка-театр сәнгатенә булган кызыксынуларын булдыра, актерлык осталыгын да үстерә.

Шулай итеп, балалар бакчасында сөйләм үстерү бурычлары дөрес сөйләшү-аралашу, тыңлап аңлау күнекмәләрен булдыруга юнәлтелгән. Бу бурычлар барлык төркемнәрдә дә балалар бакчасында булган вакыт дәвамында тормышка ашырыла. Балаларның монологик, диалогик сөйләм телләрен үстерү, сәнгатьле сөйләмгә өйрәтү, сүзлек запасларын баету, аваз культураларын үстерү буенча яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып төрле эш төрләре тәкъдим ителә.

Балаларның сөйләмен үстерүдә яшь үзенчәлекләренә бәйле рәвештә төрле ысуллар, алымнар кулланырга мөмкин. Әлеге ысулларны сөйләм үстерүнең төп 3 методына берләштереп карарга мөмкин:

1) күрсәтмәлелек методы: рәсемнәр, картиналар буенча диалоглар төзү, уенчыклар турында тасвирлап сөйләү, алар буенча хикәя төзү, табигать күренешләрен күзәтү һәм тасвирлау, өлкәннәрнең эшчәнлеген карап бәяләү, тәҗрибә үткәрү; татарча видеоматериаллар, мультфильмнар карап фикер алышу; спектакльләр тамаша кылу; һ.б.

2) сүз методлары: шигырьләр, хикәяләр, экиятләр уку, эчтәлеген сөйләү; әңгәмә үткәрү, сүзләр, сүзтезмәләр, җөмләләр, хикәяләр төзү, хикәяне дәвам итеп сөйләү; мини-викториналар, ребуслар чишү һ.б

3) гамәли методлар: үз исеменнән вакыйга тасвирлап сөйләү, хәрәкәтле, дидактик уеннар, пластик этюдлар, күмәк җырлы уеннар, хәрәкәтләнү күнегүләре, сәхнәләштерү уеннары, иллюстрацияләр куллану махсус оештырылган сөйләм ситуацияләре, сюжетлы-рольле уеннар, хәрәкәтле уеннар һ.б.

Сөйләшергә өйрәтү өчен, баланы мөмкин кадәр күбрәк сөйләмгә җәлеп итәргә кирәк. Бу юнәлештә яңача методик алымнар һәм чаралар куллану, электрон ярдәмлекләр, аудио - һәм видеоматериаллар файдалану яхшы нәтиҗәләргә китерә дип саныйбыз.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, төрле характердагы инновацион технологияләр баланың әйләнә-тирәне күзәтү һәм танып-белү күнекмәләрен, иҗадый эшчәнлеген һәм сөйләм телен үстерүгә, аңа акыл һәм әхлакый (экологик культура, гигиена, юл йөрү кагыйдәләре һ.б.) тәрбия бирү һәм белемгә омтылыш булдыруга юнәлтелгән.

**Әдәбият**


1. Нәбиуллина Г.Ә., Гыйләҗева Л.Г. Нәниләргә элифба. Хәрефләр илендә. (Азбука для малышей. В стране букв). – Казань: Раннур,2011. – 96 с.
2. Нәбиуллина Г.Ә., Гыйләҗева Л.Г. Нәниләргә элифба. Сүзләр илендә. (Азбука для малышей. В стране слов). – Казань: Раннур, 2011. – 104с.

3. Нәбиуллина Г.Ә., Гыйләҗева Л.Г. Нәниләргә әлифба. (Азбука для малышей). – Казань: Раннур, 2011. – 45с.
4. Нәбиуллина Г.Ә., Гыйләҗева Л.Г.Нәниләргә әлифба. Иртәгә мәктәпкә. – Казан: Раннур, 2012. – 120 б.

# ТАТАР ЖУРНАЛИСТИКАСЫ ФӘНЕН УКЫТУДА ЯСАЛМА ФӘҺЕМ КУЛЛАНУ

***Нәбиуллина Г.Ә., Хәялиева Р.Р.***
***Казан федераль университеты***
***GuzelNab2@yandex.ru; 0702007@mail.ru***

***Аннотация.*** В статье рассматриваются варианты применения искусственного интеллекта в образовании и в журналистике. Изучение возможностей создания искусственного интеллекта на татарском языке является большим шагом в заботе о родном языке. Проанализированы необходимость внедрения искусственного интеллекта в процесс обучения, а также технологии, которые уже используются.

***Ключевые слова:*** искусственный интеллект, информационные технологии, обучение, журналистика, татарский язык

Соңгы вакытта ясалма фәһемнең (ЯФ) кешелекнең барлык өлкәләренә үтеп керүе хакында күп ишетергә туры килә. Интернетта, массакүләм мәгълүмат чараларында ясалма фәһем тарафыннан барлыкка китерелгән текстлар һәм сурәтләр төп тренд буларак кабул ителә. Шул ук вакытта мәгариф системасына ясалма фәһемне кертү хакында сөйләшүләр арта, тәҗрибәләр уздырыла. Татар телендә ясалма фәһем булдыру мөмкинлекләрен өйрәнү туган телебезне кайгыртуда зур адым булып тора.

Тиз арада безнең тормышта инкыйлаб ясарга җыенган ясалма фәһем нәрсә соң ул? Нейрочелтәрләр дигәндә нинди системаны күз алдына китерергә?!

Ясалма фәһем ул бик күп төрле көчле технологияләрне берләштергән гомуми бер атама. Нейрочелтәрләр – ясалма интеллектның конкрет реализациясе. Димәк, нейрочелтәр – ясалма фәһемдә кулланыла торган механизмнарның берсе, әмма бердәнбер түгел. Ясалма фәһем ул үзе күргән информациягә, җыйган мәгълүматына таянып, яки яңалык, яки искелекне берләштереп нindидер яңа информация җитештереп бирә. Ягъни кайберләре бик күп төрле рәсемнәр күреп яңа рәсемнәр ясарга өйрәнә, кайберләре интернеттагы бик күп төрле текстларны күреп, анализлап аның буенча яңа текст яза. Ясалма фәһемдә белем базасы буларак кешенең баш миенә охшатырга тырышып ясалган нейроннар системасы тора. Шуңа күрә ул кешенең информацияне ничек күрүенә, кабул итүенә охшатып мәгълүмат эзли һәм шуны тәкъдим итү белән шөгыльләнә дип әйтү дөрес булыр.

Ясалма фәһемнең нигезе өч өлештән тора. Беренчесе – мәгълүмат (ЯФ нинди мәгълүмат ала, шуны чыгара). Икенчесе – сыйфатлар (зур мәгълүматны алып, компьютерга аңлаешлы рәвештә бирер өчен кулланыла, ягъни мәгълүмат детальләргә бүленә). Өченчесе – алгоритм (ЯФ мәгълүматны туплап, аны төрле сыйфатлар дәрәҗәсендә күрсәтеп, нindидер алгоритм рәвешендә безгә җаваплар бирә).

Классификация буенча ясалма фәһемне көчле һәм көчсез төрләргә бүлеп карыйлар.

Көчсез ЯФ тар класслы интеллектуль мәсьәләләрне, көчле ЯФ күп төрле интеллектуль мәсьәләләрне чишә. Көчле ясалма фәһем турында бик күп мифлар йөри, шуларның берсе – ул кешелекне бетерергә дә мөмкин дигән фикер. Әмма белгечләр исбатлавынча, андый системадан әлегә без бик ерак торабыз. Әлегә безнең тормышта көчсез ясалма фәһем – тар класслы интеллектуль мәсьәләләрне чишә ала торган система гына эшли. Хәзерге ЯФ безгә бик көчле булып күренсә дә ул бик чикле. Алар билгеле бер форматка гына корылган һәм безгә шул форматтагы эшләрне генә башкарап чыга ала. Рәсем ясарга җайланганы рәсем ясый, текст белән эшләргә җайлашканы безгә шәп итеп текст язып бирергә мөмкин.

Игътибар итсәк, инде бүген үк ЯФ тормышның барлык аспектларын да каплап алып бара. Социаль челтәрләрдәге «акыллы» ленталар, автоматик рәвештә текстлар язу, анимация, яңа стильдә рәсем, илююстрацияләр ясау, финанс анализлар, медициналда рак клеткаларын табу, мәгариф өлкәсендә нейрочелтәрләр кулланылу хакында еш ишетергә туры килә. Шуңа күрә, ясалма фәһем бик тиздән безнең тормышыбызның аерылгысыз бер өлешенә әйләнер дигән фаразларның чынга ашуына шик юк.

Тарихка карасак, ясалма фәһем хакында беренче мәгълүматлар инде 1956 елда ук дөньяга чыккан. Әмма әлегәчә ЯФ программачыларга, шушы системада эшләүчеләргә генә ачык система иде, ягъни ЯФ ябык формада булды дисәк тә була. 2023 елның башында GhatGPT исемле ясалма интеллект инкыйлаб ясады. Бу система башка ЯФдан аермалы буларак, мәгълүматларны гади кеше теленә эшкәртеп бирә башлады, шул рәвешле GhatGPT системасы хәзер бик күп технологияләргә, кулланучыларга юл ача.

Белгечләр ясалма фәһемнең тиз арада мәгариф системасында кулланыла башлавын фаразлый. Ул имтиханнар уздыру һәм тикшерү, аерым өлкәләрдә уку материалларын автомат рәвештә сайлап алу, студентларның белем дәрәҗәсен күтәрерлек өстәмә материал тупларга, студентларның һәм укучыларның мөмкинлекләрен, сәләтләрен билгеләргә булышачак, укыту системасын анализларга, чит телләр өйрәнергә, ярдәм итәчәк, диләр. Шулай ук ясалма фәһем студентларга белем дәрәҗәсенә һәм сәләтләренә туры килерлек өстәмә курслар сайларга, дистанцион яки мөстәкыйль уку чорында биремнәрне үтәүнең мөстәкыйльлеген контрольдә тотарга ярдәмче булачак.

Заманча белем бирүнең тагын бер проблемасын нейрон челтәрләре ярдәмендә хәл итәргә мөмкин – ул һөнәри юнәлеш бирү, һөнәр сайларга булышу. ЯФ кешенең сәләтләрен анализлап, аның мәнфәгатьләре хакында тулы картина ясап бирәчәк.

Әлегә нейрочелтәрләр иң актив кулланылган өлкә ул – журналистика.

Хәзерге вакытта журналистикада нейрочелтәрләрне куллануның төп өлкәсе булып контент генерациясе тора. Күзәтүләрдән күренгәнчә, аерым өйрәтелгән нейрочелтәрләр текстны гына түгел, ә визуаль һәм видео иҗади эшләрне дә яхшы башкаралар, аларның тематикасын билгелиләр һәм берничә

минут эчендә оригиналь нәтиҗәләр тәкъдим итәләр. Бу технологияләр журналистларга контентның эчтәлегенә игътибар итәргә мөмкинлек бирә, ә аны төрле форматларга һәм аудиторияләргә яраклаштыруның монотон процессына түгел, идеяләрне эзләү һәм аларны тормышка ашыру өчен вакытны экономияли, шулай ук мәйданчыкларны модерацияләү белән техник проблемаларны киметә.

Нейрочелтәрләрнең журналистикада өлкәсендәге кулланыла торган берничә юнәлеше:

1.*Мәгълүмат җыю*: ЯФ мәгълүмат җыю процессын җиңеләйтә, журналистларга кирәкле мәгълүматны тизрәк табарга һәм аны тирәнрәк анализларга мөмкинлек бирә.

*2.Мәгълүматны анализлау:* ЯФ мәгълүматны анализлау процессын автоматлаштырырга ярдәм итә, бу мәгълүмат күләме даими артып торганда аеруча мөһим. Журналистлар мәгълүмат кырындагы тенденцияләрне, закончалыкларны һәм үзара бәйләнешләрне ачыклау өчен ЯФ алгоритмнарын куллана ала.

*3. Эчтәлек булдыру*: ЯФ нигезендә заманча платформалар һәм кораллар журналистларга язмаларын сыйфатлырак, кызыклырак итәргә, яңа идеяләр һәм мәгълүматны структуралаштыру мөмкинлеген бирә. ЯФ аерым аудиториянең ихтыяҗларына һәм мәнфәгатьләренә яраклаштырылган контент булдырырга да ярдәм итә ала.

*4. Эш нәтиҗәлелеген яхшырту*: журналистлар ясалма фәһемне эш процессын оптимальләштерү өчен куллана ала. Мәсәлән, текстлар язу, графиклар һәм таблицалар төзү, мәгълүматны классификацияләү һәм маркировкалау кебек гадәти бурычларны автоматлаштыра.

Алда күрсәтелгән иҗади эш бурычларына алынырлык нейрочелтәрләр инде әзер. Алар: ChatGPT һәм YaGPT (текст белән эшли), Midjorney (рәсем генерацияли), Whisper (тавыш белән укыганны текст рәвешенә китерә), Perplexity AI (мәгълүмат эзли), 300.ya.ru (тезислар аерып ала).

Шулай итеп, нейрочелтәрләр медиа киңлеккә күбрәк яраклаша, кыска вакыт эчендә зур максатларга ирешергә ярдәм итә. Шул нисбәттән, ясалма фәһем татар журналистика дәресләрендә дә кулланылуы һәм кертелүе мөһим мәсьәләләрнең берсе булып көн кадагында тора. Бу актуаль сорау, чөнки бүгенге көндә белгечләр ясалма фәһемне татар теленә күчерү һәм куллану буенча зур эшчәнлек алып бара. Күптән түгел генә семиотика институты базасында татарча аудионы язма текстка әйләндерүче программа тәкъдим ителде, хәзер аны камилләштерү эшләре бара. Шулай ук татар телен иң яхшы аңлаган ЯФ, татарча контент, “татар” стилендәге рәсемнәрне ясаучы нейрочелтәрләр өйрәнелә.

Гомумән итеп әйткәндә, ЯФ бик күп телдәге мәгълүматларга таяна. Әмма интернетта татар теленең өлеше бик аз, иң күбе – инглиз теле. Татар телле чыганаклар, гадәттә үзебезнең сайтларда гына куела, дөньякүләм челтәрләргә аз чыга. Татар телендәге ЯФ булдыру өчен аерым татар телле текстлар базасын

туплау мөһим.  Әлбәттә, бу эштә иң зур ярдәмчеләр татар телендә иҗат итүче каләм ияләре, журналистлар булыр дип көтелә.

**Әдәбият**

1. Булаева, М.Н. Методические рекомендации применения цифровых платформ в профессиональных образовательных организациях обучения / М.Н. Булаева, О.Н. Филатова, П.В. Канатьев // Проблемы современного педагогического образования. – 2022. – №72(4). – С. 34-36 2.

2. Гущин, А.В. Особенности реализации информационной стратегии высшей образовательной организации / А.В. Гущин, О.И. Ваганова, О.Н. Филатова // Известия Балтийской государственной академии рыбопромыслового флота. – 2021. – № 3 (57). – С. 47-51

3. Лебедева, Т.Н. Формирование цифровой культуры педагога средствами массовых открытых онлайн-курсов / Т.Н. Лебедева, О.Р. Шефер, С.В. Крайнева, Н.А. Белоусова, Е.Н. Эрентраут, Ю.А. Ахкамова // Вестник Мининского университета. – 2022. – Т. 10. – №3.

# ТУГАН ТЕЛНЕ ӨЙРӘТҮДӘ ЭЛЕКТРОН СҮЗЛЕКЛӘРНЕҢ РОЛЕ

***Нәгыймуллина Л.Р.***
***Казан шәһәренең Ш.Мәрҗани исемендәге №2 татар гимназиясе***
***leilawww@mail.ru***

***Аннотация.*** Укыту процессында электрон сүзлекләрдән файдаланып эшләү киң таралыш ала бара. Мәкаләдә электрон сүзлекләр фонды һәм электрон сүзлекләрне туган тел дәресләрендә файдалану мәсьләсе карала.

***Ключевые слова:*** тел һәм әдәбият дәресләре, электрон сүзлекләр, сүзлекләрнең электрон фонды.

Күренекле мәгърифәтче Ризаэддин Фәхреддин: «...Заман һәм мәдәният алга үскәнчә, һәм икенче төрле итеп әйткәндә, ихтыяҗ һәм мәҗбүрилек кебек нәрсәләр мәҗбүр иткәнчә, укыту рәвешләре төрлеләнер, монда исә акыл ияләре берләшәләрдер», – дип язган. Бүгенге көндә белем бирү системасына даими рәвештә яңалыклар үтеп керә: мәгариф системасы көннән-көн камилләшә, замана укучысы өчен кызыклырак була бара, традицион укыту методларын, алым һәм чараларын заманчалары алыштыра. Бу юнәлештә татар телен укыту да искәрмә булып тормый, татар теленә өйрәткәндә дә заманча һәм цифрлы технологияләр кулланыла.

Туган тел һәм әдәбиятны нәтиҗәле өйрәтү максаты белән без, укытучылар, уку-укыту барышында төрле заманча метод-алымнардан, технологияләрдән файдаланып эшләргә тырышабыз. Элек-электән тел-әдәбият дәресләрендә аерым бер урынны сүзлек эше алып тора. Укыту процессында төрле сүзлекләргә мөрәҗәгать итеп эшләү ярдәмгә килә. Билгеле, һәр кабинетта дәрестә эшләү өчен сүзлекләр фонды булдырылырга тиеш. Алар махсус эшләү өчен, укучыларга дәрестә таратыла. Өй эшен хәзерләгәндә дә, укучылар сүзлекләр кулланып эшлиләр. Бүген әлеге традицион эш алымы белән беррәттән электрон сүзлекләрдән файдаланып эшләү дә киң таралыш ала бара. Бу, бер яктан, уку-укыту процессын цифрлаштыру юнәлешендә актуаль санала – күп төрле электрон сүзлекләрнең барлыкка килүе бу эшкә уңай яктан тәэсир итә.

Электрон сүзлекләрнең кулланучы өчен нинди уңай яклары бар соң? Беренчедән, электрон формат лексик берәмлекне эзләү процессының тизләтә. Эзләү системасында кирәкле сүз хата белән язылса, электрон версия аның дөрес вариантларын тәкъдим итә. Шунысын да әйтергә кирәк: электрон сүзлектә сүзгә бәйле белешмәләр төрле юнәлештә тәкъдим ителә: аңлатмасы, кулланылышы, төрле лексик-грамматик үзенчәлекләре дә бирелә.

Икенчедән, электрон сүзлекләр сүзгә аңлатма бирүдә зуррак мөмкинлекләргә ия. Бу сүзлеккә кертелгән сүзләрнең күләме, аларның мәгънәләренең бирелеше һәм функцияләре белән генә бәйле түгел, ә грамматик характеристикаларының, сүз төзелешенең, орфоэпик үзенчәлекләренең, килеп чыгышының, фразеологик берәмлекләр составында кулланылышына да бәйле.

Сүзгә бәйле төрле үзенчәлекләрнең бирелеше сүзлекне универсаль итә, сүзнең “яшәешен” анализлау мөмкинлеген бирә, аны сөйләмдә куллану үзенчәлекләрен билгели.

2018 нче елда татар телендәге төрле сүзлекләрнең электрон фонды булдырылу куанычлы хәл. Мәсәдән, “Татар теле: зур электрон тупланма” “TATZET” платформасының бер проекты буларак тәкъдим ителә. Мәгълүм булганча, ул Татарстан Фәннәр академиясе тарафыннан эшләнә. Тупланманы булдыруның төп максаты – бер чыганак белән генә чикләнеп калмыйча, төрле чыганакларны туплау, татар теле сүзлекләренең күпфункцияле электрон тупланмасын булдыру. Бу, үз чиратында, кулланучыга татар теле турында күбрәк мәгълүмат алу мөмкинлеген бирә. Фондта тәрҗемәи сүзлекләр, ике телле һәм күп телле сүзлекләр урнаштырылган. Әлеге фондта сүзнең дөрес язылышы, басымы, тәрҗемәсе, грамматик үзенчәлекләре, диалекталь сүзләрнең мәгънәсе, синонимнарны һәм башкаларны табарга мөмкин [Сүзлекләрнең электрон фонды].

Бу платформа укучылар өчен дә бик уңайлы: барлык электрон сүзлекләр бер урынга тупланып тәкъдим ителә һәм бу кирәкле мәгълүматны эзләүдә уңайлыклар тудыра. Бу лексикографик байлык белән укытучы укучыларны, һичшиксез, таныштырырга тиеш. Мисал өчен, эзләү системасына “китап” сүзен язабыз, анда дистәдән артык сүзлектә бу лексик берәмлек турында бирелгән сүзлек мәкаләләре тәкъдим ителә.

Шулай итеп, сүзлекләрнең электрон фонды мәгълүматны эзләү мөмкинлекләрен киңәйтә, кулланучыга төрле мөмкинлекләр ача:

1) эзләү өчен чыганаклар даирәсен билгеләү (сүзлекләрнең барысы да, сүзлекләрнең бер өлеше яисә аерым бер сүзлек);

2) сүз өлешләре буенча, шулай ук аларның сүздәге урынын күздә тотып эзләү (мәсәлән, билгеле бер кушымчалы сүзләр);

3) фондта тасвирланган сүзләрнең үзенчәлекләрен исәпкә алып эзләү мөмкинлеге (мәсәлән, сүз төркеме, омонимнар, функциональ-стилистик билгеләр, этимология һ. б.)

Башлангыч сыйныфларда да сүзлекләрнең электрон фондын кулланырга мөмкин. Фонетиканы өйрәтүдә сүзлекләрнең электрон фондыннан файдалану мөмкинлеген карап китик. Мәсәлән, ирен гармониясен өйрәнгәндә, түбәндәге бирем тәкъдим ителә: “*Нокталар урынына кирәкле хәрефләрне куеп, сүзләрне языгыз*: *оз...н, йолд...з, он...тмагыз, тозл..., ол..., кор..., торм...ш*”. Әлеге биремнең дөреслеген тикшереп, хаталарны барлаганнан соң, аның белән эшне шунда ук тәмамларга ярамый. Чөнки әлеге сүзләрнең дөрес укылышы мөһим. Моның өчен электрон орфоэпик сүзлек кулланырга була. Орфоэпик сүзлектә сүзләрнең укылышы, ягъни транскрипциясе тәкъдим ителә. Моңа бәйле рәвештә, биремне бераз катлауландырырга да була: “*Сүзлектән файдаланып, сүзләрнең транскрипцияләрен языгыз*”. Болай эшләү уңышлы нәтиҗәләр бирә, укучы [о] авазына бәйле ирен гармониясе күренешен исендә калдыра. Орфографик, лексик, фразеологик берәмлекләрне өйрәнүгә бәйле тел күнегүләрен башкарганда да, электрон сүзлектән файдаланырга мөмкин.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, дәресләрдә электрон сүзлекләр куллану укытуның сыйфатын күтәрергә ярдәм итә, этәргеч бирә.

Шушыларны күздә тотып , без түбәндәге нәтиҗәләргә килдек:

1) электрон сүзлекләр белән эшләү укучыларның татар теленнән үзләштергән белем, осталык һәм күнекмәләренең күрсәткече булып тор;

2) укучылар актив рәвештә уйлый, фикерли, нәтиҗәдә - белем дәрәҗәсенең күрсәткече арта;

3) электрон сүзлекләр укучыларның белем дәрәҗәсен диагностикалауда уңышлы алым булып тора.

Шулай итеп, татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә электрон сүзлекләрне куллану укытучылар өчен зур ярдәмлек була ала.

**Әдәбият**

Сүзлекләрнең электрон фонды. Режим доступа: http://suzlek.antat.ru/. (Мөрәҗәгать итү вакыты 12.01.2024).

# ФОРМИРОВАНИЕ ИНОЯЗЫЧНЫХ КОММУНИКАТИВНЫХ КОМПЕТЕНЦИЙ У СТУДЕНТОВ И СТАРШЕКЛАССНИКОВ ПОСРЕДСТВОМ АУТЕНТИЧНЫХ ВИДЕО- И АУДИОМАТЕРИАЛОВ

***Нурмухаметов И. И., Мухаметзянова Л.Р.***
***Казанский федеральный университет***
***nurmukhametov.iskander@mail.ru***

***Аннотация.*** Проблема использования аудио- и видеоматериалов на занятиях иностранного языка на сегодняшний день приобретает особую ценность. Данная статья посвящена проблеме формирования иноязычной коммуникативной компетенции у старшеклассников и студентов вуза, имеющие элементарный и предпороговый уровни владения языка (Elementary и Pre-Intermediate). Аутентичный аудио- и видеоматериал содействует процессу освоения иностранных языков: способствует формированию у учеников иноязычной коммуникативной компетенции, расширяет их кругозор, вносит вклад к заинтересованности изучения языка.

***Ключевые слова: к***оммуникативная компетенция, подкаст, аутентичные видео- и аудиоматериалы, медиаресурсы, коммуникативный подход.

На сегодняшний день одной из самых значимых задач современной лингводидактики в обучении иностранному языку является развитие коммуникативной компетенции. Нарушение фонетических норм языка в рамках коммуникативного обучения приводит к частичному или полному нарушению информативности, что часто является барьером в самом общение. Диалектическое единство состоит из двух взаимосвязанных составляющих: «иноязычного общения» и «произносительной стороны речи». Следовательно, произносительный навык – одна из значимых проблем лингводидактики и во многом одну из важных задач составляет роль в подготовке обучающихся к полноценному взаимодействию непосредственно с носителями языка [6].

В основу формирования коммуникативной компетенции у студентов на занятиях иностранным языком положен деятельностный подход, так как он развивает самостоятельную творческую активность каждого учащегося. Обучение предполагает на первоначальном этапе совместную образовательную деятельность под руководством педагога, а затем самостоятельную, в которой большая часть внимания сфокусирована на практической стороне вопроса. Развитие коммуникативной компетенции – процесс продолжительный и довольно трудный. Исключительную сложность в преподавании иностранного языка представляет соотношение предметного курса и реального речевого опыта студентов, процесс приобретения знаний о языке и процесс овладения языком.

Коммуникативная компетенция есть объединительное понятие, состоящее как из навыков взаимодействовать с языковым материалом, так и из лингвострановедческих знаний, свидетельствующих об обученности общению, то есть непосредственно коммуникации с помощью разных видов речевой

деятельности. Коммуникативный подход предполагает атмосферу доверия и сотрудничества на уроке, когда все студенты вовлечены в образовательный процесс. Одним из составляющих содержания речевой деятельности являются условия, в которых она проходит. Для этого преподавателю следует строить учебные речевые ситуации, стимулирующие коммуникацию. Процесс формирования данной компетенции носит постоянный характер, он не заканчивается с окончанием школы или вуза, а сопровождает в течение всей его последующей профессиональной деятельности, которая отражает путь формирования коммуникативной компетентности как необходимого компонента карьерного роста выпускника школы или вуза.

Применение медиаресурсов на занятиях – незаменимый элемент образовательной парадигмы, являющийся нетривиальный средством организации обучения через динамичные занятия, фокусирующихся на осуществлении личностно-ориентированного подхода. Главная цель использования таких медиаресурсов как аудио- и видеоматериалы на занятиях состоит в создании иноязычной среды для студентов и школьников. Невзирая на то, что она создается неестественным путем, иноязычная среда предоставляет возможность учащимся слушать аутентичную речь, не посещая при этом страну изучаемого ими иностранного языка.

Основными преимуществами применения аудио- и видеоматериалов на занятиях иностранного языка являются следующие:

1. Присутствует живой разговорный язык.

2. Возможность услышать различные тембры.

3. Иностранная речь звучит в быстром темпе, следовательно, достигается одна из основных задач обучения устной речи – совершенствование навыков аудирования.

4. Как правило речь накладывается на естественные помехи – шум леса, дождь, телефонный звонок, стук в дверь, работает параллельно ТВ или радио, играет музыка– то есть достигается максимальное приближение учебного видео к реальной жизни.

Отдельные преимущества видеоматериалов состоят в следующем:

1. Просмотр видео оказывает эмоциональное реакцию на учеников, увеличивает объем долговременной памяти, способствует улучшению их внимания. Помимо описания сюжета видеофрагмента, учащиеся анализируют чувства и эмоции героев, делятся впечатлениями от просмотра. Следовательно, предоставленный преподавателем учебный материал раскрывается глубже, шире используется эмоционально-оценочная лексика.

2. Показано поведение в различных социальным средах в той или иной ситуации разновозрастных носителей языка.

3. Зачастую в дополнение к интонации мимика и язык тела помогают понять отношение говорящего к объекту обсуждения или же взаимоотношения героев сюжета.

4. Аккомпанирование, световые и шумовые эффекты способствуют пониманию режиссерского замысла видеосюжета. Создание фона звукового

фона видео способствует выработке так называемой «помехоустойчивости» восприятия, необходимого в реальном общении [1].

С другой стороны, нельзя не упомянуть образовательные подкасты, которые также могут быть имплементированы в образовательный процесс. Термин «подкаст» и соответствующее ему обозначение технологии «подкастинга» в отечественной дидактике и методике остаются мало изученными. «Подкаст» можно дефинировать как аудио- или видеофайл, который можно скачать и прослушать или просмотреть на любом удобном гаджете [2]. Для закрепления прослушанного материала в ряде случаев на серверах подкастов предлагаются разработанные речевые рецептивные упражнения и тесты, ориентированные на контроль понимания содержания текста. Кроме того, весьма ценным является наличие скриптов к подкастам.

В современных реалиях учителя предпочитают использовать подкастинг в процессе преподавания все более масштабнее, так как это интенсифицирует обучение с помощью новых технологий и дистанционной коммуникации.

В связи с этим Мусина А.А. и Шкилев Р.Е выделяют следующие преимущества подкастинга:

1. Доступность

Подкасты позволяют обучающимся получать доступ к информации в любое время. Можно загружать информацию на гаджет по своему выбору и слушать или смотреть в любое удобное время. Для молодого поколения загрузка подкастов требует только базовых технических знаний и навыков.

2. Архив уроков

Преподаватель способен делать записи своих уроков и загружать их в онлайн архивы. Соответственно, обучающимся имеют доступ к пройденным материалам для получения информации.

3. Обновления

Обучающиеся, подписавшиеся на определенный подкаст, будут уведомлены, если есть обновление. Лидирующим преимуществом подкастинга является то, что в таком случае ученик будет постоянно получать информацию. Таким образом, подкастинг позволяет просто передавать информацию всем своим пользователям [5].

4. Непрерывное изучение

Ученики могут просматривать подкаст, даже если они находятся вне учебной среды, поскольку каждый урок может быть загружен на любой удобный гаджет.

5. Творческое обучение

В отличие от традиционных педагогических стратегий, существуют различные виды подкастинга, такие как гостевые лекции, интервью, видеодемонстрации и так далее. Они также мотивирует учеников к созданию своих собственных подкастов, стимулированию их навыков аудирования, ориентируясь на предпочтения каждого обучающегося [2]. Имплементация подкастинга повышает результативность обучения английскому языку посредством самоинтенсификации работы, так как имеет четкий ход действий

учителя и учеников: предварительный план и задачу, развитие восприятия и интерпретации подкаста и управление работы с учетом уровня знаний английского языка обучающихся [4].

Мы считаем, что аутентичные аудио- и видеоматериалы могут быть имплементированы в образовательный процесс для развития навыков говорения и аудирования. Таким образом, можно по праву говорить об эффективности использования аутентичных аудио- и видеоматериалов целью развития иноязычной коммуникативной компетенции обучающихся.

## Литература


1. Ахметова М.Р. Использование аудио- и видеоматериалов на уроках иностранного языка в школе // Вестник Башкирского государственного педагогического университета им. М. Акмуллы, 2019. – URL: https://cyberleninka.ru/article/n/ispolzovanie-audio-i-videomaterialov-na-urokah-inostrannogo-yazyka-v-shkole [дата обращения 3.02.2024]

2. Глушатова О. С. Дидактический потенциал подкастов и методика их использования при обучении английскому языку. URL:https://drive.google.com/file/d/1qGfpmMKbbwdwe0fffVsjWwKhzfy9uC5l/view [дата обращения 3.02.2024]

3. Горбова Н.В., Селезнева И.П. Развитие иноязычной коммуникативной компетенции обучающихся с использованием технологии подкастинга // Проблемы современного педагогического образования, 2018. – URL: https://cyberleninka.ru/article/n/razvitie-inoyazychnoy-kommunikativnoy-kompetentsii-obuchayuschihsya-s-ispolzovaniem-tehnologii-podkastinga [дата обращения 3.02.2024]

4. Ковалёва Т. А. Дидактический потенциал подкастов и методика их использования в дистанционной форме обучения иностранному языку // Иностранные языки в дистанционном обучении: мат-лы III Международной науч.-практ. конф.: в 2-х т. / Пермский государственный технический университет. Пермь: Изд-во Перм. гос. техн. ун-та, 2009. Т. 2. С. 48-55

5. Мусина А.А., Шкилев Р.Е. Преимущества использования подкастов при обучении английскому языку учащихся старших классов // Педагогика. Вопросы теории и практики, 2019, № 4 (1). – URL: https://cyberleninka.ru/article/n/preimuschestva-ispolzovaniya-podkastov-pri-obuchenii-angliyskomu-yazyku-uchaschihsya-starshih-klassov [дата обращения 3.02.2024]

6.Мустафина, Ф.Ш., Методика обучения иностранным языкам и воспитания: учебное пособие, 2-е издание. – Уфа: Башкирский государственный педагогический университет им. М. Акмуллы, 2016. – 294 с.

# ОБУЧЕНИЕ ЧТЕНИЮ РАЗНОСТИЛЕВЫХ ТЕКСТОВ НА ИНОСТРАННОМ ЯЗЫКЕ

***Пименова Т.С., Абдрафикова А.Р.***
***Казанский федеральный университет***
***pimenova_ts@mail.ru***

***Аннотация.*** Актуальность темы исследования можно определить тем, что чтение по-прежнему остается самым востребованным видом речевой деятельности при изучении иностранного языка. Поэтому обучению чтению должно уделяться особое внимание в школьном образовании. Умение читать важно не только в образовательных целях; это умение носит практико-ориентированный характер: оно полезно и в повседневной жизни. Примерами этому могут служить умения прочитать инструкцию по использованию импортных товаров, субтитры к фильмам и телепередачам, новости в социальных сетях, вести переписку с зарубежными друзьями, читать книги и газеты на иностранном языке. Следует грамотно с дидактико-методической точки зрения подобрать эффективные методы обучения чтению текстов различных стилей. В данном исследовании выдвинута следующая гипотеза: чтобы процесс обучения чтению разностилевых текстов на иностранном (английском) языке был результативным, должны быть определены 1) методологические основы обучения чтению текстов разных стилей на английском языке и 2) подобраны и имплементированы в образовательный процесс эффективные стратегии обучения чтению текстов разных стилей на английском языке. Для эмпирического подтверждения гипотезы был проведен педагогический эксперимент, в котором приняли участие учащиеся среднего этапа обучения (7-8 классы). В исследовании использовались различные научные методы: контент-анализ методической и научной литературы; анализ опытно-экспериментальных исследований; педагогический эксперимент; методы статистической обработки данных. В статье описана и доказана эффективность методики обучения чтению разностилевых текстов (художественных, публицистических и научно-популярных), основанной на комбинации фонетического метода, лингвистического метода и метода «целых слов» (whole-word method). Апробированная методика обучения чтению разностилевых текстов на иностранном (английском) языке может быть рекомендована для преподавателей английского языка средней общеобразовательной школы.

***Ключевые слова:*** обучение иностранным языкам, стратегии обучения чтению, тексты разных функциональных стилей, чтение как вид речевой деятельности.

Важным компонентом теории и методики преподавания иностранного языка является целенаправленный процесс обучения получения и принятия информации, а также ее передачи, опосредованный языковой системой и обусловленный коммуникативной ситуацией [1: 224]. Процесс приема и

передача информации может осуществляться различными способами; одним из них является чтение текстов. Исторически чтение характеризуется как рецептивная речевая деятельность, направленная на восприятие и осмысление письменного текста [5: 215]. В словаре Л.С. Выготского находим следующую интерпретацию термина: «Чтение не сводится к связыванию письменных знаков с соответствующими звуками, это сложный когнитивный процесс, в котором непосредственное участие принимают высшие психические функции» [3]. В теории и методике преподавания иностранных языков чтение рассматривается как самостоятельный вид речевой деятельности, так и средство формирования навыков устной и письменной речи. При чтении текста изучающий иностранный язык а) изучает новые слова и словосочетания, б) запоминает структуры предложений и в) соотносит каждый графический символ (букву, слог или слово) с его звучанием [4]. В конечном счете, обучаясь чтению текстов на иностранном языке, изучающий язык улучшает свои знания иностранного языка в целом.

Умение читать на иностранном языке формируется гораздо быстрее, чем умение говорить, воспринимать на слух или писать на иностранном языке [2: 92]. Разделяя эту точку зрения, мы утверждаем, что навыки чтения текстов разных стилей на иностранном (английском) языке также можно развивать быстро и эффективно при условии внедрения адекватных методов обучения чтению таких текстов на занятиях по английскому языку. Хотя и непросто, научиться читать тексты различных стилей возможно. Это утверждение стало основой нашей гипотезы, для доказательства которой мы разработали и протестировали методику обучения чтению разностилевых текстов на основе комбинирования фонетического метода, лингвистического метода и метода «целых слов» с учетом уровня подготовки и индивидуальных особенностей учащихся. Первый метод – фонетический – основан на алфавитном принципе. Обучение построено на соотношении между буквами или группами букв и их произношением. Лингвистический метод обучения чтению основывается на наиболее часто употребляемых словах, которые произносятся идентично своему написанию. Главным принципом метода «целых слов» выступает визуализация или визуальное распознавание целых слов. Такой метод не обучает ни названию букв, ни звуко-буквенному соотношению. Учащихся обучают распознавать слова как целые единицы. Результаты, полученные в ходе эксперимента, подтвердили нашу гипотезу.

В исследовании приняли участие 60 учащихся. Эксперимент проводился с целью анализа и оценки эффективности использования вышеназванных методов обучения чтению разностилевых текстов на уроках английского языка. В течение учебного года учащиеся 7-го и 8-го классов проходили экспериментальное обучение. Эксперимент проходил в три этапа: констатирующий, формирующий и контрольный. На начальном (констатирующем) этапе исследования учащимся была предложена анкета для определения уровня их мотивации к чтению, уровня владения навыками чтения и выявления предпочтений в жанрах литературы (художественная,

публицистическая, научно-популярная литература). Данные показали, что все участники эксперимента предпочитают читать художественную литературу как на родном, так и английском языке. Публицистические тексты, с которыми учащиеся сталкиваются каждый день, читая новости в социальных сетях, слушая и читая радио и теле-новостные программы, заняли второе место. Участники эксперимента отметили важность и полезность чтения научной литературы, написанной доступным и обстоятельным языком. Однако такого рода тексты были идентифицированы ими как слишком сложные для чтения и понимания. На втором (формирующем) этапе эксперимента авторы создали методику обучения чтению разностилевых текстов на основе комбинации трех методов: фонетическом, лингвистическом и методе «целых слов». Контрольный этап состоял из двух подэтапов: на первом был протестирован разработанный комплекс упражнений к серии текстов всех трех стилей, на втором подэтапе участникам эксперимента каждые две недели предлагался новый текст разного стиля. Учащиеся должны были прочитать текст, демонстрируя сформированность навыков чтения.

Эксперимент выявил следующие результаты. Самым сложным для восприятия оказался текст в научно-популярном стиле. Минимальное количество слов, прочитанных участниками эксперимента, составило 90. Средняя скорость чтения научно-популярного текста на английском языке составила 111 слов в минуту. Максимальное количество ошибок составило 39. Участники эксперимента продемонстрировали лучшие навыки чтения художественных текстов. Минимальное количество слов в минуту составило 106. Средняя скорость чтения художественного текста составила 127 слов в минуту. Сравнительный анализ результатов оценки навыков учащихся в чтении разностилевых текстов на английском языке представлен в таблице 1 и таблице 2.

Таблица 1.
Результаты входного теста, оценивающего навыки чтения учащихся

| Критерии оценивания | Художественные тексты | Публицистические тексты | Научно-популярные тексты |
|---|---|---|---|
| Максимальное количество слов в 1 минуту | 147 | 169 | 127 |
| Средняя скорость чтения | 127 | 125 | 111 |
| Количество ошибок | 21 | 19 | 39 |

Таблица 2.
Результаты контрольного теста, оценивающего навыки чтения учащихся

| Стиль текста | Максимальное кол-во слов в 1 минуту | Средняя скорость чтения | Кол-во ошибок |
|---|---|---|---|
| Художественные тексты (фонетический метод) | 174 | 150 | 7 |
| Художественные тексты (лингвистический метод) | 150 | 134 | 13 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Художественные тексты (метод «целых слов») | 158 | 138 | 11 |
| Публицистические тексты (фонетический метод) | 176 | 142 | 8 |
| Публицистические тексты (лингвистический метод) | 150 | 134 | 10 |
| Публицистические тексты (метод «целых слов») | 179 | 136 | 10 |
| Научно-популярные тексты (фонетический метод) | 153 | 129 | 18 |
| Научно-популярные тексты (лингвистический метод) | 129 | 115 | 21 |
| Научно-популярные тексты (метод «целых слов») | 134 | 119 | 18 |

Сравнительный анализ показал положительную тенденцию в исследуемой области. Тексты художественного и публицистического стилей оказались самыми легкими для учащихся. Научно-популярные тексты, несмотря на увеличение скорости чтения и уменьшение количества допускаемых ошибок, имели самые низкие показатели. Следует сделать вывод, что чтение научно-популярных текстов на занятиях по английскому языку требует интенсивного обучения и особого внимания со стороны преподавателя для достижения намеченных результатов.

С целью доказать валидность выводов был использован G-критерий признаков для зависимых выборок. Количество участников эксперимента составило 60, соответственно G-критерий оказался равным 23. Результаты представлены в таблице 3:

Таблица 3.
Критерий знаков G

| Стиль текста | $G_{-empirical}$ | $G_{-critical}$ |
|---|---|---|
| Художественные тексты (фонетический метод) | 0 | 23 |
| Художественные тексты (лингвистический метод) | 1 | 23 |
| Художественные тексты (метод «целых слов») | 0 | 23 |
| Публицистические тексты (фонетический метод) | 0 | 23 |
| Публицистические тексты (лингвистический метод) | 0 | 23 |
| Публицистические тексты (метод «целых слов») | 0 | 23 |
| Научно-популярные тексты (фонетический метод) | 0 | 23 |
| Научно-популярные тексты (лингвистический метод) | 7 | 23 |
| Научно-популярные тексты (метод «целых слов») | 0 | 23 |

Таким образом, мы можем заключить, что G-эмпирический является < G-критическим, что доказывает надежность и валидность гипотезы нашего исследования.

Итак, в этом исследовании был поставлен и решен вопрос: Какие методы обучения чтению разностилевых текстов могут быть идентифицированы как эффективные и потому применены в процессе обучения иностранному (английскому) языку? Мы представили краткий обзор методов обучения

чтению, которые признаны в теории и методике преподавания иностранных языков отечественными и зарубежными экспертами, чтобы выбрать наиболее эффективные для нашего исследования. Мы продемонстрировали эффективность методики, основанной на сочетании трех методов обучения чтению текстов различных стилей на иностранном (английском) языке – фонетическом, лингвистическом и методе «целых слов». Мы также определили роль, которую выполняет чтение в обществе в целом и конкретно для каждого индивида. Чтобы подтвердить нашу гипотезу, что при определенных педагогических условиях способность читать тексты различных стилей на английском языке может развиваться быстро и эффективно, мы провели педагогический эксперимент, который позволил апробировать и доказать эффективность разработанной нами методики обучения чтению текстов различных стилей на английском языке. Данные, полученные в ходе эксперимента, выявили следующие результаты: количество допущенных ошибок сократилось более чем на 10%, а среднее количество слов, прочитанных за минуту, увеличилось от 147 (художественные тексты), 127 (научно-популярные тексты) слов в минуту до 161 (художественные тексты), 137 (научно-популярные тексты) слов в минуту. Среднее количество прочитанных за минуту слов при чтении публицистических текстов значительно не повысилось. Таким образом, мы приходим к выводу, что обучение чтению разностилевых текстов с применением вышеописанной методики можно считать эффективным.

## Литература

1. Гальскова Н.Д., Гез Н.И. Теория обучения иностранным языкам: Лингводидактика и методика: Учебник для студ. лингв. ун-тов и фак. ин. яз. высш. пед. учеб. заведений. – 2-е изд., стер. – М.: Академия, 2006. – 336 с.

2. Сакаева Л.Р., Баранова А.Р. Методика обучения иностранным языкам: Учебное пособие для студентов Института математики и механики им. Н.И. Лобачевского по направлению «Педагогическое образование (с двумя профилями подготовки)». – Казань: Изд-во КФУ, 2016. – 189 с.

3. Словарь Л.С. Выготского. – М.: Смысл, 2010. – 118 с.

4. Щукин А.Н. Обучение иностранным языкам: Теория и практика: Учебное пособие для преподавателей и студентов. – М.: Филоматис, 2006. – 408 с.

5. Solnyshkina, M.I., & Vishnyakova, O.D. (2017). English textbooks for Russian students: Problems and specific features. *Journal of Social Studies Education Research*, *8*(3), 215–226.

# ИЯРЧЕН ҖӨМЛӘЛӘРНЕҢ ТӨРЛӘРЕН КАБАТЛАУ, АЛАРНЫҢ БӘЙЛӘҮЧЕ ЧАРАЛАРЫН БАРЛАУ

***Сабирҗанова Р.Р., Гарафутдинова Р.М.***
***Казан шәһәре Совет районы 72 нче мәктәп***
***ruzila79@yandex.ru***

***Аннотация.*** В этой работе рассматривается синтаксис сложных предложений.

***Ключевые слова:*** воспитание, синтаксис, сложное предложение, связующие средства.

Бу эш күренекле галим Ризаэддин Фәхреддиннең хезмәтләре нигезендә укучыларга изгелек, гаделлек, әдәп – әхлак тәрбияләүне максат итеп куя.

Бүген без халыкка тәрбия җитмәгән заманда яшибез. Кыйммәтләрне күңел белән түгел, акча белән исәплибез. Бер – беребездән өстен булырга тырышабыз. Хәзер тәрбиялелек аеруча кыен чор кичерә. Чөнки бүгенге буын әти-әниләрнең күбесе ишле гаиләдә үсмәгән, әби-бабайлардан аерым тору сәбәпле, аларның кыйммәтле рухи мирасыннан мәхрүм калган. Еш кына балалар буш вакытларын компьютер каршында, урамда үткәрә, аларны телевизор, урам тәрбияли. Үгет-нәсихәт, боеру аша балалары белән уртак тел таба алмаучылар да җитәрлек. Тәрбиянең нигезе – гаилә. Һәрбер әти-әни баласын итәгатьле, эш сөючән, белемле, кешелекле, ихтирамлы итеп тәрбияләргә тели. Тәрбиянең төп асылы – мәктәп белән гаиләнең бердәмлеге. Алар бер юнәлештә эшләгәндә генә уңышка ирешергә мөмкин. Бала үзенең көндәлек тормышында гаиләдәге, мәктәптәге, үзе яшәгән мохиттәге традицияләрне истә тотып эш итә. Әлеге традицияләрнең нинди булуы укучының киләчәк тормышына, шәхес буларак формалашуына хәлиткеч йогынты ясый. Тәрбия процессы ата-анадан, мәктәптәге укытучы-тәрбиячеләрдән килешеп эшләүне, акыл һәм көч егәрлеген бер максатка туплауны сорый. Мәсәлән, һәрбер дәрестә, белем бирүдән тыш, тәрбияви максат та куелырга тиеш. Туган тел һәм әдәбият дәресләрендә бу проблемага зур игътибар бирәбез. Бу эшне ничек алып барырга мөмкин соң?

Татар төркемнәрендә генә түгел, рус төркемнәрендә дә дәресләрне Р. Фәхреддиннең киңәшләренә таянып алып барырга була. Җөмләләрнең башларын төзеп, мәгънәле итеп дәвам итү күнегүләре;ахырын язып, Р.Фәхреддин әсәрләрен кулланып, җөмләне язып бетерү алымнары бик уңышлы була. Дәресләрдә тәрбияви ситуацияләр чишү шулай ук үтемле.

Туган тел дәресләрен синтаксистан башка күз алдына да китереп булмый. Мәгънәле сүзләр белән җөмлә төзү, сүзтезмәләр уйлау алымнары да отышлы.

Тел дәресләрендә лексик-грамматик күнегүләр эшләүне дә мавыктыргыч итәргә мөмкин. Әйтик, бирелгән аңлатманы бер сүз белән алмаштырырга кирәк: Үз-үзен тотышында җәмгыятьтә кабул ителгән кагыйдәләрдән

чыкмый торган кеше – ... (тәртипле). Кызгану, мәрхәмәт күрсәтү – ... (шәфкатьлелек). Инсафлы, тыйнак, үзен тота белә торган – ... (әдәпле). Тиешле әдәп кагыйдәләренә өйрәтү – ... (тәрбияләү). Намуслы, гадел – ... (вөжданлы). Дөреслекне яклый торган, хак – (гадел).

Тәрбияви максатларга ирешүдә, әдәби әсәрләрдән өзекләр алып, проблемалы ситуацияләр бирү дә отышлы.

Татар халкында “Яхшылык ит тә суга сал, халык белмәсә, балык белер”, – дигән әйтем бар. Без балаларга бу гыйбарәне истә калдырырга, һәр көн игелекле гамәлләр кылырга, кешеләргә карата миһербанлы, шәфкатьле булырга өндәргә тиешбез.

# УКУ ГРАМОТАЛЫГЫН ҮСТЕРҮ АЛЫМНАРЫ

***Сабирова Р. А.***
***«Рост» Шәмәрдән лицее***
***rez-sabirova@yandex.ru***

***Аннотация.*** Статья посвящена формированию читательских умений обучающихся на уровне основного общего образования при работе с разными видами текстов, что позволяет обеспечить динамику в формировании читательской грамотности обучающихся. Описаны эффективные приемы и методы формирования читательской грамотности.

***Ключевые слова*:** : читательские умения, формирование читательских умений, читательская грамотность, функциональная грамотность, логическая цепочка, сплошные и несплошные тексты.

Укучыларның функциональ грамоталылыгын үстерү мәгариф системасында бүген актуаль проблема. Педагогик хезмәткәрләр, җитәкчеләр, белем бирү оешмалары алдында укучыларның белем сыйфатын күтәрү, укытучының һөнәри осталыгын үстерү, укучыларны халыкара тикшерүләргә әзерләү бурычы куелды.

Функциональ грамоталылыкның төп өлеше буларак математик, уку, табигый-фәнни, финанс грамоталылыгы, глобаль компетенцияләр һәм креатив фикерләү аерылып күрсәтелгән.

Шулар арасында уку грамоталылыгы-функциональ грамоталылыкның төп компоненты. Грамоталы уку — үзмаксатка ирешү, белем һәм мөмкинлекләрне үстерү, җәмгыять тормышында актив катнашу өчен , язма текстларны кабул итү, аңлау һәм аларның эчтәлеген куллану сәләте. “Менә шушы сәләтне нинди эффектив алымнар кулланып үстерергә, ничек укуга кызыксыну уятырга” дигән сорау бүгенге көндә һәр укытучы алдына куелган сорауларның иң мөһимедер.

Уку грамоталыгы ул - укыганны аңлый белү, куллану һәм анализлый алу сәләте. Нинди алымнар белән шушы сәләтне үстерергә? Иң отышлы алымнар дип мин үзем кулланган түбәндәге алымнарны саныйм:

1. “Предмет дөньясы” алымы.

Укуга кызыксыну уяту –уку грамоталыгын үстерүнең иң мөһим өлеше. Дәреснең мотивация өлешендә “Предмет дөньясы” дигән алымны куллану укучыда өйрәнеләчәк әсәргә кызыксыну уята. Мәсәлән, Р.Низамиевның “Төсле карандашлар” әсәрен өйрәнгәндә, дәресне төсле карандашлар турында әңгәмә белән башлау укучыда зур кызыксыну гына тудырып калмый, баланың логик фикерләү сәләтен дә, метапредмет нәтиҗәләренә дә ирешергә ярдәм итә. ( *Минем кулымда карандашлар. Алар нинди? Тасвирлап карыйк әле. Менә шушы предмет сезне нинди дәрескә алып керер, ягъни карандашны нинди фәннәр белән бәйли аласыз?Карандашларны әдәбият дәресендә нәрсә белән чагыштырыр идегез? )*

Дәресне өйрәнеләчәк әсәрдәге деталь - предметлар белән башлап җибәреп, әсәрне өйрәнү барышында әлеге деталь - предметларны тексттан табарга, аларның вазифасын ачыкларга да ярдәм итә.

2. “Чуалган чылбыр” алымы

“Чуалган логик чылбыр” алымы җөмләләрне, текстның өзекләрен, гомумән, әдәби әсәрнең эчтәлеген логик эзлеклелектә төзүне таләп итә торган алым булып тора. Укытучы әсәрнең эчтәлеген чагылдырган җөмләләрнең логик тәртибе бозылган рәт бирә. Укучылар хаталарны табып төзәтергә һәм җөмләләрне логик эзлеклелектә куярга тиеш булалар. Әсәрне укымаган укучы бу эшне башкара алмый, шуңа күрә бала өйдә әсәрне укып килми булдыра алмый.

Бу алым әдәби әсәрнең эчтәлеген истә калдырырга, логик фикер йөртергә һәм әсәрне укырга өйрәтә. Әлеге алымны үзләштергән материалны ныгыту өчен генә түгел, ә бәлки, яңа материалны үзләштерү максатыннан куллану тагын да отышлырак. Укытучы укучы белән берлектә яки укучылар мөстәкыйль рәвештә “Чуалган чылбыр” төзиләр. Бу очракта бала әсәрне,әлбәттә, җентекләп укый һәм эчтәлекне чагылдырырлык җөмләләр төзи бара. Мәсәлән*, «Сихерче кыз» риваяте* буенча “Чуалган чылбыр”ны мисалга китерик.

1. Казаннан унике чакрым ераклыктагы авылга егылып төшкән.
2. Бер кыз,шәһәргә начар урын сайлаган өчен, патшага ачу белдергән.
3. Кыз сихерле сүз әйтеп, еланнарны бер чокырга җыеп яндырган.
4. Кыз күрсәткән урында еланнар бик күп икән.
5. Унике башлы елан гына һавага күтәрелгән.
6. Иске Казан бик текә тауда урнашкан булган.
7. Гади киемнән йөргән патша зарны ишетеп, киңәш сораган

*Җавап: 6,2,7,4,3,5,1*

Бу алымны https://learningapps.org/ сервисында куллану тагын да отышлы https://learningapps.org/display?v=p716oqc0n22

3. “Хат башы яз каршы “ алымы. Әсәр герое исеменнән яки башка бер образ исеменнән хат тәкдим ителә. Хат фактик хаталар белән. Укучының максаты: хаталарны төзәтеп җавап хаты язу.

*Исәнме дустым, Миннегали! Сиңа Әхмәдулла хат яза.*

*Миннегали, минем шатлыгым бик зур бит әле. Әти миңа Төркиядән шундый матур читек алып кайтачак. Аның олтаны Болгар олтаны, үзе ямь-яшел үлән төсле түгел, ә безнең әбинең күзе төсле яшел.*

*Ул шундый кечкенә, минем нәни аякларыма чак кына. Ә менә абыйга дигән читекне тегеп өлгертмәгән күрше әби. Читеге булмагач, абый елады. Әби аны тынычландырды, “Үзем тегеп бирәм” диде. Иртәгә яңа читекләребезне киеп, мәчеткә гаеткә барырбыз. Миңа иртәгә гаеткә киеп барырга әти чапан тегә. Минем кәвешем дә бар әле.*

*Миннегали, мине көт, бергә барырбыз,яме.......*

“Хаталы хат” танып белү эшчәнлеген үстерә, җөмлә төзү күнекмәләрен камилләштерә, логик фикерләргә өйрәтә, игътибарлылыкны үстерә, хат язу

күнекмәләрен камилләштерә, иң мөһиме әсәрне укырга этәрә, әсәрне укымаса бу биремне үти алмый.

4. «Цитата» алымы

Бу алым - әдәби әсәрне укуга һәм тексттан кирәкле мәгълүматны эзләп табарга этәргеч бирә торган алымнарның тагын берсе. Әсәрдән цитата китерелә һәм укучы әлеге цитатаның кем тарафыннан әйтелүен яки кайсы образга караганлыгын, шулай ук әлеге сүзләрнең нинди әсәрдән булуын да ачыкларга тиеш. Бу алымны һәр дәрестә һәм дәреснең төрле этабында кулланырга мөмкин. Мәсәлән, *Г.Әпсәләмовның “Миңа унтугыз яшь иде”* әсәре буенча түбәндәге цитаталарның кайсы образга караганлыгын билгеләүне таләп иткән бирем: *“Бу –кем сүзләре?”* Көчлерәк укучыларга образны язарга тәкъдим ителсә, йомшаграк укучыга туры китерергә генә дә тәкъдим итеп була.

5. «Бер әсәргә- йөз сорау» алымы

“Бер әсәргә – 100 сорау”алымын әдәбият дәресләрендә файдалану укучыда әсәрне укуга кызыксыну уята.

Өйрәнеләчәк әсәр буенча билгеле бер күләмдә җентекле сораулар төзелә, бала әсәрне укый-укый сорауга җавап эзли. Сораулар никадәр күбрәк булса, нәтиҗә шулкадәр зуррак була. Укучыларда мөстәкыйль уку һәм җавап бирү күнекмәләре формалаша, камилләшә, сөйләм теле үсә, грамоталылыгы арта.

“Бер әсәргә – 100 сорау”төзү алымын укучылар тарафыннан башкарылса, тагын да отышлырак . Укучы бала әсәрне укый бара һәм “нечкә” (“тонкие вопросы”) төзи бара. 9-11нче сыйныфларда исә укытучы “юан” сораулар (“тостые вопросы”) төзетүне дә максат итеп куя ала.

Һәр темага эшләнгән сораулар укучыларның белемнәрен контрольдә тоту максатында да, үзләштерелгән белемнәрнең дәрәҗәсен ачыклау өчен дә, авыр темаларны җиңелрәк үзләштерү өчен дә файдаланырга мөмкин.

6. « Кроссворд чишү» һәм «Кроссворд төзү» алымы

Кроссворд — укучыларның танып белү эшчәнлеген активлаштыручы, укыганын аңларга ярдәм итүче мавыктыргыч дидактик уен. Кроссвордларны яңа материалны үзләштергәндә дә, белем һәм күнекмәләрне формалаштыру этабында да, өйрәнгән материалны йомгаклау вакытында да, контроль һәм мөстәкыйль эшләр үткәрү өчен дә кулланырга була.

Кроссвордлар укучыларның сүзлек запасын баету, әдәби әсәрне өйрәнү, уку грамоталыгын үстерү, китап укуга мотив формалаштыру кебек бурычларны үтәргә мөмкинлек бирә.

Мәсәлән, Фатих Кәрими иҗаты буенча:



Горизонталь буенча:

1. Ф.Кәриминең “Истанбул мәктүпләре” әсәренең жанры?
4. Фатих Кәрими Бөгелмә өязенең кайсы авылында туган?
6. 1917нче елда “Яңа .......” газетасын чыгара.
7. “Ауропа сәяхәтнамәсе” кайда басыла?
8. .Европа буйлап сәяхәт кайсы шәһәрдән башлана

Вертикальбуенча:
2. Фатих Кәримине Европа буйлап сәяхәткә кем алып китә?
3. Сәяхәттә Ф.Кәрими нинди вазифа башкара?
5. Фатих Кәриминең этисе кем булган?
7. “Укы,эзлә, тап” алымы

Текст тәкъдим ителә. Укучы текстны укып, текст эченә яшеренгән әсәр исемнәрен яки мәгълүматны табарга, авторын әйтергә һәм сөйләүче геройның да кайсы әсәрдән булуын ачыкларга тиеш.

Мәсәлән: *” Белсеннәр, белсеннәр. Безнең авыл кешеләре барысы да : әниләр һәм бәбиләр дә, күрше кызы да, ир-егетләр дә, Гөргери кияүләре дә, хәтта Канкай улы Бәхтияр да, Әлдермештән Әлмәндәр дә, Миләүшәнең туган көнендә «Без бит авыл малае»дип, моңлы бер җыр җырлап йөрүче дә белсеннәр”* (ТУФАН МИҢНУЛЛИН) Мондый текстлар төзүне укучыларга да бирергә мөмкин..

Әлеге алымнар укучыларда әдәби әсәрләрне укуга кызыксыну уятып кына калмыйча, әдәби әсәрләрне, әдәбият теориясен һәм тарихи-әдәби чорны тирәнрәк үзләштерергә ярдәм итәчәк.

**Әдәбият**

1.Вопросы формирования и оценивания функциональной грамотности средствами учебых предметов. : учеб.-метод. пособие / Е. С. Баранова [и др.]; под ред. И. Е. Барыкиной, Е. В. Иваньшиной. – Санкт Петербург: ГАОУ ДПО «ЛОИРО», 2021. – 230 с.
2.Гостева, Ю.Н. Теория и практика оценивания читательской грамотности как компонента функциональной грамотности/ Ю. Н. Гостева, М. И. Кузнецова, Л. А. Рябинина, Г. А. Сидорова, Т.Ю. Чабан // Отечественная и зарубежная педагогика. - 2019. - № 4. – С.34–57.
3.Җамалетдинова З.И. Татар теле һәм әдәби уку дәресләрендә башлангыч сыйныф укучыларының функциональ грамоталыгын формалаштыру үзенчәлекләре: методик тәкъдимнәр. — Казан: ТРМҮИ, 2021. – 48 б.

# РЕКОМЕНДАЦИИ ПО ПРЕОДОЛЕНИЮ ИНТЕРФЕРЕНЦИИ ПРИ ОБУЧЕНИИ НЕМЕЦКОМУ ЯЗЫКУ КАК ВТОРОМУ ИНОСТРАННОМУ В СОШ

***Сайпанова А.Э.***
***Казанский федеральный университет***
***aurorasaypanova@gmail.com***

***Аннотация.*** **В** статье автором рассматриваются понятия интерференции и трансференции при обучении немецкому языку как второму иностранному языку. Автором предложены варианты использования положительного переноса для преодоления трудностей при обучении.

***Ключевые слова:*** немецкий как второй иностранный, интерференция, трансференция

Современное общество находится в постоянном развитии. Эта динамичность развития выдвигает новые задачи образования, одним основополагающих из которых является способность воспринимать мир во всем его поликультурном разнообразии в условиях глобализации.

Именно поэтому владение одним или более иностранными языками является ключом к самореализации и раскрытия профессиональных возможностей человека.

Выбор немецкого язык как второго иностранного языка является одним из самых распространённых в России. В подавляющем числе школ немецкий изучается после освоения базы английского языка.

Английский и немецкий языки принадлежат индоевропейской языковой семье, ее западногерманской группе. Такое родство объясняет большие сходства между языками – полное семантическое совпадение некоторых слов, словосочетаний; наличие форм прошедших форм глагола и модальных глаголов и др.

Такие совпадения облегчают процесс обучения немецкому языку. По И.Л. Бим [1: 1] задействование трех языков (родного, первого и второго иностранных языков) обязательно влечёт за собой интерференцию и трансференцию.

Трансференция – это положительный перенос одних языковых явлений на изучаемые. Интерференция – это негативный перенос одного или нескольких языков на изучаемый.

Если явление трансференции только помогает в изучении нового языка, то интерференция усложняет этот процесс. Первичные последствия интерференции проявляются в фонетической системе языка. Для нивелирования данных ошибок рекомендуется регулярно слушать речь носителей, проводить аудирования и, конечно, учителю следует исправлять артикуляционные ошибки сразу после их совершения. В случае объяснения грамматических структур предлагается использовать сопоставительный метод. Например, при объяснении темы «Степени сравнения имени прилагательного»

можно обратиться к опыту учащихся в английском языке через заполнение сопоставительной таблицы. Ученики самостоятельно формируют грамматическое правило, а затем вместе с учителем проверяют его.

*Таблица 1.*

*Сопоставительная таблица грамматической темы степени сравнения*

| | |
|---|---|
| Englischer Komparativ<br>Das Adjektiv+ er<br>Sweet – sweeter | Deutscher Komparativ<br>…<br>… |
| Englischer Superlativ<br>Das Adjektiv + the + est<br>Sweet – the sweetest | Deutscher Superlativ<br>…<br>… |

В качестве домашнего задания учителю рекомендуется подготовить упражнения на цифровых платформах, так как такой метод как облегчает нагрузку на учителя, так и мотивируют учеников выполнять домашнее задание. Цифровые платформы имеют яркий интерфейс, у учеников есть время подумать над заданием, а также при желании учителя есть возможность несколько раз решать одно задание.

Наиболее сложной грамматической темой при обучении немецкому языку как второму иностранному является тема «Склонение существительных». Категория падежа английского языка включает в себя только общий и притяжательный падежи. Немецкая же категория падежа более обширна, что вызывает множество сложностей у учеников. В данном случае учителю рекомендуется обращаться не к английскому языку, а к русскому, в котором также есть разветвленная система падежей. Так, обучающиеся отметят, что в ранее уже встречались с этой темой и проведут некоторые аналогии. В качестве закрепления данной темы рекомендуется подстановка существительных в нужном падеже в текст, самостоятельное написание предложений в разных падежах по теме (например, тема «Моя комната», «Мой распорядок дня» и др).

В заключение, обучение немецкому языку как второму иностранному в СОШ имеет ряд трудностей при его некоторой схожести с английским. Для нивелирования большинства ошибок требуется пристальное внимание учителя, которому следует учитывать возможные явления интерференции при обучении как лексике, так и грамматике. Основной рекомендацией для предупреждения негативного переноса является использования наглядного сопоставления первого и второго языков.

## Литература

1.Бим И.Л. Иностранный язык в системе школьного филологического образования / И.Л. Бим, М.З. Биболетова, А.В. Щепилова, В.В. Копылова // Иностранные языки в школе. 2009. № 1. С. 4-7.

2.Миролюбов, А.А. Методика обучения иностранным языкам: традиции и современность/ Миролюбов ; под ред. А.А. Миролюбова. - Обнинск: Титул, 2010. - 464 с.

3. Шатилов, С. Ф. Методика обучения немецкому языку в средней школе учеб. пособие для студ. пед. ин-тов по спец. N2103 "Иностр. яз., 1986

# ИЯРТЕМНӘРНЕҢ ФОНЕТИКҺӘМ МОРФОЛОГИК ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

***Саматова И.Р.***
***МБОУ “Лицей имени В.В. Карпова”***
***ilzirashka88@mail.ru***

***Аннотация.*** Как известно, междометия отличаются от других групп слов тем, что не обладают номинативной функцией. Они выражают различные звуки, существующие в природе, не через понятия, а непосредственно через звучание собственных звуков, либо описывают явления света, движения подобно звукам условной речи

***Ключевые слова:*** междометие, морфология, фонетика, части речи, синтаксические функции.

Билгеле булганча, ияртемнәр башка сүз төркемнәреннән номинатив функциягә ия булмаулары белән аерылалар. Алар табигатьтә булган төрле тавышларны төшенчәләр аша түгел, ә турыдан-туры үз авазларының яңгырашы аша чагылдыралар, я булмаса яктылык, хәрәкәт күренешләрен шартлы сөйләм авазларына охшатып тасвирлыйлар. Мәсәлән: *Тау астындасалкын чишмә чылтыр-чылтыр агадыр яки чут-чут итеп тирәкләрдә сандугач сайрый* дигән юлларда чишмә чылтыравы һәм сандугач сайравы фонетик яктан шул тавышларга охшатып ясалган аваз ияртемнәре ярдәмендә турыдан-туры һәм иң кыска рәвештә тасвирланганнар.

Шуның кебек үк яктылык күренешләре, төрле җан ияләренең тышкы кыяфәте һәм хәрәкәте дә образлы итеп күзалланырга һәм, эчке бер ассоциация нигезендә “нинди дә булса үзенчәлекле тавышка охшатып”, ияртемнәр белән тасвирланырга мөмкин.. Мәсәлән: *Җем-җем итә чыклар таңда, бизәп мул кырны (М.Хөсәен)* яки *Фыр-фыр итеп торган чәчкәйләрең битләремә тиеп сөярләр (М.Укмаси).*

Шул рәвешчә, ияртемнәр тавыш, яктылыку күренешләрен атап белдермичә, сөйләм авазларының яңгырашы аша гына тасвирлап, аларны гаять конкрет рәвештә образлы итеп безнең күз алдына китереп бастыралар. Димәк, алар ишетеп һәм күреп сиземләнә торган күренешләрнең атамалары, лексик символлары түгел, ә образлы копияләре булып торалар. Ымлыклардан аермалы буларак, ияртемнәрнең үзләренә хас фонетик структуралары була, алар билгеле бер модельләр буенча төзеләләр. Гадәттә, ияртемнәр тартык +сузык+тартык яки тартык+сузык+сонор+тартык авазлардан торалар: *лык, дөп, чулт, шырт* һ.б.

Киресенчә, ымлыкларда аваз төзелеше ягыннан нинди дә булса фонетик типларны билгеләү бик кыен: *и, эх, чү, бәй, иһи, абау, һайт, ай-һай* һ.б. Кагыйдә буларак, ымлыклардан башка сүзләр я бөтенләй ясалмый, я бу – бик сирәк очракта гына мөмкин. Ә ияртемнәр исем һәм фигыль ләр ясау өчен нигез булып хезмәт итәләр; алардан морфологик һәм синтаксик ысуллар белән дә яңа

сүзләр ясала: *чаң – чаң* ( исем), *тар-тар* – тартар (кош исеме), *гөр-гөр* – гөрлә, *быз* – бызылда (фигыльләр) һ.б.

Синтаксик функцияләре буенча җөмләдәге башка сүз төркемнәре белән бәйләнешкә кереп, күбесенчә, рәвеш хәле булып киләләр, хәтта ия, хәбәр һәм аергыч функцияләрендә дә кулланылалар. ***Чут-чут*** *сайрый сандугачлар, җәйге таң сызылып бара* (Ә.Ерикәй). ***Кыйгак*** *казлар,* ***кыйгак*** *казлар бармыйсызмы безнең якларга?* (“Халык җыры”). Ымлыклар исә, бөтенләй җөмлә кисәге функциясен үти алмыйлар.

Тавышның эзлекле рәвештә кабатланып торуын белдерергә кирәк булганда, иялтемнәр да-дә//та-тә теркәгечләре ярдәмендә бәйләнеп киләләр. Мәсәлән: *Төштеләр ярдан суга барлык бакалар : “шып та шып!”* (Г.Тукай). Ымлыкларга мондый үзенчәлек хас түгел: җөмлә кисәге булып килә алмау аркасында, алар үзара теркәгечләр белән бәйләнеп килә алмыйлар.

Туган телнең үз фонологик системасы җирлегендә ясалу сәбәпле иялтемнәр һәрбер телдә специфик яңгырашлы булалар. Мәсәлән, этнең өрү тавышы татарча *вау-вау* яки *һау-һау*, русча *гав-гав* яки *ав-ав*, инглизчә *бау-бау*, французча *ва-ва*, итальянча *бу-бу* һәм кытайча *ванг-ванг* дигән аваз иялтемнәре белән белдереләләр (Сәгыйтов, 1972, 177).

Иялтемнәрнең аваз ягы “тумыштан” ук, ягъни үзенең табигате белән үк тирә-якта туган тавыш күренешләре белән бәйләнгән булганлыктан, аваз иялтемнәре арасында башка теллләрдән алынмалар очрамый; аларның лексик составы алынмалар исәбенә баемый. Шулай ук алар телнең үз эчендәге башка сүз төркемнәреннән дә ясала алмыйлар. Ымлыклар башка сүз төркемнәреннән дә ясала алалар һәм фразеологик берәмлекләр исәбенә дә байыйлар. Шулай ук алар арасында башка телләрдән кергән алынмаларны да очратырга мөмкин: ура (монголчадан кергән ороя), алло (французчадан allons) һ.б. Димәк, иялтемнәргә номинатив функция хас булмаса да, ул исем, сыйфат, сан, рәвеш кебек башка мөстәкыйль мәгънәле сүз төркемнәре рәтендә каралырга хаклы. Алар мөстәкыйль мәгънәле башка сүз төркемнәре кебек үк чынбарлыктагы күренешләрне белдерәләр. Алардан аермалы яклары шунда, алар аваз составлары ягыннан шул ук күренешләрнең реаль чагылышына якынлаштырылган булалар.

Билгеле булганча, татар теле тарихында иялтемнәрне ымлыклар рәтенә кертеп караганнар. Әйе ымлыклар белән аваз иялтемнәре арасында кайбер уртак яклар бар: тегеләре дә болары да номинатив функциягә ия түгелләр; ымлыклар хис-тойгыларны, ә аваз иялтемнәре тавыш һәм яктылык күренешләрен атап күрсәтмиләр, бәлки аларны “турыдан-туры һәм иң кыска рәвештә белдерәләр” (Тумашева, 1974, 280-281). Н.А.Баскаков та үзенең бер хезмәтендә түбәндәгечә яза: “Ымлыклар һәм аваз иялтемнәренең уртак билгесе шул: алар эмоцияләрне, тавыш һәм хәрәкәт образларын атап белдермиләр, ә аларның турыдан-туры тәгъбирләре булып торалар” (Баскаков, 1952, 235). Әмма бу охшашлыкларга нигезләнеп кенә аларны бер грамматик категориягә кертү үзен акламый. Югарыда санап үтелгән күп кенә аермалы яклар аларны икесен ике сүз төркеме итеп карауга дәлилле нигез булып торалар.

**Әдәбият**

1. Әдәби сүзлек (элекке чор әдәбияты һәм мәдәнияты буенча кыскача белешмәлек). – Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. – 399 б.
2. Баскаков Н.А. Каракалпакский язык. – М., 1952. - 264с.
3. Сафиуллина Ф.С.,Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле. - Казан: Мәгариф, 1998. - 315 б.
4.Сәгыйтов М.А. Аваз ияртемнәрен өйрәнүгә карата //Вопросы тюркологии. – Казань, 1972. С. 176-186.
5. Тумашева Д.Г. Хәзерге татар әдәби теле. Морфология. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1978. – 122 б.

# ИСТОРИЧЕСКИЕ РАЙОНЫ РАСПОЛОЖЕНИЯ КИПЧАКОВ И ОБЩАЯ ХАРАКТЕРИСТИКА ТЮРКСКИХ ЯЗЫКОВ КИПЧАКСКОЙ ГРУППЫ

***Самедова К. И.***
***Азербайджанский государственный педагогический университет***
***samedovakonul74@mail.ru***

***Аннотация.*** Самой густонаселенной группой в историческом и современном тюркском мире является группа кыпчаков. Как турецкая этническая общность, кипчаки имеют много общих элементов с точки зрения географии, культуры и социальных аспектов. Потому что многие из этих тюркских племен образовались из одного и того же племени. Опять же, роль географии, истории и языкового единства важна в оценке всех этих племен как кыпчакских племен. Некоторые из кыпчакских племен упоминаются в истории как самостоятельное племенное название или этноним. В статье представлены сведения о местах расселения кыпчакских племен, их месте в истории, их языковых и этнических особенностях.

***Ключевые слова:*** кипчакская группа тюркских языков, этническое единство, антропологический тип, набеги кипчаков.

*Данная работа выполнена при финансовой поддержке Азербайджанского Научного Фонда - Qrant № AEF-MCG-2022-1 942)-12/12/5-M-12*

Kıpçakların Azerbaycan'a ve çevre bölgelere akınları ve buralardaki yerleşimleri hakkında birçok bilgi Ermeni ve Gürcü kaynaklarında yansıtılmaktadır. Bunlar arasında Leonti Mrovei'ye atfedilen ve Kafkasya'daki Kıpçakların adının V yüzyıldaki olaylarla bağlantılı olarak anıldığı Gürcü kaynağı «Kartli Çarlarının Hayatı» dikkat çekicidir. Kıpçakların Gürcistan'a nakledildiği gerçeği Gürcü kaynaklarından «Çar Davud'un Hayatı» adlı esere de yansımıştır. Ermenice kaynaklardan Kirakos Ganzaketsi, Moğol işgali sırasında Kıpçakların Azerbaycan'a akışı hakkında bilgi veriyor. Bunun yanı sıra asıl Kıpçak Türk kavminin bünyesinden ayrılıp zamanla ayrı boy olarak meydana çıkmış Kıpçak Türk boyları da vardır. Büyük Kıpçak devleti olan Altın Ordu’nun kurulmasıyla (Kıpçaklar Altın Ordu halkının çoğunluğunu oluşturuyordu) Kıpçak adı tekrar tarih sahnesine çıkmaya başlamıştır. Altın Ordu içinde yaşayan halklar, zamanla eski adları olan «Kıpçak boyları», «Kıpçak kabileleri», «Kıpçak havzası», «Kıpçak halkları» adıyla anılmışlardır. Bu adlandırmalar şu anda çağdaş bilim dünyasında da kullanılmaktadır [4]

Kıpçak antropolojik tipi genellikle antropologlar tarafından Güney-Sibirya veya Turan tipi olarak kabul edilmektedir. Arkeolog ve antropologlar tarafından bu türün eski kalıntıları Doğu Kazakistan’dan Kafkas ve Küçük Asya’ya kadar yayılan

topraklarda bulunmuştur. Türkler, onları genellikle ön yargılı ve delilsiz bir şekilde Moğol ırkı olarak kabul etmektedirler ve onların ataları sadece Volga'nın doğusundaki topraklarda yaşamış diye genel sonuçlara varmaktadırlar.

Modern Türk dili alanında oldukça geniş bir coğrafyaya yayılmış olan Kıpçak lehçelerini coğrafî esasta üçe ayırabiliriz: İdil-Ural bölgesinde konuşulan lehçeler, Aral-Hazar gölleri arasında konuşulanlar ve Hazar-Karadeniz arasında (Kafkaslarda) konuşulan lehçeler. İdil-Ural grubu içinde Tatar Türkçesi, en büyük sayıda Tataristan'da, sonra Başkurdistan, Bulgaristan, Kazakistan, Romanya, Çin, Türkiye, Finlandiya, Ukrayna, Kırgızistan, Azerbaycan, ABD, Tacikistan ve bazı Avrupa ülkelerinde, oldukça geniş bir coğrafyada konuşulmaktadır.

Aral-Hazar gölleri arasında konuşulan Kıpçak Türk lehçelerinden Kazak Türkçesi, Kazakistan'da, Afganistan'da, Çin'de, Moğolistan'da, Türkmenistan'da, Özbekistan'da konuşulmaktadır. Kazakçaya çok yakın olan ve Kazakçanın bir diyalekti sayılması gereken Karakalpak Türkçesi, Sovyet devriminden sonra yazı dili olmuştur. Bugün çoğunlukla Özbekistan'a bağlı Karakalpak Muhtar cumhuriyetinde ve Kazakistan'da konuşulur. Kıpçak grubu içinde dil özellikleri bakımından Kazak ve Karakalpak Türkçeleriyle benzer özellikleri taşıyan Nogay Türkçesi, Aral-Hazar dışında, Kafkasya bölgesinde konuşulmaktadır. Bugün Nogayca Karaçay-Çerkes Cumhuriyetinde, özellikle Stavropol vilayetinde, Dağıstan cumhuriyetinin çeşitli bölgelerinde konuşulmaktadır. Ayrıca Romanya'da ve Türkiye'de de küçük bir Nogay topluluğu bulunmaktadır.

İdil-Ural coğrafyası içinde Tatarlarla komşu olan Başkurtlar vardır. Tatarcaya çok yakın olan Başkurt Türkçesi, büyük çoğunlukla Başkurdistan'da konuşulur. Tatarlar için saydığımız oblastların bir bölümünde de yine Başkurtça konuşulduğu bilinmektedir. Tatarca ve Başkurtça, Kıpçak grubu içinde gösterdikleri dil özellikleri bakımından müstakil bir grup oluştururlar. Tataristan ve Başkurdistan bugün Rusya Federasyonuna bağlı otonom cumhuriyetlerdir [3, 219].

Aral-Hazar coğrafyasında konuşulan bir başka Kıpçak Türk lehçesi de Kırgızcadır. Kırgızistan'da, Özbekistan'da, Tacikistan'da, Çin'de konuşulmaktadır. Kırgızlar adları Orhun yazıtlarında sık geçen eski Türk boylarından biridir. Kırgızca dil özellikleri bakımından Kıpçak grubu içinde müstakil bir yerdedir. Kırgızcanın Kuzey-Doğu grubundan Altayca ile yakın benzerlikleri vardır. Kırgızcanın en önemli özelliği, kuvvetli dudak çekimine bağlı (labial attraction) yuvarlaklaşmadır. Aynı özelliği Altaycada da görmek mümkündür.

Karadeniz-Hazar alanında (Kafkasya) konuşulan Kumuk Türkçesi, Dağıstan Muhtar cumhuriyeti sınırları içinde (başkent Mahaçkale) konuşulur. Azerbaycan türklerinden sonra Kafkasya'da yaşayan en kalabalık Türk topluluğu Kumuklardır. Bir Kıpçak lehçesi olan Kumukçada Oğuzcanın tesirleri vardır. Yine Kafkasya'da konuşulan bir başka Türk lehçesi de Karaçay ve Balkar Türkçesidir. Karaçay

Türkçesi, Karaçay-Çerkes Cumhuriyetinde, Kuban nehri yakınlarında, Balkar-Kabartay cumhuriyetinde konuşulur. Bu iki boy kaynaklarda ayrı zikredilmekle birlikte dil, tarih ve kültür bakımından bir bütünlük gösterir ve birlikte değerlendirilmesi gerekir. Rusya dışında Türkiye'ye göç eden Karaçaylılar da vardır. Karaçayca-Balkarca Sovyet devriminden sonra yazı dili olmuştur.

Tarihe bakıldığında Kıpçakların Azerbaycan'a ilk akını kuzeyden gerçekleşmiştir. Elbette Orta Asya Kıpçaklarının Azerbaycan topraklarına Hazar Denizi'nin güneyinden girdiğini varsayabiliriz. Ancak bu kaynakla ilgili herhangi bir bilgi henüz açıklanmadı. Kuşkusuz bu akışlar kuzey yönündeki ana geçişler olan Daryal ve Darband geçişleri üzerinden gerçekleştirilmiştir. Azerbaycan'a eski Türk akınları da Büyük Kafkasya'nın diğer dağ geçitlerinden gerçekleşmekteydi. Bu nedenle Gah bölgesinin kuzeyindeki geçitlerden birine yerel halk tarafından hâlâ «Hun beli» denilmektedir.

Kıpçak grubunun en batısında konuşulan lehçelerinden biri de Karayimcedir (Karay, im çoğuldur). Bunlar Musevî Türklerdir. Köken bakımından yine Musevi olan Hazar Türklerine bağlanırlar. Litvanya'da, Batı Ukraynada, Kırım'da, Polonya'da konuşulur. Bugün Karayim Türkçesi dil ölümü, dil kaybı tehlikesi ile karşı karşıya kalan Türk lehçelerinden biridir. Konuşur sayıları gittikçe azalan ve yok olmaya doğru giden Türk lehçelerinden biridir. Karaylar dillerini 1930'lu yıllara kadar İbrani, Latin ve Kiril alfabeleri ile yazmışlar. Karayimlere ait eski pekçok dini elyazması metin, doğal olarak İbranî yazısıyla yazılmıştır.

Kıpçaklarda «Ana Kıpçakça» kavramı vardır. «Ana Kıpçakça», tarihî-dilbilimsel bir kavramdır ve Türk dillerinin birkaç kolunun gelişiminde rol oynayan başlangıç dönemini oluşturur. O, ana Türk dilleri esasında ortaya çıkan ve yeniden kurgulanan bir dildir. XIX yy. sonunda eski Sümer dilinin Türk dilleriyle ilişkisi gösterilmiştir: «Sümer dili» (şimdi «Şumer» olarak adlandırılmaktadır), Asya dillerinin içindeki en eski dildir.

Oğuz dilinin Kıpçak lehçeleri üzerinde önemli bir etkisi olmuştur. X-XII yüzyıllar ve sonrasında Kıpçak dili, Karalug ve Oğuz dilleri arasında orta bir konumda yer alıyordu. Oğuz diline daha yakındı. M. Kaşgari, Oğuz dilinin etkisini her yerde hissetmiş ve Oğuz-Kıpçak dillerinin karıştığından emin olmuştur. Bu, M. Kaşgari'nin sıklıkla «Oğuz» ile birlikte «Kıpçak»tan veya tam tersi olarak «Oğuz»dan Kıpçak ile birlikte bahsetmesiyle açıklanmaktadır. Bazen «oğuz»u gösterir ve ardından gelen «kıpçak» kelimesinin kendini açıklayıcı olduğunu varsayar. «*Bu tür ortak özelliklerden dolayı Türkolojide Oğuz-Kıpçak dili veya tam tersi «Kıpçak-Oğuz» dilleri kullanılmaktadır. Günümüzde kıpçakça ve oğuzcaların izlerinin bir çox türk dillerinde hala var olduğunu görüyoruz. Bilimsel araşdırmalar sonucunda şunu eminlikle söyleye biliriz ki, Kıpçak Türkçesi Azerbaycan edebi dilinin yanı sıra lehçelerinin tüm gruplarını etkilemiştir»* [1,85].

«*Tarihe baktığımızda Oğuz ve Kıpçaklar arasında münakaşaların olduğu bazı kaynaklarda belirtiliyor. Araştırmalar, Azerbaycan'ın edebi dilinin oluşumunda Oğuzca'nın, milli Azerbaycan dilinin oluşumunda ise ilk Kıpçak unsurlarının az önem taşımadığını göstermektedir. Kuşkusuz bu durum «Dede-Korkut» destanında da Kıpçak unsurlarının yansıtılmasından kaynaklanmaktadır*» [5, 51].

«Dede Korkut» destanından gelen 19 kök kelimenin d sessiz harfiyle kullanılması (bu özellik kıpçak türkçesine has özelliktir), Oğuzlardan önce Kıpçakların varlığına veya Oğuzlarla birlikte Kıpçakların varlığına işaret etmektedir. Hatta yapılan araştırmalara dayanarak Kıpçakların bu bölgelerde Oğuzlardan daha önce oluşmaya başladıkları, daha sonra Oğuzlarla karıştıkları sonucuna varıyoruz. Ancak daha sonra Roma Kilisesi, Avrupa'daki Türklere ait her şeyi sistematik olarak yok etmeye karar verdiğinde, bu planın bir kısmı da Kıpçak'ın Oğuzlarla çatışmasına yönelik planların uygulanmasıydı. Dolayısıyla «Dede Korkut» destanında «Kıpçak Melik» ifadesi doğru şekilde gösterilmemiştir [2 129].

Antik dönemin sonlarında, Orta Çağ'ın başlarında, Kıpçakların sadece yazı sahibi olmadığı, aynı zamanda birçok kavmin alfabesinin de Kıpçak Türkleri tarafından yaratıldığı yönünde görüşler vardır. Kıpçak alfabesi, Türklerin eski çağlardan beri kullandığı Roma alfabesidir. Daha sonra Hıristiyan kalabilmek için İslam'ı kabul etmeyen Kıpçakları Ermenileştiren Ermeniler, alfabelerini de özelleştirdiler. Burada Ermenileştirilmiş Kıpçak nüansını gözden kaçırmamak gerekir. Zamanla Hıristiyan-Kıpçak kültürünün incelenememesi Ermeni milliyetçileri için koşullar yarattı. «Dede Korkut» destanında Türklerin Kıpçak Melik, Söklü Melik ve diğer Oğuz kuvvetleriyle savaştığına Türkler dikkat çekmemiş ve ilgi göstermemiş miydi? Ermeniler bizden farklı olarak bu konuyu ustalıkla kullanarak eski Hıristiyan-Kıpçaklara ait olan her şeye el koymaya başladılar. Özellikle tarihin belli bir aşamasından itibaren Arnavut aşiret topluluğuna ve devletine ait her şeye el koydular. Gregoryenlik ile bağlantılı olarak Arnavut ve daha sonra Ermeni alfabesiyle Kıpçak Türkçesiyle yazılmış orijinal eserleri yok ederek tercümelerini yaymaya başladılar.

Çok çeşitli lehçe ve şivelere ayrılan, yeryüzünde yaklaşık 200 milyondan fazla bir nüfusa sahip Türk boyları tarafından konuşulmakta olan Türkçenin ses bilgisel ve biçimbilimsel özelliklere göre tam bir sınıflandırmasının yapılabilmesi için karşılaştırmalı dil araştırmalarının derinleştirilmesi, her lehçe ve şivenin özelliklerinin tam olarak ortaya konulması gerekmektedir.

## Edebiyat

1.Demirçizade E. Azerbaycan dilindeki oğuz-kıpçak lisani ünsürleri. - Bakı: Azerb. SSR. EA. Dilçilik eserleri, 1947.- c.1.

2.Demirçizade E.M. “Kitabi-Dede Korkut” dastanlarının dili. - Bakı: İ.Lenin adına APİ-nin neşriyyatı.,1959. – 157 s

3. Xudiyev N. Kadim türk yazılı abidelerinin dili. - Bakı: Elm-tahsil, 2015. - 596 s.
4. Karamanoğlu Ali Zehni. Kıpçak türkçesi qrameri. - Ankara: TDK.Yay. XVII, s.994.
5. Mustafa, Öner. Bugünki kıpçak türkçesi. - Ankara: Türk dil yayınları, 2-ci baskı. – 2013.- 269 s.
6. Üstüner Ahat. Türkçenin tarihi gelişmesi. - İstanbul: Çaşıoğlu Basım, 2015.- s. 256.

# ИСПОЛЬЗОВАНИЕ ДЕЛОВОЙ ИГРЫ В ПРОЦЕССЕ ФОРМИРОВАНИЯ ПРОФЕССИОНАЛЬНЫХ КОМПЕТЕНЦИЙ СТУДЕНТОВ ГУМАНИТАРНЫХ НАПРАВЛЕНИЙ ТЕХНИЧЕСКОГО ВУЗА

***Самитова С.Г.***
***Казанский национальный исследовательский технологический университет***
***savilas@yandex.ru***

***Аннотация.*** В данной статье рассматриваются вопросы применения деловой игры в процессе формирования компетенций у студентов гуманитарных направлений технического вуза. Автором анализируются современные требования выпускникам вузов в сфере гуманитарных направлений, обосновывается необходимость использования инновационных методов обучения и доказывается положительное влияние деловой игры на формирование таких компетенций, как коммуникация, лидерство, аналитическое мышление и принятие решений. Опираясь на результаты и выводы исследования рекомендуется интегрирование деловой игры в учебный процесс.

***Ключевые слова:*** технический вуз, учебный процесс, инновационные методы обучения, деловая игра, коммуникация

В последние годы, характеризуя актуальное развитие Российской Федерации, и даже всего мира в целом, можно говорить об активном течении научно-технической революции, детерминированной пандемией нового коронавируса. За три года произошли рекордные скачки в развитии цифровых, инженерных, коммуникативных технологий. Безусловно, с одной стороны, такие изменения несут в себе огромный потенциал для развития науки и общества, но, с другой стороны, они бросают серьезный вызов системе высшего образования, которая, итак находится в условиях трансформации: ведь обновленное содержание программ подготовки и перечень формируемых профессиональных компетенций студентов вузов вновь нуждаются в корректировке сообразно произошедшим изменениям.

При этом необходимо принять во внимание, что, если в отношении формирования профессиональных компетенций студентов непосредственно технических специальностей данный процесс относительно понятен и носит менее продолжительный характер, то в отношении обучающихся гуманитарных специальностей технического вуза складывается весьма неопределенная ситуация, поскольку специфика, содержание и особенности влияния результатов технического прогресса на общество в целом и на личность в частности пока практически не изучены. Иными словами, возникает противоречие между необходимостью подготовки компетентных выпускников гуманитарных направлений технического вуза и ограниченностью педагогических средств организации данного процесса. Указанное

противоречие инициировало обращение взглядов преподавателей к проверенным и уже зарекомендовавших себя в качестве эффективных средствам, одним из которых является деловая игра.

М.Б. Земш, рассматривая специфику учебной деловой игры, обращается к ее трактовке Я.М. Бельчиковым и М.М. Бернштейном, согласно которой она представляет собой «метод имитации принятия решений руководящих работников или специалистов в различных производственных ситуациях, осуществляемый по заданным правилам группой людей или человеком с ЭВМ в диалоговом режиме, при наличии конфликтных ситуаций или информационной неопределенности» [1]. При этом ученым указывается, что в деловых играх на основе игрового замысла моделируются жизненные ситуации: игра предоставляет участнику возможность побывать в роли экскурсовода, учителя, судьи, директора и т.п. Использование деловых игр значительно укрепляет связь (студент - преподаватель), раскрывает творческий потенциал каждого обучаемого. Опыт проведения деловой игры показал, что в ее процессе происходит более интенсивный обмен идеями, информацией, она побуждает участников к творческому процессу [4].

Определение деловой игры А.А. Вербицкого является приближенным непосредственно к образовательному процессу в вузе и отражает ориентацию преподавателя при их применении: «Деловая игра - ведущая форма квазипрофессиональной деятельности, по определению профессора А.А. Вербицкого. Согласно его концепции знаково-контекстного обучения, деловая игра – это форма воссоздания предметного и социального содержания профессиональной деятельности, моделирования систем отношений, характерных для данного вида труда» [3]. М.Б. Земш говорит о высоком потенциале применения деловой игры на ступени высшего образования, поскольку она дает возможность студентам увидеть разные грани их будущей профессиональной деятельности при моделировании ситуаций [4].

Анализ исследований применения деловой игры в системе высшего образования на основе работ В.П. Беспалько и Г.К. Селевко, М.Б. Земша и других можно говорить о том, что она представляет собой мощный инструмент, способствующий формированию будущих специалистов [2, 4, 5]. В этом контексте она выступает не только как метод обучения, но и как средство моделирования предметного и социального контекстов будущей профессиональной деятельности. В ходе совместной деятельности каждый студент приобретает социальные навыки, ценностные установки и ориентации, важные для него, как для будущего специалиста.

Центральным фактором успешного применения деловой игры является интерес. Именно интерес становится стимулом для действий участников, направляя их творческую активность. Он вызывает положительные эмоции, ускоряя процесс поиска решений и пробуждая творческое мышление. Яркие положительные эмоции, детерминируемые совместным творчеством в процессе деловой игры, отличают ее традиционных форм учебной работы.

Особенности применения деловой игры включают в себя различные виды и цели. Имитационные игры, операционные игры, исполнение ролей, «деловой театр», психодрама и социодрама – каждая из них направлена на достижение определенных образовательных целей. Выбор конкретной игры зависит от специфики обучения, целей обучения и интересов студентов.

Однако, в зависимости от контекста применения деловой игры, она может приобретать различную специфику. В рамках данного доклада предлагается рассмотреть особенности ее использования в процессе формирования профессиональных компетенций студентов гуманитарных направлений технического вуза. Итак, многолетний опыт преподавания и анализ учебной результативности студентов гуманитарных специальностей технического вуза позволяют говорить о наличии двух основных проблемных зон в области формирования их профессиональных компетенций: это социально-коммуникативные навыки и аналитическое мышление. Деловая игра, в рамках компетентностного подхода, представляет собой эффективное средство для формирования данных навыков.

Рассматривая особенности ее применения подробнее, необходимо отметить, что коммуникативные навыки играют важную роль в будущей профессиональной деятельности данной категории студентов. Например, игра «Проектный менеджмент» создает условия для развития этих навыков при взаимодействии в команде по управлению проектом. Студенты формируют команды, имитируют проектное задание, обсуждают стратегии, представляют свои идеи команде и взаимодействуют с «заказчиком».

Аналитические навыки развиваются в игре «Анализ рыночной ситуации». Задачей студентов является исследование рыночных тенденций, проведение анализа конкурентной среды и выявление сильных и слабых сторон компаний в конкретном рыночном сегменте.

Успешному развитию межличностных навыков, имеющих особое значение для эффективной работы в коллективе, способствует деловая игра «Командное решение проблемы». Студенты играют роли членов команды, решая сложную задачу и акцентируя внимание на эффективном взаимодействии, обмене идеями и разрешении конфликтов.

Еще одна грань специфики использования деловой игры в формировании профессиональных компетенций студентов гуманитарных направленностей технического вуза определяется активным применением цифровых технологий в организации учебного процесса на современном этапе. Они позволяют создавать интерактивные и реалистичные сценарии деловых игр. Симуляция рабочих процессов, внедрение виртуальных инструментов и задач делают опыт студентов более наглядным и соответствующим реальным профессиональным ситуациям.

Онлайн-платформы для деловых игр позволяют студентам взаимодействовать виртуально, преодолевая географические барьеры. Международное сотрудничество вузов, виртуальные телемосты со студентами тех же специальностей иных вузов города, региона, страны или даже других

стран позволяют создавать увлекательные сценарии деловых игр, основанные на реальных проектах, стимулируют взаимодействие обучающихся и позволяют сформировать навыки работы в интервузовских и интерконтинентальных командах.

Цифровые платформы предоставляют возможность создания персонализированных сценариев игр. Это позволяет учитывать уровень знаний, интересы и потребности каждого студента. Адаптивные сценарии корректируют сложность задач в зависимости от профессионального роста студента.

Более того, использование цифровых инструментов в деловых играх обеспечивает обширную аналитику. Результаты, прогресс, обратная связь – все это автоматизировано, что позволяет эффективно мониторить и корректировать образовательный процесс.

Однако, наиболее иллюстративным отражение особенностей использования деловых игр в формировании профессиональных компетенций студентов гуманитарных специальностей технического вуза было бы на конкретных примерах таковых.

В частности, деловая игра «Виртуальный бизнес-симулятор» имеет своей целью развитие навыков управления бизнес-процессами. В ходе ее организации студенты управляют виртуальным предприятием, принимая стратегические решения, анализируя рынок и конкурентоспособность.

Еще одним интересным примером может служить деловая игра «Международный проект по организации мероприятий». Ее целью является формирование международного командного взаимодействия. В процессе организации данной игры студенты работают в онлайн-команде, планируя и реализуя крупное международное мероприятие, учитывая разнообразие культур и требований.Частной версией деловой игры является «интерактивный кейс-метод», направленный на развитие аналитического мышления. При его применении студенты решают кейсы, взаимодействуя с виртуальными бизнес-сценариями, используя цифровые инструменты для анализа данных.

Таким образом, современные деловые игры являются эффективным инструментом формирования профессиональных компетенций у студентов гуманитарных направлений технического вуза, поскольку позволяют развивать необходимые навыки в психологически комфортной для студентов данной категории среде, но с учетом специфики вуза. Это обеспечивает гармоничный тандем реализации личностно-ориентированного и компетентностного подходов к обучению в высшей школе.

Яркий акцент в виде базирования на применении цифровых технологий в организации деловых игр в организации учебного процесса студентов гуманитарных направлений технического вуза значительно повышает их эффективность, делая их более интересными и ресурсными для них. Взаимодействие с цифровыми платформами обогащает образовательный опыт и готовит данную категорию студентов к современным вызовам профессиональной среды.

## Литература

1.Бельчиков Я.М. Бирштейн М.М. Деловые игры.– Рига: Авотс, 1989. – 304 с.
2.Беспалько, В. П. Педагогика и прогрессивные технологии обучения. – М.: Изд-во Института профессионального образования МО России, 1995. – 342 с.
3.Вербицкий А. А. Деловая игра в компетентностном формате// Вестник ВГТУ. – 2013. – №3-2. – С.140-144.
4.Земш М.Б. Учебная деловая игра в гуманитарном вузе: теория и практика / М. Б. Земш. – Москва : Академия естествознания, 2012. – 69 с.
5.Селевко, Г.К. Современные образовательные технологии/Г.К. Селевко. – М.: Народное образование, 1998. – 256 с.

# ТАТАР ҺӘМ БАШКОРТ ДИАЛЕКТЛАРЫНДА КУШМА ИСЕМНӘРНЕҢ ЯСАЛЫШ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

***Сәлахова Р.Р., Сафиуллина Г.Р.***
***Казан федераль университеты***
***ruzilya5@mail.ru***

***Аннотация.*** В данной статье рассматривается проблема диалектного словообразования. Решается задача словообразовательного анализа сложных имен существительных в диалектной лексике. Изучение производных слов в татарских и башкирских диалектах дает возможность глубже вникнуть в процесс их исторических отношений, поскольку одни и те же языковые факты системы говора и системы литературного языка образовались, в ряде случаев, в результате исторического развития общего для них прототипа в разных направлениях и разными темпами.

***Ключевые слова:*** словообразование, деривация, сложные слова, диалектизм, татарский язык, башкирский язык.

Галимнәр хәзерге тюркологиядә көнүзәк мәсьәләләрнең берсе буларак сүз ясалышын, шул исәптән диалект сүзләр ясалышын өйрәнүне дә атыйлар [3: 3]. Проблема актуаль, күп аспектлы, әмма диалекталь сүзләр нигезендә ул өйрәнелмәгән, диярлек. Мәкаләбез кысаларында сүзләр (нигезләр) кушылу ысулы белән ясалган кушма исемнәрне ике тугандаш – татар һәм башкорт телләре мисалында тикшерәбез.

Лингвистикада нигезләр кушылу ысулы турында “ике яки сирәк кенә берничә гади нигезнең бер сүз булып кушылуыннан гыйбарәт, һичшиксез, телнең теләсә нинди берәмлекләрендәге кебек, кушма сүзләрнең компонентлары арасында үзара бәйләнешләр бар, бу хәл компонентларның грамматик табигатеннән һәм лексик эчтәлегеннән чыгып сайлап алынуында чагыла” дигән мәгълүмат бирелә [4: 192]. Алга таба төрле бәйләнеш нигезендә ясалган кушма сүзләрне конкрет мисаллар җирлегендә карарбыз.

Компонентлары тезүле бәйләнештә булган кушма сүзләр гадәттә куш (парлы) сүзләр буларак билгеле; татар телендә дә, башкорт телендә дә алар сүз байлыгының шактый зур өлешен тәшкил итәләр. Куш сүзләрнең компонентлары тигез хокуклылар һәм бер-берсенә бәйле түгел. Мондый сүзләр борынгы чорлардан ук барлыкка килгәннәр, шуңа күрә диалекталь лексикада да аларның саны шактый. Мисалларга тукталыйк:

Дәwәт-тамаҡса – татар диалектының урта диалект дигән төркеменең түбән кама керәшеннәре сөйләшендә бу сүз хәситә белән тамаксадан торган комплекслы бизәнү әйберен аңлата [5:165], ягъни ике диалекталь сүз тезүле бәйләнешкә кереп куш сүз хасил иткәннәр, яңа сүзнең мәгънәсе беренче һәм икенче компонентның мәгънәләре суммасына тигез.

Башкорт диалектларында да мондый очракларны күрергә була. Мәсәлән:

Апһын-әзе – башкорт диалектының көньяк-көнчыгыш төркеменең кызыл

сөйләшендә бу сүзе “килен-ҡәйнә” дигәнне белдерә [2: 23]. Ягъни сүзнең тулаем мәгънәсе (килен-каенана) компонентларның суммасына шулай ук тигез була.

Компонентлары ияртүле бәйләнештә булган сүзләр татар һәм башкорт диалектларында саф кушма сүз буларак та, тезмә сүз буларак та формалаша алалар. Аерым мисалларга мөрәҗәгать итик:

Зәңгәрбаш – синеголовик [5: 200]. Бу үсемлек атамасы мишәр диалектының чистай сөйләшендә очрый. Ул ике компоненнтан тора, компонентлар арасында ияртүле бәйләнешнең атрибутив төре урнашкан.

Башкорт телендәге лексикографик чыганакка карыйк:

Таштабаҡ (ҡыҙыл, әйек-һаҡмар) – тарелка [2: 310]. Аңлашыла ки: аталган сүз көнчыгыш диалект төркеменең кызыл сөйләшендә, көньяк диалектның әйек-сакмар сөйләшендә тәлинкә дигән мәгънәдә йөри. Сүз таш һәм табаҡ компонентларыннан ясалаган, арада ияртүле бәйләнешнең атрибутив төре урнашкан.

Тезмә сүз буларак формалашкан түбәндәге сүзләрдә дә ияртүле бәйләнешнең артибутив төре күзәтелә: оло сырга (Урта диалектның түбән кама керәшеннәре сөйләшендә тәңкәләр тагып челтәрләп эшләнгән алка (серьги с подвесками) [5: 594]); суҡыр серки (башкорт диалектының төньяк-көнбатыш төркеменә карый) [2: 283]; çары сискә – бәпембә (одуванчик); бесәй бәрәмәсе – бесәй табаны (просвирняк); айаҡ ыуылдығы – балтыр (икры ног); әпәй асыçы – әсетке (закваска). Кайбер кушма сүзләрне диалекталь вариантта гына очратырга мөмкин, мәсәлән, башкорт телендә соңрак килеп утырган башҡортларның диалектта әтәмбәй башҡорт дигән атамасы бар, әдәби телдә андый атама сакланмаган, ул һуңыраҡ килеп ултырған башҡорт формасында гына кулланыла.

Ияртүле бәйләнешнең объект бәйләнеше түбәндәге диалекталь сүздә күзәтелә: иташар (татар теленең мишәр диалектының чистай керәшеннәре сөйләшендә христианнарның ураза беткән көннәре атамасы) [5: 219].

Ияртүле бәйләнешнең хәл бәйләнеш төре урнашу хисабына ясалган кушма сүзләрдән татар диалектларында очрый торган алчүпрәк (татар телендә урта диалектның нократ, нагайбәк керәшеннәре сөйләшенә карый), алҗапма (урта диалектның тау ягы, минзәлә сөйләшләрендә; мишәр диалектының хвалын, чүпрәле сөйләшләрендә очрый); күршебабай (башкорт диалектының төньяк-көнбатыш сөйләшләрендә ирләргә ихтирамлы мөрәҗәгать формасы буларак очрый) кебек сүзләрдә күзәтелә.

Күп кенә мондый сүзләрнең бәйләнешен төгәл билгеләүгә сүзнең этимологиясе ачыкланмаган булу комачаулык итә. Мәсәлән:

Бөйерташ – татар диалектының урта диалект дигән төркеменең пермь сөйләшендә чуерташ (крупная галька) мәгънәсен аңлата [5: 131]. Биредә беренче компонентның (бөер) кеше әгъзасы (почка) сүзенә нисбәтле дип алсак (метафорик мәгънә), икенчесенең таш сүзе булуы ачык күренә. Аның әдәби телдәге чуерташ вариантының килеп чыгышы хакында мәгълүматлар юк. Р. Әхмәтьянов фикеренчә, әлеге сүзнең этимологиясе төгәл билгеле түгел [1:

451]. Башкорт теленең көньяк диалектындагы тук-соран сөйләшендә бу сүз суйынташ буларак кулланыла [2: 238]. Моннан тыш, ҫороҡорт – әре ҡорт (трутень) сүзләре дә нигезләр кушылу ысулы белән ясалган кушма сүзләрнең ачык мисалы булып тора. Мисаллардан күренгәнчә, диалекталь сүзләрнең структурасы әдәби телнеке белән туры килмәскә дә мөмкин, мәсәлән, соңгы мисалда без сорыкорт сүзенең саф кушма сүз булуын, әдәби телдәге әре корт мисалының тезмә сүз булуын күрәбез. Киресенчә дә булырга мөмкин, мәсәлән, диалектта ҫоңҡолдауыҡ – әдәби телдә – һөҙһөт (удод).

***Казан шәһәре Идел буе районы 21 нче гимназиясе***
milli@mail.ru

***Аннотация.*** В данной статье рассматриваются педагогические компетенции учителя родного (татарского) языка и литературы в условиях внедрения в практику школ обновленных ФГОС, а также уточняются ключевые позиции федеральной рабочей программы по родному (татарскому) языку. Отдельное внимание уделяется характеристике методических компетенций учителей родного языка, связанных с воспитанием у подрастающего поколения уважения к родному языку, к национальным традициям татарского народа и национальной гордости.

***Ключевые слова****:* обновленнные ФГОС, родной (татарский) язык, федеральная рабочая программа, методические компетенции.

Россия Федерациясенең Мәгариф министрлыгы боерыгы нигезендә башлангыч гомуми белем бирү һәм төп гомуми белем бирү оешмаларында яңартылган Федераль дәүләт белем бирү стандартлары гамәлгә кертелә башлады [1, 2]. Яңартылган федераль стандартларга нигезләнеп, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан «Туган тел», «Туган әдәбият», «Татарстан Республикасының дәүләт (татар) теле» уку предметларыннан федераль эш программалары төзү эше оештырылды. Федераль экспертиза үтеп, алар төп документ буларак фгосреестрга кертелде. Программалар Татарстанның барлык гомуми белем бирү оешмаларында, шулй ук Россия төбәкләрендәге мәктәпләрдә кулланылырга хокуклы [3,4]. Бүгенге көндә, мәктәп укытучылары, аларга нигезләнеп, уку-укыту эшен оештыралар. Туган телләрдән федераль эш программалары берничә бүлектән тора: аңлатма язуы (уку предметына гомуми характеристика, уку предметын өйрәнү максатлары, уку предметының уку-укыту планындагы урыны); уку предметының эчтәлеге (һәр сыйныф өчен аерым бирелә); уку предметын үзләштерүнең көтелгән нәтиҗәләре: шәхескә бәйле, метапредмет, һәр сыйныф өчен аерым күрсәтелгән предмет нәтиҗәләре. Федераль эш программалары ФДББС таләпләренә туры килә һәм уку-укыту процессында түбәндәгеләрне тәэмин итүгә юнәлтелгән: сыйфатлы белем алуга тигез мөмкинлекләр; белем бирү процессын оештыру шартларына бердәм таләпләр; белем бирү нәтиҗәләрен бәяләүгә бердәм таләпләр; уку предметының мәҗбүри эчтәлеген һәр уку елы өчен аерып күрсәтү; темаларны өйрәнүгә бүлеп бирелгән вакыт һәм аларны үзләштерүнең эзлеклелеген якынча билгеләү. Федераль эш программасы аерым дәреслекләргә, укыту-методик комплектларга

бәйле булмый. Алар туган тел һәм туган әдәбиятны заманча укытуга, укучыларда сөйләм, тел һәм этномәдәни компетенцияләр, функциональ грамоталылык булдыруга юнәлтелән. «Туган тел», «ТР дәүләт (татар) теле» уку предметларыннан планлаштырылган предмет нәтиҗәләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) сөйләм эшчәнлегенең төп төрләре буенча аралашу осталыгына ия булу;

2) белем бирү һәм үзлегеңнән белем алу процессында шәхеснең интеллектуаль һәм иҗади сәләтләрен үстерүдә телнең хәлиткеч ролен аңлау;

3) туган телнең коммуникатив-эстетик мөмкинлекләреннән файдалану;

4) туган тел турындагы фәнни белемнәрне киңәйтү һәм системалаштыру; аның дәрәҗәләре һәм берәмлекләренең үзара бәйләнешен аңлау һәм гамәли үзләштерү;

5) сүзләргә төрле анализ ясау, сүзтезмәне һәм җөмләне синтаксик анализлау күнекмәләренә ия булу, текстны төрле аспектларда анализлый алу;

6) укучыларның сүзлек байлыгын арттыру, аралашу ситуациясенә бәйле фикерләрне һәм тойгыларны ирекле белдерү өчен, грамматик формаларны куллану;

7) әдәби телнең төп стилистик ресурсларына һәм нормаларына, сөйләм этикеты нормаларына ия булу; телдән һәм язма сөйләмдә аларны куллануга ирешү; сөйләмне камилләштерүгә омтылу;

8) гомумкешелек кыйммәте буларак тел культурасы өчен җаваплы булу.

Яңартылган федераль стандартларны гамәлгә кую чорында туган тел укытучысыннан түбәндәге педагогик компетенцияләргә ия булу сорала:

- социаль компетенцияләр (җаваплылыкны үз өстеңә алу; дөрес карар кабул итә белү; күпмәдәниятле җәмгыятьтә яшәү шартларын ачык күзаллау; эштә һәм җәмәгать урыннарында төрле кешеләр белән телдән һәм язмача аралашуга әзер булу; Интернет һәм массакүләм мәгълүмат чараларында урын алган хәбәрләргә тәнкыйть күзлегеннән карый белү);

- оештыру осталыклары (укучыларны берләштерү, танып белү эшчәнлегенә тарту, эшкә нәтиҗә ясау);

- дидактик осталыклар (дәрес материалын аңлаешлы һәм эзлекле итеп аңлату, укучыларның танып белү активлыгын арттыру);

- перцептив осталыклар (психологик күзәтүчәнлек, укучыларның эчке халәтендәге үзгәрешләрне күрә белү, психик үзенчәлекләрен исәпкә алып эш итү);

- суггестив осталык (укучыларга эмоциональ тәэсир күрсәтә алу);

- тикшеренү осталыгы (педагогик ситуацияләргә һәм уку-укыту процессына объектив бәя бирә белү; белем бирү өлкәсендәге үзгәрешләрне алдан тоеп эш итү);

- фәнни-танып белү осталыгы (үз өлкәндә заманча фәнни белемнәргә ия булу; һөнәри яктан үсеш алуга, методик осталыкны һәм иҗади активлыкны арттыру, гамәли эшчәнлекне камилләштерүгә омтылу).

Методик осталыкларга килгәндә, алар түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

- “укытучы-укучы” системасы белән идарә итә белү (максат-бурычларны билгеләү, белем бирү процессын оештыру һәм нәтиҗәләрне бәяләү);

- дәресне үткәрүгә методик үзгәрешләр кертү;

- шәхескә юнәлтелгән педагогик технологияләрдән файдалана белү;

- укучыларга мөстәкыйль белем алу өчен шартлар булдыру;

- белем бирүнең сыйфатын яхшырту һәм эшнең нәтиҗәлелегенә ирешү.

Туган тел дәресләрендә белем һәм тәрбия бирүнең сыйфатын яхшырту һәм нәтиҗәләргә ирешү өчен, укытучыга заманча технологияләрдән, цифрлы ресурслардан файдалану да зарур: мәгълүмати технологияләр, дистанцион укыту технологияләре, тәнкыйди фикерләү технологиясе, проект технологиясе, үстерелешле укыту технологиясе, проблемалы укыту технологиясе, уен технологиясе, модульле укыту технологиясе, кейс технологиясе, кроссенс технологиясе, берләштереп укыту технологиясе һ.б.

Шуны да ассызыклап үтик, бүгенге шартларда Татарстанда һәм Россиянең төрле төбәкләрендә эшләүче татар теле һәм әдәбияты укытучыларының мөһим эшләреннән берсе булып балаларда милли горурлык тәрбияләү эше тора. Татар халкы – югары мәдәниятле халык. Иҗатлары, тормышның төрле өлкәләрендә ирешкән казанышлары белән дөньяда танылган, дөнья мәдәниятенә зур өлеш керткән шәхесләребез бихисап. Менә шулар үрнәгендә яшь буында татар халкының лаеклы уллары һәм кызлары булу хисе булдыру зур әһәмияткә ия. Туган тел һәм әдәбият дәресләрендә дә, сыйныфтан тыш эшләрдә дә моңа аерым игътибар бирү сорала. Әйткәннәрне дәлилләү өчен, күренекле татар мәгърифәтчесе Ризаэтдин Фәхретдиннең сүзләрен искә алып үтәсе килә: “Балачакта алган тәрбияне соңыннан бөтен дөнья халкы да үзгәртә алмас.” [5: 134]. Димәк, туган тел укытучысының җаваплы эшләренең тагын берсе - бала күңелендә туган телгә карата хөрмәт уяту. Бала кечкенәдән үк татар әкиятләрен, татар җырларын, татар әдипләренең әсәрләрен тыңлап, укып үссә, ул ирексездән үз халкының баласы булып җитешә, татар җанлы булып үсә, үз милләте турында кайгыртырлык итеп тәрбияләнә.

Йомгак ясап, шуны әйтәсебез килә: тел үзендә кешелек тарихын саклый. Һәрбер халык туган телен саклап калу, үстерү, укыту, дөньяда тарату һәм таныту турында кайгыртып яши. Туган телебезне, гасырлар буена сакланып килгән гореф-гадәтләребезне, түкми-чәчми, киләсе буынга житкерергә тиешбез. Телне саклау – халыкны саклау дигән сүз ул. Әгәр бүгенге көн укучылары мәктәпләрдә татар әдәби телен үзләштермиләр икән, аның киләчәге булмаячак. Тел бетсә, милләт тә яшәүдән туктый, чөнки милләтне саклау телне саклаудан башлана. Яңартылган федераль дәүләт белем бирү стандартларында әйтелгәнчә, укытуның максаты җәмгыять тарафыннан куелган социаль заказ белән билгеләнә. Татар телен укыту барышында иҗади фикерләүче, иҗтимагый тормышта актив катнашучы, белемле, дәүләт телләрендә һәм чит телләрдә иркен сөйләшеп аралашучы билингваль (полилингваль) шәхес тәрбияләү төп бурыч булып билгеләнә. Күргәнебезчә, туган (татар) тел укытучыларының эшчәнлегенә педагогик һәм методик таләпләр көннән-көн арта бара, чөнки, заман белән бергә атлау өчен, аларга дәресләрдә эш алымнарын төрләндерергә,

балаларның яшь үзенчәлекләренә яраклы эш төрләрен кулланырга туры килә. Шунлыктан әлеге юнәлештә фикер алышу оештыру, алдынгы тәҗрибә белән уртаклашу эше даими рәвештә алып барылырга тиеш.

Илебезнең киләчәге җәмгыятебездәге кешеләр белән бәйле. Ә ул кешеләргә укытучылар белем һәм тәрбия бирә. Шуңа күрә туган тел укытучысыннан үз эшен намуслы, нәтиҗәле итеп башкару сорала.

**Әдәбият**

1.ФГОС НОО https://www.garant.ru/products/ipo/prime/doc/400807193/ (дата обращения 10.01.2024)
2.ФГОС ООО https://www.garant.ru/products/ipo/prime/doc/401333920/ (дата обращения 10.01.2024)
3.Федеральная рабочая программа учебного предмета «Государственный (татарский) язык Республики Татарстан» для 1-4 классов. https://mon.tatarstan.ru/rus/file/pub/pub_3230313.pdf (дата обращения 10.01.2024)
4.Федеральная рабочая программа учебного предмета «Государственный (татарский) язык Республики Татарстан» для 5-9 классов. https://mon.tatarstan.ru/rus/file/pub/pub_3230313.pdf (дата обращения 10.01.2024)
5.Фахреддин Р. Жизнь длиною в жизнь. Казань: Рухият, 2014. 148 с.

# ТУГАН (ТАТАР) ТЕЛ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ТОПОНИМИК МАТЕРИАЛДАН ФАЙДАЛАНУНЫ РЕГИОНАЛЬ КОМПОНЕНТКА НИГЕЗЛӘНЕП ОЕШТЫРУ

***Хадиева Г.К., Кузьмина Х.Х.***
***Казан федераль университеты***
***gul-khadieva@yandex.ru; shirmanx@yandex.ru***

***Аннотация.*** Использование топонимического материала на занятиях по родному (татарскому) языку обеспечивает реализацию регионального компонента ФГОС и, как следствие, способствует воспитанию у учащихся чувства патриотизма, формированию и укреплению у них навыков гражданской позиции.

***Ключевые слова:*** родной (татарский) язык, топонимия, региональный компонент

Топонимик материалны татар теле дәресләрендә һәм, аерым алганда, сыйныфтан тыш чараларда куллану мәсьәләсендә федераль дәүләт белем бирү стандартларының региональ компоненты аеруча мөһим роль уйный. Моны дәлилләү максатыннан мәгариф системасындагы үзгәрешләргә һәм региональ компонентның үзенчәлегенә тукталып китәргә тәкъдим итәбез.

XX гасырның соңгы чирегеннән алып бүгенгәчә Россиянең мәгариф системасы форма һәм эчтәлек ягыннан шактый үзгәрешләр кичерә. Болон системасын кабул итү, уку-укыту процессын Европа мәгарифе кануннарына буйсындыру белән бергә әлеге өлкәдәге мондый төр модернизацияне тормышка ашыруның төп шарты булып Россиядә, шул исәптән Татарстан республикасы территориясендә дә, географик яктан гына түгел, социаль мәдәни яктан да гомуми белем бирү мәйданына юл ачу чарасы булган федераль дәүләт белем бирү стандартларын кабул итү, аларны кулланылышка кертү тора. Бу исә, үз чиратында, Россиядә мәктәп яшендәге балаларга теләсә кайсы урта һәм төп гомуми белем бирү оешмаларында тулы белем алу хокукын, белемнең һәркем өчен ачык һәм федераль дәүләт белем бирү стандартлары билгеләгән чикләрдә түләүсез булуын тәэмин итә.

Федераль дәүләт белем бирү стандартларын тормышка ашыру нигезен гомуми белем бирү оешмасының уку-укыту планы тәшкил итә. Планның структурасы өч компоненттан гыйбарәт: 1) федераль; 2) милли-региональ; 3) белем бирү оешмасының компоненты.

Региональ компонент федераль компонент таләпләре белән ярашырга, базис планның инвариант өлешен күләгәдә калдырмыйча һәм регионның тар кысаларында гына калмыйча федераль компонентның үсешенә уңай йогынты ясарга тиеш.

Гомуми белем бирү оешмаларында укучыларга ономастик, аерым алганда, топонимия белән бәйле белем бирү укучыларда милли үзаң формалаштыру мәсьәләсе белән турыдан-туры бәйле, чөнки торак пункт, шәһәр

атамаларын өйрәнү, аларның этимологиясен ачыклау процессында катнашу, класстан тыш чараларда туган төбәк хакында проект эшләре башкару укучыларда ватанпәрвәрлек, үз халкыңа, мәдәниятеңә, тарихка хөрмәт хисләре тәрбияләү чарасы булып тора. Ономаст Г.Ф. Саттаров «Мәктәптә туган як ономастикасы» дигән хезмәтендә, шулай ук  башка тел белгечләре бу турыда яздылар [1; 3].

А.В. Суперанская үзенең «Общая теория имени собственного» дип аталган хезмәтендә ялгызлык исемнәрнең төрле сөйләм һәм язма стильләрдә очравын ассызыклый. Әлеге тел берәмлекләреннән башка, мисал өчен, изложение, рецензия, хатны күз алдына китерү мөмкин түгел. Шул сәбәпле, укучылар мондый төр сүзләр запасын баетырга, аларның үзенчәлекләрен өйрәнергә, ялгызлык исемнәрнең охшашлыкларына һәм аларның төрләргә бүленеш принципларына төшенергә тиеш [2: 262].

Методистлар ономастик материалларны тел өйрәнүне тирәнәйтү чарасы буларак кабул итәләр һәм аларны тел дәресләрендә генә түгел, сыйныфтан тыш чараларда да куллану зарурлыгын билгелиләр. Бу эш төре мәктәптә укытыла торган башка предметлар, аерым алганда, география, әдәбият, җәмгыять белеме, тарих дәресләре белән бергәлектә алып барылганда, нәтиҗәсе югарырак булуга өмет бар. Мисал өчен, сыйныфтан тыш чара буларак «Туган авылым микротопонимиясе», «Авылым атамасының килеп чыгышы», «Исемемнең мәгънәсе» һ.б. темаларга докладлар ясау үткәрергә мөмкин. Бу, бер яктан, балаларның сөйләм телен үстерү, ораторлык осталыкларын камилләштерү булса, икенче яктан, әлеге эш укучыларга фәнни эш язу күнекмәләрен бирә, ономастик материал белән тирәнтен таныштыру чарасы да булып тора. Моннан тыш ялгызлык исемнәрне шул рәвешле өйрәнү укучыда күзәтүчәнлек, кызыксыну хисләрен уята, чөнки бу очракта укучының шәхесенә, биографиясенә зур игътибар бирелә. Укытучыга, үз чиратында, әлеге алым шәхескә якын килеп укыту, индивидуальләштерү принцибын тулысынча тормышка ашырырга мөмкинлек бирүе белән әһәмиятле.

Укучыларга топонимика буенча мәгълүмат бирү, татар теле дәресләрендә, сыйныфтан тыш чараларда әлеге белемнәрне тулыландыру һәм камилләштерү мөһим мәсьәлә булып тора, һәм әлеге мәсьәләне чишүнең зарурлыгы хәзерге традицион дәресләргә дә үзгәреш кертүенә әзер булу кирәк.

Билгеле булганча, мәктәп курсының традицион нигезендә тел нормаларын үзләштерү өчен кирәк булган телне структур-семантик яктан тасвирлау ята. Ул исә, үз чиратында, коммуникатив һәм мәдәни аспектлар ярдәмендә тулыландырыла. Соңгы вакытта уку-укыту практикасына кертелгән милли-региональ компонент федераль дәүләт белем бирү стандарт структурасы эчендә тәкъдим ителә.

Милли-мәдәни аспект стандартның федераль һәм өлешчә региональ компонентларын тормышка ашыра. Региональ компонент Россия федерациясенең билгеле бер субъектының җирле үзенчәлекләрен чагылдыра торган региональ аспектта реальләшә.

Бүгенге көндә лингвистлар, методистлар, мәктәп һәм югары уку йортлары укытучылары, телне мәдәни-тарихи мохит буларак караган хәлдә, өйрәнүнең традицион чикләрен киңәйтәләр, милли менталитетның үзенчәлеген чагылдыра торган тел билгеләрен активлаштыралар. Бу исә телара элемтәләр принцибын төгәл үтәгәндә генә мөмкин. Методистлар фикеренчә, ономастиканы, аерым алганда топонимнарны өйрәтүне мәктәп курсына кертү укучыларда туган ягына, аның тарихына кызыксыну уята, аларда сакчыл караш тәрбияли. Шул ук вакытта әлеге исемлек татар телен укытуның традицион бурычлары белән тулыландырыла.

Топонимик материалны лексика, фонетика, орфоэпия, сүз ясалышы, грамматика бүлекләрен өйрәнгәндә дәрес барышына кертеп җибәрү интеграцияләнгән дәресләр, экскурсия-дәресләр, рольләргә бүлеп уйнау, иҗади конкурслар, сәяхәт-дәресләр үткәрергә мөмкинлек бирә.

Туган (татар) тел дәресләрендә топонимик материалны һәрдаим куллану уку-укыту ягыннан гына түгел, тәрбияви яктан да бик мөһим. Бала өчен туган телдә иркле аралаша алу мөмкинлеге белән бергә бу тормышта, җирдә үзенең урынын табу, Ватаны, туган җире белән гармониядә булу, үзен аның белән бергәлектә бербөтен итеп тою да әһәмиятле. Әлеге эштә иң мөһиме – төрле ысул-алымнар, дәрес формалары кулланып, укучыны ялыктырмыйча, аңарда кызыксыну хисләре уяту.

Безнең фикеребезчә, ялгызлык исемнәрне, аерым алганда топонимик материалны текстларга кертү, сөйләм телен үстерү дәресләрендә куллану, контроль диктант текстларын топонимнарның кулланылу ешлыгына карап сайлау, укучыларның мөстәкыйль эшен туган якны өйрәнү эше белән бәйләп оештыру, класстан тыш чараларда топонимнар буенча проект эшләре уздыру тәрбияви яктан да, уку-укыту процессының нәтиҗәлелеген тәэмин итү ягыннан да, телгә өйрәтү өлкәсендә дә уңышлы булыр.

Шулай итеп, топонимик материал укучыларның танып-белүгә омтылышларын көчәйтә, уйлау сәләтен үстерүгә мөмкинлек бирә. Танып-белүгә кызыксынуны үстерү белән бергә, топонимиканы тел дәресләрендә куллану гомуми грамоталылык һәм сөйләм культурасы дәрәҗәсен үстерүгә китерә, чөнки географик атамаларны дөрес язу һәм әйтү кагыйдәләре топонимиканы укыту системасына керә.

**Әдәбият**

1. Саттаров Г.Ф. Мәктәптә туган як ономастикасы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. – 286 б.

2. Суперанская А.В. Общая теория имени собственного. - М.: Книжный дом «ЛИБРОКОМ», 2012. - 368 с.

3. Һадиева Г.К., Кузьмина Х.Х. Гомуми белем бирү оешмалары өчен татар телендә төзелгән дәреслекләрдә топонимик материалның кулланылышы // Совершенствование прогрессивной практикой: материалы V Международного научно-методического онлайн-семинара (Казань – Баку – Измир – Уфа, 18

февраля 2021 г.) = Телләргә өйрәтү методикасын камилләштерү: алдынгы тәҗрибә белән уртаклашу мәйданчыгы: V Халыкара фәнни-методик онлайн семинар материаллары (Казан –Баку – Измир - Уфа, 2021 елның 18 феврале). – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2021. – С. 310-320.

# ТУГАН ТЕЛ ТУРЫНДА УЙЛАНУ

***Хайруллина Р.Ш.***
***Кама Тамагы районы УБМ***
***hairullinaraushanya@yandex.ru***

***Аннотация.*** В статье представлены размышления об овладении речевой компетецией на татарском языке.

***Ключевые слова:*** татарский язык, общение, интернет.

Дөньяда күпме милләт, шулкадәр тел бар. Һәр милләт үз телендә сөйләшә, аралаша. Һәр яңа туган нарасыйның да теле туган телендә ачыла. Ата-ана, әби-баба баланы үз телендә сөйләшергә өйрәтә, үз телендә җырлар җырлый, экиятләр сөйли.

Телләрне күбрәк белгән саен, кешенең белеме дә, шуның белән бергә үз-үзенә ышанычы да арта. Татар телен белеп, мәсәлән, башкорт, казах, әзәрбайҗан, төрек һәм бик күп башка тугандаш телләрне аңлап була. Хәтта әрмән телендә дә татарныкына охшаш сүзләр бар.

Безнең туган телебез дә – татар теле, бөек Тукай, Сәйдәш, Туфан, Такташ, Җәлилләр теле. Кечкенәдән бишек җырларын, Тукай шигырьләрен, соңрак халкым җырларын тыңлап үскәнгәдер, туган телем миңа иң моңлы, иң матур яңгырашлы тел булып ишетелә.

Кызганычка каршы, елдан-ел туган телемне рус теле кысырыклый бара. Ник дигәндә, рус телен өйрәнү татар телен өйрәнүгә карарганда күпкә җиңелрәк. Мәсәлән, без яшәгән посёлокта хәзер татарлар күбрәк булуга карамастан, башлыча русча аралаша халык. Яңа гына авылдан күчеп килгән апа-абыйлар балалары, оныклары белән вата-җимерә русча сөйләшергә азаплана. Аларга акцент белән русча сөйләшергә оят түгел, ә үз телләрендә - оят. Каян килә бу мескенлек?

Халкымны элек-электән кимсеткәннәр, кыерсытканнар. Иң элек явыз Иван татарны көчләп чукындырган, мәчетләрне, мәдрәсәләрне яндырган, татар-фарсы, гарәп телендә язылган китапларны, истәлекләрне юкка чыгарган. Бу сәясәтне Пётр I дәвам иткән. Шуңа караматан, халкым көчен, хәтта гомерен дә кызганмыйча, үз телен, динен саклап калган.

Совет чорында да җиңел булмады. Урамда татарча сөйләшкән кешеләргә руслар тарафыннан шелтә белдерелгән очраклар да күп булды. Менә шуңа күрә татар кешесе туган телендә рәхәтләнеп сөйләшергә кыенсына да инде, минемчә.

Бу күренеш тагын дин белән дә бәйледер дип уйлыйм мин. Мөселманнар элек-электән тыйнак халык булган: кычкырып сөйләшмәгән, кычкырып көлмәгән. Күндәм булган, юл куя белгән. Дин шулай кушкан.

Биш-ун ел элек мәктәпләрдә татар теле атнасына 3-4, ә әдәбият ике дәрес укытылып килде. Тугызынчы сыйныфтан соң татар телле укучылар гына түгел, рус теллеләре дә имтихан тапшыра иде (аралашуның күркәм, тик хәзерге яшьләргә сәер тоелган бер төре – хат язарга, дөрес итеп диалог төзергә,

сорауларга төзек җөмләләр белән җавап бирергә өйрәнделәр алар). Беркем дә зарланмады, ата-ана да ризасызлык белдермәде. Хәзер исә телебез ирекле рәвештә өйрәнү мөмкинлегенә калдырылды. Мәсәлән, укучылар, татар телен яхшы белүенә карамастан, үз теләге буенча рус төркеменә языла, хәтта телне өйрәнүдән баш тарта ала. Шундый очраклар да күзәтелә: бала татар төркемендә калырга тели, ә ата-аналары, мәшәкатьтән куркып, рус төркеменә күчерәләр. Телне өйрәнүдән баш тартканнары, үз телен өйрәнмичә, татар була торып, “туган (рус) тел” дип аталган төркемдә укый. Аларның ата-аналары нәрсә уйлый икән? Кайда телең, динең белән горурлану хисләре? Минем шуңа исем китә. Бит туган телгә, туган халыкка мәхәббәт хисләре уятучылар, иң беренче чиратта – ата-аналар. Гаиләдә, аннан соң балалар бакчасында, башлангыч мәктәптә туган телендә тәрбияләнгән бала ана телен инде онытмаячак, ди белгечләр. Ана телендә тәрбияләнгән бала тәртиплерәк, әхлаклырак, туган җанлырак та була. Минемчә, бала үз ата-анасына, туганнарына булган җылы хисләрен туган телендә генә җиткерә ала. Гаиләдә телебезгә хас булган күркәм гадәт буенча “әни”, “әти”, “апа”, “абый”, “энем”, “сеңелем”, “алма апа”, “нәни апа” һ.б. дип бер-береңә эндәшү дә туганлык хисләрен тагын да арттыра. Чит телдә сөйләшеп, ата-ана балаларын, оныкларын шундый җылы хисләрдән мәхрәм итәләр ич!

Мин бер күренешне хәтерлим. Әтисе татар, әнисе рус милләтеннән булган бер баланы яныма чакырып алдым, безнең арада шундыйрак сөйләшү булды:

- Ник син татар телен өйрәнергә теләмисең? Күрәсең, рус милләтеннән булганнар да теләп өйрәнә, ә синең әтиең - татар!

- Миңа татар теле кирәк түгел, мин – рус!

- Мин синең дәү әтиеңне әйбәт белә идем, район Советында бергә эшләдек. Татар телендә ул шундый дөрес, матур итеп сөйләшә иде, хәйран калырсың! Гомере буе балаларым дип янып-көеп яшәде, иртә китте. Оныкларым үз туган телләрен белми, диннәре дә, телләре дә юк дип сиңа рәнҗеп ятса, оятын кая куярсың? Шул турыда уйлап кара әле!- дигән идем мин аңа русча, әлбәттә.

Вакыт узды, ни хикмәт, бу малай үзгәрде, туган телен тырышып-тырышып өйрәнә башлады. Димәк, дөрес нәтиҗә ясады, фикеремне дөрес аңлады. Димәк, теләгән кешегә укытучы сүзләре дә тәэсир итә! Укытучы һөнәрен дөрес сайлаганмын икән дип тагын бер кат шатланып куйдым шул чакта.

Советлар чорында үрнәк алу өчен В.И.Ленин, аның гаиләсе, октябрят, пионер, комсомол оешмалары бар иде, бүгенгесе көндә алар берсе дә юк. Аларны алыштырырлык үрнәк тә юк. Кызганыч!

Элек балалар тирән мәгънәле тәрбияви фильмнар, мультфильнар, экиятләр карап үссәләр, хәзерге чор балалары чит илдән кертелгән куркыныч, мәгънәсез тапшырулар карыйлар, компьютерда миңгерәткеч уеннар уйныйлар. Үзара аралашырга да вакытлары калмый. Татар телен әйтәсе дә юк, рус телендә

рәтләп сөйләшә алмыйлар – сүз байлыклары сай! Бу күренеш аларның китаплар аз укуыннан яки бөтенләй укымавыннан да килә.

Еллар узган саен, балаларга күбрәк ирек бирелә бара. Ата-ана кечкенәдән артык ирек биргәнгә, үсә төшкәч, балалары үзләрен дә тыңламый башлый. Юкка гына борынгылар "Баланы сәкегә аркылы ятканда тәрбиялиләр"- дип әйтмәгәннәр!

Элегрәк авыл балалары татарча матур итеп сөйләшә иделәр. Ә хәзер, мәктәпләрне комплектлаштырабыз дип авыл мәктәпләрен ябып, аларны районнарга алып килеп укыталар. Ул балалар да үзара русча аралаша.

Кешеләрне көчләп туган телләрендә генә сөйләштереп булмый. Хәзерге заманда туган телен дә, русча һәм инглизчә дә белгән кешеләр кирәк. Ләкин, татар теленең дәрәҗәсе төшкәнлектән, укучылар аны өйрәнүдән баш тарта. Моңа бердәм дәүләт итиханнарын тапшыру кертелү дә сәбәпче. Математика, рус теле һәм әдәбияты иң мөһим предметларга әйләнделәр, чөнки алар буенча имтихан тапшыру мәҗбүри. Шулардан кала, сайлап алына торган фәннәр: тарих, җәмгыять белеме, физика, биология, химия һ.б., ә татар теле - исемлекнең иң ахырыда. Бер-ике ел элек, ниһаять, татар теле һәм әдәбияты буенча имтхан бирдерүгә игътибар итә башладылар. Тик теләүче укучылар гына юк дәрәҗәсендә. Чөнки бу фәннәрдән имтихан нәтиҗәләре беркайда да кирәкми диләр алар. Мәсәлән, минем чыгарылыш сыйныфындагы бер укучым рус телен дә, инглиз телен дә әйбәт белә. Туган телебездә иркенәп аралаша. Тик, олимпиадада, җиңмәс өчен, соңгы биремне үтәмәгән – хикәя язмаган. Республикада ул тарих, инглиз теле буенча олимпиада призеры. Татар телен дә нечкәлекләре белән өйрәнү аңа көчкә киләчәк. Шулай итеп, туган телебезне өйрәнү укучыларга авыр йөккә әйләнеп бара, аның дәрәҗәсе төшә дә инде.

Туган телнең дәрәҗәсе төшүнең тагын бер сәбәбе – ата-анага уку-укыту, тәрбия процессына кагылган мәсьәләләрдә артык ирек бирү. Элек төркемнәргә бүлү эше белән мәктәп дирекциясе шөгыльләнсә, хәзер бу мәсьәлә ата-ана теләген истә тотып хәл ителә. Алда язып узганымча, ата-ана, артык мәшәкатьтән куркып, рәхәтләнеп туган телдә аралашкан баласын рус төркеменә, хәтта туган (рус) төркеменә бирә. Укытучы, баланың татар төркеменнән рус төркеменә күчүеннән куркырга, балага "икеле"ләр, "өчле"ләр, куймаска, өй эше бирмәскә мәҗбүр була. Юк-бар сәбәп аркасында да ата-ана укытучы өстеннән мәктәп дирекциясенә түгел, район мәгариф бүлегенә, алай гына да түгел, мәгариф Министрлыгына шикаять белән мөрәҗәгать итә. Ә югарыдагылар, вакытларын кызганмыйча, шул әләк белән шөгыльләнергә мәҗбүр. Шулай итеп, балаларны укыту, тәрбияләү эшендә катнашучы өчпочмак: укытучы – бала - ата-ана – үз вазифалары белән шөгыльләнер урынга, вакытларын юк-барга сарыф итәргә мәҗбүр.

Мин – татар теле һәм әдәбияты укытучысы. Хәзер без "туган тел һәм әдәбият укытучылары" дип аталабыз. Алда язып үткәнемчә, мәктәпләрдә өч ел элек татар һәм рус төркемнәреннән кала, туган (рус) тел укытучылары да барлыкка килде. Мәктәп программасында татар теле һәм әдәбияты дәресе атнасына өчкә кадәр кыскартылганга күрә, туган тел укытучылары байтагы яки

квалификацияләрен үзгәртергә, яки лаекы ялга китәргә мәҗбүр булдылар. Тик, өлкән буын вәкилләре мәктәпләрдә кирәк дип уйлыйм мин, чөнки алар – татар халкын прогресска илтү, телен үстерү, мәдәниятен алга җибәрү өчен, иң әһәмиятле шарт - халыкта, барыннан да бигрәк, балаларда, яшьләрдә, милли горурлык, әхлакый тәрбия, патриотлык хисләре булдыручылар, бу хисләрне укучыларда, ата-аналарда тәбияләүләр, гореф-гадәтләребезне, йолаларыбызны саклаучылар, үткән белән бүгенгене, киләчәкне тоташтыручылар.

Тормышта кеше нинди генә югарылыкларга күтәрелмәсен, ул нигездә балачакта, гаиләдә алган гадәтләрне, күнекмәләрне ташламый диярлек. “Бала чакта алган тәрбияне соңыннан бөтен дөнья халкы да үзгәртә алмас”, - дип юкка гына әйтмәгән бөек мәгърифәтче Ризаэддин Фәхреддин. Ә бит телнең нечкәлекләрен белү һәм саклау өчен, аны һәрвакыт куллану кирәк. Бөек шәхесебез Садри Максуди менә нәрсә дигән: “Телебезне өйрәнми башлаган көннән башлап без бетә башлаячакбыз. Безнең бер милләт булып тора алуыбыз телебезне саклый алуыбызга бәйледер. Телебезне саклый алсак, бер милләт булып тора алырбыз, әгәр телебезне саклый алмасак, милләтебездән мәхрүм булырбыз”.

Чыннан да, тел - халыкның, милләтнең иң беренче, иң әһәмиятле билгесе. Тел бетсә, ул телнең иясе булган халык та, милләт тә югала. Шуның өчен дә туган телен кадерләп саклау, үстерү, аның сафлыгы, матурлыгы өчен көрәшү - мәдәниятле, зыялы һәр кешенең изге бурычы. Без - татарлар. Телебезне киләчәк буыннарга тапшыру, балаларыбызга-оныкларыбызга гореф-гадәтләребезне сеңдерү – милләтебезне саклауның мөһим шарты.

# ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ЭЙЛЕР ТҮГӘРӘКЛӘРЕН ФАЙДАЛАНУ

***Шарипова Р. Ш.***
***1нче номерлы Бакалы гомуи белем бирү мәктәбе***
***ralliya.sharipova@mail.ru***

***Аннотация.*** В статье обсуждается проблема сохранения родных языков в современных условиях. Использование современных инновационных образовательных технологий, методов, приемов – это объективная необходимость и условие достижения высокого качества современного образования. Сегодня, наряду с активными формами обучения, широко востребованы и интерактивные, в ходе которого осуществляется взаимодействие между учеником и учителем, а так же между самими учениками. Моей находкой стало использование кругов Эйлера**.** Я бы хотела рассказать об эффективности этого метода на уроках татарского языка и литературы.

***Ключевые слова:*** круги Эйлера**,** современные и инновационные технологии, прививать любовь к родному языку.

Бүгенге көндә рус телле балаларга татар теле укыту зур проблема булып тора. Шуңа күрә, татар теле дәресләрен хәзерге заман балалары өчен кызыклы итеп үткәрергә тиешбез, ягъни укучыларда фәнне өйрәнүгә карата уңай мотивация тудырырга кирәк. Соңгы елларда күп кенә яңа технологияләр тәкъдим ителде һәм гамәлгә кертелде. Укытучы алдында яңа педагогик технологияләрнең иң нәтиҗәлеләрен сайлап алып, аны үзләштерү зарурлыгы туды һәм шуларның берсе үзем кулланган “Эйлер түгәрәге”технологиясе.

Бу нинди түгрәкләр соң? Бу түгәрәкләрнең авторы, берничә фән өлешенә гаять зур өлеш кертүче, күренекле алман галиме, математик, физик, астроном – Леонард Эйлер.

“Эйлер түгәрәге”- объектлар, төшенчәләр арасындагы мөнәсәбәтләрне табарга ярдәм итүче геометрик схемалар[1]. Үзенчәлеге: укучылар эзләнәләр, объектларны классификациялиләр, предметларның, төшенчәләрнең билгесе буенча анализ ясыйлар, чагыштыралар, нәтиҗә ясарга өйрәнәләр.

Гомумән, дәрестә без төшенчәләрне, предметларны, объектларны чагыштыру өчен таблица кулланабыз. Таблица ярдәмендә аерманы яхшы күрсәтеп була, ә ике яки өч төшенчәнең уртак якларын табып күрсәтү авырлык тудыра. Ә “Эйлер түгәрә”генең кисешкән зонасында төшечәләр өчен уртак билгеләр күренеп тора.

2000 ел элек кытай галиме Конфуции: “Ишетүмне онытам, күргәнемне хәтерлим, эшләгәнемне аңлыйм”,- дигән. “Эйлер түгәрә”ге күрсәтмәлелеге белән аерылып тора.Укучы күрә, үзе эшне башкара. Шулай итеп, укучы алдына куелган эшне, максатны кызыксынып, аңлап башкара һәм теманы яхшы үзләштерә. “Эйлер түгәрә”ген башлангыч класстан ук кулланырга мөмкин. Башта укучылар бер түгәрәк белән эшләргә өйрәнә. Мәсәлән, “Үрдәк

беренчелекне алган” әкиятен үзләштерерү, нәтиҗә ясау өчен кулланылган түгәрәк. Әкият укылганнан соң, әкияттә катнашкан һәм шулай ук катнашмаган образлар языла. Укучыларга әкияттә катнашкан геройларны гына түгәрәк эченә урнаштырырга, дигән эш тәкъдим ителә. Әгәр укучылар беренче башкарганда дөрес эшләмиләр икән, эшне кабатлап эшләү мөмкинчелеге дә бар.







“Эйлер түгәрә”ген кулланып башкарган эш төрләре:

I. Бер түгәрәк белән эш төрләре

1)“Фонетика”бүлеген өйрәнгәндә авазларга характеристика биргәндә “Эйлер түгәрә”ен кулланып аңлату укучылар өчен уңышлы метод булып тора. Мәсәлән, [а] авазын өйрәнәбез, түгәрәк кырыена [а] авазына туры килгән һәм туры килмәгән билгеләмәләр языла, укучыларга [а] авазына туры килгән билгеләмәләрне генә түгәрәк эченә язарга дигән, эш тәкъдим ителә. Бу эш төрен теманы кабатлаганда кулланырга мөмкин.







2) Яңа теманы билгеләгәдә “Кайсы сүз артык?” дигән эш төре тәкъдим ителә. Артык сүз түгәрәк кырыенда кала. “Матур” сүзе, нинди сорауга җавап булып килә. Дәрестә үтәчәк тема билгеләнә.







II. Бер түгәрәк икенчесенең эчендә

Алга табан эш төрләре катлаулана, эш төрләре катлауланган саен түгәрәкләр саны да арта.

Бу эш төре “Буйсыну” дип атала. Бер төшенчәгә икенче төшенчә тулысынча керә.

1) Беренче түгәрәк “ Сүз төркеме” дип атала, укучыларга “Фигыль” дип язылган икенче түгәрәк тәкъдим итәбез. Әлеге рәсем, түгәрәкләр, барлык фигыльләр дә сүз төркеме төшенчәсенә карый дигәнне аңлата.







2) “Табигать, тау, елга, Агыйдел, Ык, Урал, Ямантау” сүзләрен түгәрәкләргә урнаштырырга кирәк.







3) Укучыларның кызыксынуларын арттыру максатыннан чыгып, эш төрләрен уен формасында тәкъдим итәргә дә була.

Яр буена урнашкан “Фонетика” кунакханәсенә авазлар ял итәргә туктаган. Кунакханә администраторына ике урынлы, өч урынлы, дүрт урынлы, биш урынлы номерларга авазларны бернинди дә ризасызлык тудырмаслык итеп урнаштырырга кирәк. Безнең бурыч кунакханә администраторына ярдәм итү.







III.”Эйлер түгәрәге”н кулланып башкарган икенче эш төре “Кисешү” дип атала.

Дәреснең темасыннан чыгып төшенчәләр саны билгеләнә. Төшенчәләр саны буенча түгәрәкләр саны билгеләнә.Түгәрәкләр уртак зона барлыкка килерлек итеп кисешәләр. Һәрбер түгәрәккә әлеге төшенчәгә генә төгәл билгеләмәләр языла, ә кисешү зонасына барлык төшенчәләр өчен дә уртак билгеләмәләр языла.

Берничә эш төренә күзәтү ясап китәбез.

“Фонетика” бүлеген өйрәнгәндә кулланылган эш төрләре. Аерма һәм уртак якларын табу,

1 нче эш төре – сүзләрне ике түгәрәккә урнаштырырга кирәк;

2 нче эш төре- һәрбер түгәрәккә туры килгән кагыйдәне табып урнаштырырга;

3 нче эш- ике төшенчәгә дә уртак якларны табып кисешү зонасына урнаштырырга.

[н][ң] тартык авазлары

[w][в] тартык авазлары

[h][х] тартык авазлары

“Дөрес авазны билгелә” кебек эш төрләре дә укучыларны нәтиҗә ясарга өйрәтә.







“Морфология” темасын өйрәнгәндә дә “Эйлер түгәрәге” яхшы күрсәтмәлелек булып тора. Затланышсыз фигыльләр темасын өйрәнгәндә кулланылган түгәрәкләр.Укучыларга сыйфат белән сыйфат фигыль, фигыль белән сыйфат фигыль арасындагы уртаклыкны табарга дигән эш тәкъдим ителә.







Исемнәргә морфологик анализ ясаганда да күрсәтмәлелек буларак “Эйлер түгәрә”ген куллану. Җөмлә бирелә “Айгөл өстәлгә өчпочмаклар куйды”.

Исемнәрнең үз-ара уртак морфологик билгеләмәләрен табарга. Шулай итеп, укучылар исемнәргә туры килгән категорияләрне искә төшереп, кисешү зонасына уртак билгеләмәрне, аерым түгәрәкләргә конкрет сүзгә караган билгеләмәләрне генә язып чыгалар.






“Антонимнар” темасын өйрәнгәндә кулланылган түгәрәкләр. Сүзләрне парлап түгәрәкләргә урнаштырырга, аларның нинди сүз төркемнәренә караганын билгеләргә. Бу эш төрен теманы аңлатканда куллану уңышлы.






Укытучыга укучылар белән бергәләп эшләргә мөмкинчелек бар.

Чагыштыру, анализ ясау, классификацияләү, нәтиҗә ясау кебек эш төрләрен без әдәбият дәресләрендә дә кулланабыз.

“ Бу нәрсә?” Бирелгән билгеләмәр буенча предметны табарга, яки табышмак урынына да кулланырга була.






Татар әдәбиятының бөек шагыйре Г.Тукай һәм рус әдәбиятының бөек шагыйре А.С.Пушкинны өйрәнгәндә кулланылган Эйлер түгәрәге.

Аларны нәрсә берләштерә?






Күп кенә әсәрләрне без бер –берсе белән чагыштырып өйрәнәбез. Мәсәлән, Г.Тукайның "Эш беткәч уйнарга ярый", Г.Ибраһимовның "Яз башы"әсәрләренә төзелгән "Эйлер түгәрәкләре".






Бу әсәрләр өчен нинди уртаклык бар? дигән сорау куела. Укучылар башта һәрбер әсәргә туры килгән төп геройларны язып чыгалар, аннан нәрсә алар өчен уртак икәнен билгелиләр.

**Эйлер түгәрәгенең эш этаплары:**

1) теманы өйрәнү, чагыштырыла торган төшенчәләрне аерып алу;

2) һәр төшенчәнең үз билгесен табу;

3) төшенчәләрнең уртак якларын табу;

4) телдән төшенчәләргә характеристика бирү, фикер алышу.

**Эйлер түгәрәген куллану нәтиҗәсе**

1.Күрсәтмәлелектән (геометрик схемадан) мәгълүмат алу;

2.Мәгълүматларның үзенчәлекләрен ачу;

3.Төшенчәләрнең билгеләре буенча гомумиләштерү, классификацияләү, чагыштыру, уртак һәм аерма якларын табу;

4. Анализлау нигезендә нәтиҗә ясау.

Өйрәтә:

1.Башкаларны тыңларга;

2.Телдән үз фикереңне әйтергә;

3. Парларда, төркемнәрдә эшләргә.

# ТЮРКОЛОГИЯ КОНТЕКСТЫНДА Ф.С.САФИУЛЛИНАНЫҢ ЛИНГВИСТИК МИРАСЫ

***Юсупова Ә. Ш.***
***Казан федераль университеты***
***alyusupova@yandex.ru***

***Аннотация.*** Тел гыйлеме тарихында белемгә юл ярып барган, әле өстәвенә үзләре артыннан башкаларны да ияртеп барган көчле профессорлар бар. Шундый шәхесләрнең берсе галимә, татар теле белгече, филология фәннәре докторы (2000), Казан дәүләт университеты (хәзер КФУ) профессоры (1997), гамәли тел белеме һәм тәрҗемәчелек кафедрасы мөдире, Татарстанның атказанган укытучысы (1993), Каюм Насыйри премиясе лауреаты (2001), Халыкара төрки академиянең хакыйкый әгъзасы (1997), Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе (2004) Флера Садри кызы Сафиуллина.

***Ачкыч сүзләр:*** тюркология, татар теле белеме, лексикология, лексикография, синтаксис

Филология фәннәре докторы, профессор Флера Садри кызы Сафиуллина – үзенең татар лингвистикасы һәм тюркологиясе өлкәсендәге фәнни хезмәтләре белән Татарстанда һәм Россиядә генә түгел, дөньяның күп илләрендә танылган галим. Аның турында, ул язган фәнни хезмәтләр, дәреслекләр хакында күп җирдә беләләр. Чөнки аның укучылары Америкада да, Япония, Кытай, Алмания, Финляндия һәм Төркиядә.

Бөтен гомерен галим татар телен фәнни яктан өйрәнүгә багышлаган. Ф.С. Сафиуллинаның фәнни эшчәнлеге татар теле белеменең күп төрле өлкәләрен колачлый: тасвирлама һәм тарихи синтаксис, сөйләм теле синтаксисы, текст төзелеше, рус һәм татар телләренең чагыштырма синтаксисы, текст синтаксисы, татар теленең диалектлары, әдәби тел тарихы, матур әдәби теле, татар теленең стильләре, татар теленә өйрәтүнең методик нигезләре, татар теленең лексикологиясе, терминологиясе, лексикографиясе...

Ф.С. Сафиулина хезмәт эшчәнлеген 1960 нчы елда университетның татар теле кафедрасында лаборант буларак башлап җибәрә, аннары яңа оешкан татар теле кафедрасында ассистент вазифасын башкара. Күренекле галим М.З. Зәкиев җитәкчелегендә 1962-1965 нче елларда аспирантура үтеп, 1966 нчы елда “Татар телендә сүз тәртибе” дигән темага кандидатлык диссертациясе яклый. Флёра Садриевна 1971нче елга кадәр әлеге кафедрада ассистент, соңрак доцент булып эшли [1:259].

Профессор Ф.С. Сафиуллина – 300 дән артык фәнни монографияләр һәм фәнни-методик хезмәтләр авторы. Моннан кала, ул – 500дән артык якын фәнни һәм укыту-методик мәкаләләре белән татар тел белеменең үсешенә зур өлеш керткән шәхес. Алар арасында татар теленең синтаксисы, лексикологиясе, стилистикасы, татар һәм рус телләренең чагыштырма грамматикасы, югары уку

йортлары, мәктәпләр, колледжлар, гимназияләр өчен программалар, дәреслекләр зур урын алып тора. Галимә лексикография (антонимнар, синонимнар, омонимнар, татар һәм рус фразеологик сүзлекләре, лингвистик әйтелмәләр сүзлеге, балалар өчен рәсемле сүзлек, татарча-русча, русча-татарча кесә сүзлеге һ.б.), татар телен чит тел буларак укыту методикасы юнәлешләрендә дә эшли.

Ф.С. Сафиуллинаның фәнни мирасына күз салсак, лексикология өлкәсенә караган хезмәтләреннән түбәндәгеләрне атап була: "Тел дигән дәрья бар ..." (1979), "Хәзерге татар әдәби теле" (1993, 1994, 2002), "Хәзерге татар әдәби теле. Лексикология (югары уку йортлары студентлары өчен)", "Тел гыйлеменә кереш" (2001) һәм берничә күнегүләр җыентыгы (1975, 1992, 1998, 2002 һ.б.).

Ф.Сафиуллинаның сүзлекләр төзү эше белән 1980нче еллар уртасыннан шөгыльләнә башлый. Аңа кадәр ул үзе татар сүзлекләре тарихын өйрәнә, басылган сүзлекләргә тасвирламалар, рецензияләр яза. Галимә "Татарча-русча сөйләүлек" (1986), "Карманный татарско-русский и русско-татарский словарь" (1996, 2001), "Базовый татарско-русский и русско-татарский словарь для школьников" (1997, 2000, 2012), "Татарча-русча һәм русча-татарча сүзлеге" (1997), "Татар теленең омонимнар сүзлеге" (1997), "Краткий русско-татарский словарь для работников образования" хезмәте (1997), "Детский русско-татарский иллюстированный словарь = Балалар өчен русча-татарча рәсемле сүзлек" (1998), "Учебный англо-татарско-русский словарь-минимум" (1999), "Татарча-русча-французча сүзлек" (2001), "Антонимнар сүзлеге (Хәзерге татар поэзиясе һәм мәкальләрдән)" (2005) һ.б. сүзлекләр авторы.

Татар теле гыйлеменең кайсы гына тармагын алып карасаң да, аның нигезендә тел галиме Ф.С. Сафиуллинаның фәнни-теоретик хезмәтләре, тәгълиматлары ята. Шулай да, Ф.С.Сафиуллинаны, иң беренче чиратта, синтаксист галим дисәк дөресрәк булыр. Фәндә үз мөстәкыйль карашы, үз мәктәбе булган галим күп еллар татар синтаксисы өлкәсендә зур хезмәт куя.

60 нчы елларда татар синтаксисы өлкәсенә М. Зәкиевнең аспирантлары килә башлый. Алар арасында Ф.С. Сафиуллина була һәм ул үзенең хезмәтләре белән татар синтаксисын баетуга шактый өлеш кертә.

1965 елда "Вопросы татарского языкознания" җыентыгында Ф.С. Сафиуллинаның "Вопросы порядка слов в татарском языке" темасына язылган 46 битлек фәнни мәкаләсе басылып чыга.

1960 елларда төрки теле белемендә җөмләдәге сүз тәртибен өйрәнү мәсьәләсе шактый актуаль була. Диссертацияләр, фәнни мәкаләләр, монографияләр языла. Мисалга тюрколог галимнәрнең түбәндәге эшләрен китереп була: Л.Ю. Тугушеваның "Төрки телләрдә сүз тәртибе турында (сорауның куелышы)" ("О порядке слов в тюркских языках (К постановке вопроса)" рус телендә, 1966), М.Б.Кетенчиевнең "Карачай-балкар телендәге атау җөмләләрнең структура һәм семантикасы" ("Структура и семантика именных предложений в карачаево-балкарском языке", 2001), Г.Басырованың "Башкорт җанлы сөйләм теленең бер специфик үзенчәлеге буларак ялгау" ("Присоединение как специфическая особенность башкирской разговорной речи", 2010), Н. Н. Ефремовның "Якут

телендә сүз тәртибенең төп функцияләре” (“Основные функции порядка слов в якутском языке”, 2013) һәм башка бик күп фәнни хезмәтләр Ф.С.Сафиуллинаның югарыда әйтелгән фәнни эшенә таяна.

Аспирантурага кабул ителгәч, Ф.Сафиуллина студентлар белән дәресләр алып бара башлый, параллель рәвештә “Татар телендә сүз тәртибе” темасына диссертациясен төгәлли. Бу ул вакытта төрки телләрдәге сүз тәртибенә багышланган, югары фәнни таләпләргә җавап бирерлек бердәнбер хезмәт була. Галимә 1966 елда “Порядок слов в современном татарском литературном языке” дигән темага кандидатлык диссертациясен яклый. Бу диссертация, тагын да эшкәртелеп, 1974 елда “Татар телендә сүз тәртибе” дигән исем астында аерым китап булып басылып чыга.

“Татар телендә сүз тәртибе” хезмәтендә автор татар телендә сүз тәртибе закончалыкларын ачуны максат итеп куя. Ул төрки, угро-фин, рус-герман һәм гомум тел белемендә бу темага мөнәсәбәтле махсус әдәбиятны (библиографиядә генә дә өч йөзгә якын хезмәт китерелә!) җентекле өйрәнеп, төрле фикерләрне анализлый, гомумиләштерә, аерым галимнәрнең фикерләрендә очраган каршылыклы якларны тотып алып, бу каршылыкларның сәбәпләрен ачыкларга тырыша. Бай фәнни мирасны шул рәвешчә өйрәнү аңарга бердәнбер дөрес юлны сайлап алырга һәм алдында торган бурычларны, әле хәл ителмәгән яки тирәнтен яктыртылмаган мәсьәләләрне ачыкларга мөмкинлек биргән.

Ул елларда җөмләнең актуаль кисәкләргә бүленеше турындагы фән татар тел белемендә әле үзенең беренче адымнарын гына ясый. М.Зәкиевнең татар синтаксисын өйрәнүгә багышланган хезмәтләрендә беренче тапкыр көн тәртибенә куелган бу проблема Ф.Сафиуллина китабында гаять бай фактик материал нигезендә төрле яклап махсус тикшерелә. Моңарчы язылган хезмәтләрдә җөмлә кисәкләренең гадәти урыннары гына күрсәтелеп, теге яки бу тәртипнең сәбәпләре ачыкланмыйча кала биргән. Ф.Сафиуллина китабында актуаль кисәкләргә бүленеш һәм җөмлә кисәгенең коммуникатив йөкләнеше һәр җөмлә кисәгенең урынын билгеләүдә төп рольне үтәве ачык күрсәтелә. Моны хәтта тиңдәш булмаган аергычларның урнашу тәртибендә дә күрергә мөмкин.

Халыкның гадәти җанлы сөйләм теле моңарчы галимнәрнең игътибарыннан читтә кала килгән. Ф.Сафиуллина үзенең хезмәтендә, татар тел белемендә беренче булып, халыкның җанлы сөйләм теле синтаксисын тикшерә башлый, җанлы сөйләмнең фәндә моңарчы теркәлмәгән күп кенә үзенчәлекләрен ача.

Ф.С. Сафиуллина татар синтаксисының яңа юнәлешенә – җанлы сөйләм синтаксисына нигез сала һәм аны аерым фән дәрәҗәсенә күтәрә. 1978 елда аның “Синтаксис татарской разговорной речи” дигән күләмле монографиясе дөнья күрә.

Ф.С. Сафиуллина 2000 елның маенда “Татар әдәби теле синтаксисының үсеше (XX гасыр)” (“Развитие синтаксического строя татарского литературного языка”) дигән темага докторлык диссертациясе яклый. Флера Садриевна зур синтаксик материалда гади һәм катлаулы җөмлә структурасында тезмә сүз

синтаксисының төгәл үсеш юнәлешләрен күрсәтә. Диссертация Мәскәү, Казан, Уфа, Чабаксар тюрколог-галимнәре тарафыннан югары бәяләнә. Алар биргән бәяләмәләрдә бу фәнни хезмәтнең актуальлеге һәм фәнни яңалыгы ассызыклана. Мисал өчен, филология фәннәре докторы, профессор Д.М.Насилов әлеге хезмәтенең бер үзенчәлеге дип авторның бирелгән вакыт аралыгында милли телләр үсеше фонына булган игътибарын атый [2: 19]. Шуңа нигезләнеп, татар теленең изоляциядәге үсешен түгел, ә бәлки кардәш төрки телләрдәге гомуми синтаксик үзгәрешләргә бәя бирү мөмкинлеге тудырыла.

Ф.С.Сафиуллина әлеге хезмәтендә синтаксис төзелешенең динамикасына күзәтү ясап, күп кенә новацияләрнең кануни үсеш, төрки синтаксисның аерым үзенчәлекләре тарихи яктан активлашуыннан булуын ассызыклый. Синтаксистагы күренешләрне комплекслы күзәтү аларның шушы вакыт аралыгындагы башка төрки телләргә дә характерлы булуын күрсәтә.

Шулай ук филология фәннәре докторы, профессор Р.Г.Сибәгатовның әлеге хезмәт турында әйтелгән фикере дә шактый әһәмиятле: “Тулы йөз ел эчендә әдәби телнең формалашу процессы уртак милли телгә якынаю, басма сүзнең демократизацияләшү процессы буларак тасвирлана” [2: 24]

Татар тел белемендә беренче тапкыр Ф.Сафиуллина тарафыннан язма телнең демократизацияләшүенең эчке механизмы ачыла. Ягъни ул әдәби телгә җанлы сөйләм элементларының үтеп керү процессына тирән анализ ясый. Әлеге элементларның башта диалогик, аннан соң монологик сөйләмгә, автор сөйләменә керүе һәм матур әдәби тел стилендәге үзгәрешләр барлыкка килүенең сәбәбе булуы турында дәлилле, хронологик тасвирлама ясала.

Галимә тарафыннан исем сүзтезмәләрендә рус теленнән кергән сыйфатларның функцияләшүе үсеше нәтиҗәсендә барлыкка килгән үзгәрешләр, шулай ук калькалашкан сүзтезмәләрнең һәм татар телендәге сүзтезмәнең үсешендәге башка төр үзгәрешләр бүтән төрки телләр төзелешенә караганда шактый үзенчәлекле позициядә бирелә [2: 29].

Ф.С.Сафиуллинаның татар әдәби теленең синтаксик төзелешен өйрәнеп язылган “Татар телендә сүз тәртибе”, “Синтаксис татарской разговорной речи”, “Развитие синтаксического строя татарского языка в советский период (простое предложение)”, “Текст төзелеше”, “Сопоставительный синтаксис русского и татарского языков” монографияләрендә һәм күпсанлы фәнни мәкаләләрендә татар синтаксисы фәненең көн кадагындагы мәсьәләләре күтәрелә. Аның хезмәтләрендә гади һәм кушма җөмлә структурасында үзгәрешләр, татар теленең синтаксик системасының үсеш тенденцияләре билгеләнә.

Ф.С. Сафиуллина, татар һәм төрки тел белемендә беренчеләрдән булып, татар сөйләм теле синтаксисын, диалекталь синтаксис һәм текст стилистикасы, рус һәм татар телләренең чагыштырма синтаксисларын өйрәнә. Аның фәнни тикшеренүләре хронологик яктан тулы бер дәверне – XX гасырны үз эченә ала.

Ф.С. Сафиуллина кыскартылма конструкцияләр, парцелляция, башлам, сөйләмнең актуаль кисәкләре, “сөйләмә конструкцияләр” кебек һ.б. татар синтаксисында урын алган кызыклы күренешләрне бәян итә. Тел материалларына таянып, ул сөйләм теле һәм диалектларның әдәби телгә

тәэсирен дәлилләп күрсәтә. Синтаксик төзелеш динамикасын күзәтеп, Ф.С.Сафиуллина төрки синтаксиска хас күпчелек үзгәрешләрнең закончалыклы булуын раслый. Шул ук вакытта аларның телнең эчке һәм тышкы факторлары тарафыннан тизләтелүен дә кире какмый. Аерым алганда, киң таралыш алган милли-рус икетеллелегенең тәэсире зур булуын ассызыклый. Бу процессларны галимә төрле елларда язган дистәләгән фәнни мәкаләләрендә тасвирлый.

Ф.С. Сафиуллина татар тел белемендә стилистиканы өйрәнгән галимнәрнең берсе. Мәсәлән, "Татар телендә сүз тәртибе" хезмәтнең зур өлеше сүз тәртибенең стилистик мөмкинлекләрен ачыклауга багышланган. Төрки телләрнең агглютинатив (ялганмалы) табигате һәм сүз тәртибендәге табигате һәм сүз тәртибендәге кайбер катгыйлык аның стилистик функциясен бераз чикли, әлбәттә. Ф.Сафиуллина беренче булып, сүз тәртибенә нигезләнгән дистәләрчә синтаксик сурәтләү чараларын барлый, тәртипкә сала, тасвирлый.

1993 елда Ф.С. Сафиуллина "Текст төзелеше" дигән махсус китап чыгара һәм текстның күп проблемаларын бик бай мисалларда аңлатып бирә.

Ф.С. Сафиуллина – тюркологиядә, татар теле белеме өлкәсендә фундаменталь хезмәт куйган шәхес. Аның хезмәтләре фәнни яктан тирән эчтәлекле, фактик материалга бай булулары белән аерылып тора, һәм хәзерге көндә тел белеме өлкәсендә барган эзләнүләр өчен нигез вазифасын башкаралар. Галимәнең хезмәтләре татар теленең үткәнен барларга, бүгенгесен аңларга, киләчәк үсеш юлын фаразларга ярдәм итәләр.

Телне саклаучы төп көч халык үзе булса да, аны билгеле бер нормаларга салып камилләштерү эшен тел галимнәре башкара. Әгәр без бүген татар әдәби теле матур яңгырашлы, төзек, төгәл, аралашу өчен уңайлы, эзлекле системага салынган дибез икән, бу – татар тел белеме өлкәсендә эшләгән берничә буын галимнең уртак хезмәт нәтиҗәсе. Тел галимнәре халыкны саклап калу, аның рухи үсешен тотрыклы итү өчен хезмәт куя. Шуңа күрә без телебезнең электән килгән байлыкларын, бүгенге үсеш чыганакларын барлап, фәнни яктан камилләштереп, халыкка яңадан кайтарып бирүче тел галимнәребез хакында белергә бурычлыбыз.

**Әдәбият**

1.Сафиуллина Флера Садриевна // Казанская лингвистическая школа. – книга первая: Казанская тюркологическая лингвистическая школа. – Казань: Татар. кн. из-во., 2008. – С. 259-261.

2.Фәнгә багышланган гомер. – Казан: Казан дәүләт ун-ты, 2008. – 216 б.

# БАЛАЛАР СӨЙЛӘМЕНДӘГЕ КИМЧЕЛЕКЛӘРНЕ БЕТЕРҮ

***Юсупова Р.И. Юсупов З.З.***
***Саба районы Курсабаш мәктәп- интернаты***
***Raila1973@mail.ru; uzz73@mail.ru***

